РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ЮГАРЫ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМИЯЛЕ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
«КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ»

**Г.Г. Зәйнуллин**

# Әдәп-әхлак дәресләре

**УКУ ЯРДӘМЛЕГЕ**

КАЗАНЬ
2014

**УДК 2+37.0**
**ББК 86.38**
**З 17**

Ислам диненең тарихын һәм мәдәниятын тирән белүче белгечләрне хәзерләү буенча Федераль максатлы программа чикләрендә Казан (Идел буе) федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Фәнни Советы рекомендациясе буенча басыла

**Рецензентлар:**
филология фәннәре докторы, профессор **Хисамова Фәһимә Миргалим кызы,**
филология фәннәре кандидаты, доцент **Гыйлемшин Флүр Фоат улы.**

**Зәйнуллин Г.Г.**

З 17 **Әдәп-әхлак дәресләре**: уку ярдәмлеге / Г.Г. Зәйнуллин. – Казан: Казан университеты нәшрияты,2014. – 84 б.

**ISBN 978-5-00019-260-3**

Әлеге китапка тупланган Коръән тәфсирләреннән кыйссалар, риваятьләр, хәдисләр татар рухани әдәбиятының нәни генә өлешен тәшкил итә.

Дөрес юлдан барырга ниятләгән миһербанлы адәм балалары» өчен ярдәмлек буларак тәкъдим ителгән шушы китапны кулына алып, укучы шәфкатьлелек юлына басар, ялгыш адым ясаудан тыелып калыр, кешеләргә һәрдаим дустанә мөнәсәбәттә булыр дигән өметтә калабыз.

**ISBN 978-5-00019-260-3**

**© Зәйнуллин Г.Г., 2014**
**© Казан (Идел Буе) федераль университеты, 2014**

**Эчтәлек**

**Кереш сүз** .................... 4
**«Кабуснамә»дән хикәятләр** .................... 8
Ата-ананы хөрмәтләү турында .................... 8
Кешене бизи торган күркәм сыйфатларның тагын берсе – белемле һәм һөнәрле булу .................... 9
Сүз сөйли белүнең шартлары .................... 20
**«Кәлилә вә Димнә» әсәреннән бер гыйбрәтле хикәят** .................... 24
Кеше үзенең кулыннан килми торган эшкә тотынса, теләгенә ирешә алмас һәм булганын да югалтыр .................... 24
**«Кабуснамә»дән хикәятләр** .................... 36
Үзеңне тота белү, тыйнаклык һәм ашау-эчү тәртибе турында .... 40
Шәраб эчү турында .................... 42
Кунак чакыру турында .................... 43
Шаяру, уен-көлке сөйләү турында .................... 44
Мунчаның файдасы һәм зыяны турында .................... 45
Йоклауның файдасы һәм зарары турында .................... 46
Мал-мөлкәт туплау турында .................... 47
Өйләнү турында .................... 48
Ир баланы тәрбияләү турында .................... 49
**Хәдисләр** .................... 51
**Татарча Коръән тәфсирләреннән кыйссалар** .................... 58
**Сүзлекчә һәм аңлатмалар** .................... 81
**Файдаланылган әдәбият** .................... 83

# *Кереш сүз*

Татар халкының рухани мирасы саекмый торган чишмә кебек ул. Бу чишмәнең шифалы суына ихтыяҗ арткannan-арта гына бара. Дистә гасыр дәвамында иҗат ителгән бу мираста кешеләрдә булырга тиешле күркәм сыйфатларның барысы да тупланган дияргә мөмкин: ата-анага итагатьле булу, кешеләргә яхшы мөгамәлә һәм игелек күрсәтү, карендәшләргә – мөрәүвәтле, хайваннарга, җан ияләренә рәхимле булу һ. б. Шул ук вакытта кешене ямьсез итеп күрсәтүче сыйфатлардан – икейөзлелек, гайбәтчелек, хөсетлек, мактанчыклык һәм башка бозык гамәлләрдән сакланырга кирәклеге гыйбрәтле хикәяләр үрнәгендә бәян ителә. Боларны дәлилләп күрсәтү өчен Коръән сүрәләреннән аятьләр, Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләре, аның гаиләсе һәм сәхабәләренә кагылышлы риваятьләр китерелә. Көндәлек тормышта кешеләр арасында очрый торган уңай һәм тискәре күренешләр дә чагылыш тапкан. Кыскасы, руханият әдәбиятында әдәп-әхлак кануннарының барысын да табарга мөмкин. Шуңа күрә аны укымышлы зыялылар да, гади халык та, олылар һәм кечеләр дә яратып укыган, файдасын күргән. Җыеп кына әйткәндә, халкыбыз рухани әдәбиятка һәрвакыт игътибарлы булган. Игелекле максатларга ирешүдә мөселманнарны берләштерүче изге Коръәннең, аңарга нигезләнеп иҗат ителгән башка әдәп-әхлак китапларының роле зур булганлыгы берәүдә дә шик тудырмас. Татар халкы шәрык халыклары белән аралашып яшәгән, бигрәк тә мөселман илләренең тәэсире көчле булган. Мөселман галимнәре иҗат иткән Коръән тәфсирләре, хәдисләр җыентыгы, «Мөхәммәдия», «Алты бармак», «Сәясәтнамә», «Сәгадәтнамә», «Котадгу белек», «Һибәтел-хакаик» һ.б. китаплар белән бергә «Кәлилә вә Димнә», «Һумаюннамә», «Кабуснамә» кебек тәрҗемә әсәрләре дә, Имам Газәли, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани, Хуҗа Әхрар һ. б. мәшһүр әдипләрнең хезмәтләре дә татарлар арасында киң таралган булган.

Рухи яктан сәламәт кеше нинди сыйфатларга ия булырга тиеш соң? Руханият әдәбиятында бу сорауга җавапларның күп төрлесен табарга мөмкин. Беренче урында – иманлы булу, Аллаһка һәм аның илчесе Мөхәммәд галәйһиссәламгә мәхәббәт саклау, кыскача әйткәндә, иманның асылларын белү, аңарга тугрылыклы булу.

Мәгълүм булганча, ислам динендә иманның нигезе алтау. Аллаһның барлыгына һәм берлегенә ышану, аның фәрештәләренә, пәйгамбәрләренә, иңдерелгән китапларына (Тәүрат, Инҗил, Коръән), тәкъдиргә, ахирәт көненә чын күңел белән ышанып тану, телебез белән икърар итү. Игелекле эшләрне дә санап үтелгән гамәлләргә өстәргә ярашлы булыр. Чөнки Мөхәммәд пәйгамбәр: «Иманлы булу сүздә генә түгел, эшләгән гамәлләрдә дә күренергә тиеш. Үзен иманлы итеп санаучы кеше – кулы, теле белән башка мөселманга зыян салмас, ач-ялангачларга ярдәм кулын сузар, үзе таныган һәм танымаганнарга да сәлам бирер»,– дип әйтеп калдырган. Иман сүзен шәригать хөкемнәренең барысына да ихласлык белән ышанып, буйсынып эш итү дип аңларга кирәк. Ул хөкемнәр турында Аллаһ Тәгаләнең Коръәни Кәримендә һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләрендә тәфсилләп бәян ителә.

Рәсүлүллаһның тирән мәгънәле хәдисләрен эзләп тапкан, аларны тикшергән һәм иң ышанычлы булганнарын бергә туплаган күренекле галим Исмәгыйль әл-Бохари була. Галимнәрнең раславынча, Бохари җыйган хәдисләрнең саны алты йөз меңнән дә артыграк. Тормышның төрле мәсьәләләренә кагылышлы хәдисләр аерым китапларга тупланган. Мәсәлән, «Тыйб (медицина) китабы», «Киенү турындагы китап», «Әдәп китабы» «Рөхсәт сорау китабы», «Күркәм сүзләр китабы», «Догалар китабы», «Тәкъдир китабы», «Ант итү һәм нәзер атау китабы», «Хәйләләр китабы», «Фетнәләр турындагы китап» һ. б.

Ислам дине ата-анага итагатьле, миһербанлы булырга, аларны рәнҗетмәскә, яхшы тәрбияләргә куша. Аллаһның Рәсүле Мөхәммәд галәйһиссәлам каршысына килеп, Әбү-Һүрәйра: «Йә Рәсүлүллаһ, яхшылыкның иң зурысына кем лаеграк?» – дип сораган. Рәсүлүллаһ: «Әниең», – дип җавап биргән. Әбү-Һүрәйра: «Тагын кем?» – дип сораган. Рәсүлүллаһ: «Әниең», – дигән. Әбү Һүрәйра: «Тагын кем?» – дип сорагач, Рәсүлүллаһ бу сорауга да: «Әниең», – дип җавап биргән. Дүртенче тапкыр сораганнан соң гына Рәсүлүллаһ: «Әтиең», – дип җавап биргән.

Адәм баласы тарафыннан эшләнә торган гөнаһларның иң зурысы – ата-ананы рәнҗетү, хурлау. Кеше үз ата-анасын ничек хурласын инде диючегә Мөхәммәд пәйгамбәр: «Берәүнең ата-анасын хурлаган кеше үзенең ата-анасын да хурлаган булыр», – дип җа-

вап биргән. Кайковус бине Искәндәр бине Кабус исемле патша язып калдырган «Кабуснамә» китабында әдәп-әхлак темаларына зур урын бирелгән. Унберенче гасырда гыйлем, мәдәният һәм сәнгать үсеше шактый алга киткән була: Әбү Габдулла Рудаки, Әбүлкасыйм Фирдәүси Туси, Әбүлхәсән Бинни Әхмәд, Унсури, Әбүлхәсән Фәррухи, Низамүл-Мөлек, Гомәр Хәйам, Насир Хөсрәү кебек шагыйрьләр дә шул чорда яшәгәннәр, иҗат иткәннәр. «Кабуснамә» әсәре дә шул чорда дөнья күрә. Бу әсәр кырык дүрт бүлекчәдән гыйбарәт. Әдәби әсәр булып саналса да, «Кабуснамә»-нең баштагы дүрт бабы Аллаһ Тәгаләнең барлыгын һәм бердәнбер булуын танырга, аңарга турылыклы булырга, пәйгамбәрен яратырга кирәклеге һәм Аллаһка шөкер итәргә чакыра:

«Әй улым! Хак Тәгаләнең берлеген белмәк өчен китапның әүвәлендә йад кыйлдым[1] та ке игътикаднең юлы мөхкәм булсын[2]. Чөнки күп кешеләр аны белмәгәнлек сәбәпле гомраһ булдылар[3], ягъни азгыннардан булдылар. Әмма пакь назар ияләре[4] хата итмәделәр[5]. Әй улым, шойлә[6] белгел ки, Хак сөбханэ вә Тәгаләнең[7] барлыгы заһир[8] да вә яшерен дә, йирдә вә күкдә булган нәрсәләрдән истидлял[9] кыйлуб гакыл белән беленүр. Әмма Аллаһ Тәгаләнең зат-шәрифе[10] тасавур гакылдан мөнәззәһдер[11], ягъни Аллаһ Тәгалә алай микән, болай микән дип күңелгә килгән нәрсәләрдән һәммәсендин мөнәззәһдер[12]».

Димәк, иманы нык булган кешенең барлык эшләре дә пакь була. Аллаһны һәм аның пәйгамбәрен сөйгән, ата-анасын хөрмәт

---

[1] *Йад кыйлдым* – искә алдым.
[2] *Та ке игътикаднең юлы мөхкәм булсын* (ф а р с ы – г а р ә п) – ышануың, (тоткан) дин юлың ныклы булсын өчен.
[3] *Гомраһ булдылар* (ф а р с ы) – алдылар, адаштылар.
[4] *Пакь назар ияләре* (ф а р с ы – г а р ә п) – саф күңеллеләр.
[5] *Хата итмәделәр* (г а р ә п) – ялгышмадылар.
[6] *Шойлә* (төрек) – шулай итеп.
[7] *Хак сөбханэ вә Тәгалә* (г а р ә п) – Аллаһка, бөек Тәңрегә (дан).
[8] *Заһир* (г а р ә п) – ачык.
[9] *Заһир* (г а р ә п) – ачык.
[10] *Зат шәрифе* (гарәп) – аның бөеклеге.
[11] *Тасавур гакылдан мөнәззәһдер* (гарәп) – акыл белән аңлап белә торган гына түгел, акыл җитмәслек дәрәҗәдә булу.
[12] *Һәммәсендин мөнәззәһдер* (ф а р с ы – г а р ә п) – барысыннан да өстен.

иткән кешенең догасы да кабул булачак. Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең сәхабәләренә бик гыйбрәтле бер хикәятне сөйләгән:

«Өч кеше юлга чыгалар. Кинәт яңгыр ява башлый, һәм болар тау куышына кереп ышыкланалар. Шулвакыт зур бер таш, тәгәрәп төшеп, тау куышыннан чыгу юлын томалап куйган. Өч дус бер-берсенә: «Аллаһ Тәгалә юлында берәр яхшылык эшләгән булсагыз, аңардан ярдәм сорап ялварыгыз, бәлки, Ул ярдәмен ирештерер һәм тау куышының авызын ачар», дигән. Аларның берсе: «Әй Раббым! Минем өемдә картайган ата-анам һәм кечкенә балаларым калды. Аларны тәрбияләү өчен куйлар көтүен көтә идем. Куйлардан сауган сөтне балаларымнан әүвәл ата-анама бирә идем. Шулай бер көнне куйларымны утлатырга дип ерактагы җәйләүгә куалап илткән идем. Мин кайтканда әти-әнием йоклаганнар иде. Куйларымны савып, эшемне төгәлләп, аларга сөт алып кердем, ләкин үзләрен йокыларыннан уятырга базмадым, баш очларында утырып, үзләре уянмасмы дип көтеп тордым. Балаларым янымда сөт сорап, көйсезләнеп йөрделәр. Шул килеш без таңны аттырдык. Әй Раббым! Моны мин синең хакың өчен эшләдем. Ялварып сорыйм үзеңнән, Раббым, шул ташны бераз гына булса да урыныннан кузгалтып, якты дөньяның нурын безгә күрсәтсәң иде», – дип, Аллаһка ялварган. Аллаһ Тәгаләнең рәхмәте белән тау куышын томалап торган таш урыныннан кузгалып куйган, һәм өч дус зәңгәр күкне күрү бәхетенә ирешкәннәр.

Шулай итеп боларның һәркайсы эшләгән игелекле эшләрен исләренә төшерәләр, Аллаһка ярдәм сорап ялваралар. Тәңре Тәгалә дә аларга миһербанлык күрсәтә һәм тау куышыннан сау-сәламәт килеш чыгарга ярдәмен ирештерә».

Шуңа охшашлы гыйбрәтле кыйссаны Коръәннең «Әл-Кәһәф» сүрәсен укып белергә мөмкин. Бу сүрәдә үзләренә үлем куркынычы янаганда да Раббыларына, иманнарына тугрылык саклаган берничә егет турында бәян ителә. Боларга таянып, шундый нәтиҗәне ясарга мөмкин: ата-ана хакы ислам динендә шәргый югарылыкка куелган.

# «Кабуснамә»дән хикәятләр[13]

## Ата-ананы хөрмәтләү турында

Әй улым! Ата-ана хакларын хакла, аларны олыла, хөрмәтлә. Шул чагында син үзеңне дә кадерле иткән булырсың, зур дәрәҗәләргә ирешерсең. Моның белән син үз асылыңны хөрмәт иткән булырсың. Чөнки баланың асылы (нигезе) – ата-анадыр. Алар үз теләкләренә ирешү өчен генә түгел, бәлки сине дөньяга китерү өчен дә кавыштылар. Ата-анаң булмаса, син дөньяга килмәс идең. Аллаһ Тәгалә шулай итеп яраткан инде, ата-анаң, сиңа берәр авырлык, зыян килмәсен дип, синең өчен үләргә дә әзер торалар. Аллаһ Тәгалә сине ата-анаңның газизе, сөеклесе итеп яратты. Үз җаныңны ничек яратсаң, сине бар иткән Раббыңны да шулай яратырга бурычлысың. Аллаһ Тәгаләне никадәрле олыласаң, ата-анаңны да шулай яраткан, хөрмәтләгән булырсың. Әгәр син ата-анаңа тупас, дорфа булсаң, аларга начарлык эшләсәң, ул чагында син беркайчан да яхшылыкка лаек булмассың. Газиз ата-анасыннан изгелек күреп тә, аны аңлый, бәяли белмәгән кеше башкаларның да яхшылыгын күрә белмәс. Әгәр балаңның үзеңә хөрмәт күрсәтүен теләсәң, иң элек ата-анаңны хөрмәтлә. Адәм баласы – җимешкә, ата-ана шул җимешне бирүче куакка охшый. Куакны ничаклы яхшырак тәрбияләсәң, аның җимеше дә татлы була. Димәк, ата-анага кадер, хөрмәтне күбрәк күрсәтсәң, аларның догалары, теләкләре тизрәк кабул булыр, бәрәкәте сиңа ирешер.

Тагын шуны да белеп тор, әй улым: мирас алу теләге белән ата-анаңның үлемен теләмә. Малсызлыктан ярлы булсаң да, акыл белән бай бул. Чөнки мал-мөлкәткә караганда акылга бай булу бик күпкә хәерлерәк. Акыл белән байлык табып була, әмма байлык белән акылны табу мөмкин түгел. Надан, җаһил кеше бик тиз ярлылана. Ләкин белеп тор: акыл шундый кыйммәтле нәрсәдер ки, аны карак та урлап китә алмас, ул утта да янмас, суга да батмас.

Әгәр акылың булса, һөнәр үзләштер. Чөнки һөнәрсез акыл ялангач тәнгә яки ояты булмаган кешегә тиң. Шуңа күрә белемне акылның көзгесе дип әйткәннәр борынгы акыл ияләре. Тагын бер

[13] *Кабуснамә*. Госманлы төрек теленнән Габделкаюм мелла Габденнасыйр углы Насыйри тәрҗемәсе. Казан, 1882. 4 б.

тапкыр искәртеп әйтәм: «Ни өчен әле мин ата-анамны хөрмәтләргә, тәрбияләргә тиешмен?» – дип күңелеңә дә китермә. Әгәр бала үз акылында булса, ата-анасына лаеклы кадер-хөрмәтне күрсәтергә бурычлы. Хак Тәгалә боерган: «Әтыйгүл-лаһа вә әтыйгүр-расүлә вә үлил-әмри миңкүм». («Нисаэ» сүрәсе, 59 аять.). (Аллаһка һәм аның Рәсүленә буйсыныгыз! Бу сезнең беренче булып үтәргә тиешле бурычларыгыздан).

Татар халкының күренекле мәгърифәтчесе Каюм Насыйри бу аятькә өстәп болай ди: «Бу аяте-кәримнең күп төрле тәфсире, аңлатмалары бар. Ләкин бер тәфсирдә күрдем: иң беренче бурыч – ата-ана хакы дип аңлатыла. Бала ата-ана хөкеменә разый булырга тиешле».

Әй улым, ата-анаңны кимсетмә. Чөнки Хак Тәгалә Коръәндә боерган: «Фәлә тәкуль ләһүмә үффиү, вә лә тәнһәрһүмә вә куль ләһүмә каулән кәримә». («Бәни Исраил» сүрәсе, 23 аять). (Аларга «уф» дип тә, кычкырып та сүз әйтмә. Син аларга карата тәмле телле бул, зур хөрмәт күрсәт).

## Кешене бизи торган күркәм сыйфатларның тагын берсе – белемле һәм һөнәрле булу

Әй улым! Шуны бел: яхшы һөнәрең, осталыгың, белемең белән горурлану нәселең белән мактануга караганда артыграк. Игелекле һөнәрне үзләштер һәм аны камилләштерергә тырыш, һөнәре булмаган кешенең үзенә дә, кешегә дә файдасы тимәс. Андый кеше «могийлан», ягъни чәнечкеле куакка охшар, аның күләгәсендә кеше дә рәхәтлек тапмас, үзенә дә файдасы булмас.

Һөнәре булмаган кешенең нәселе изгеләрдән булса, халык аны күпмедер вакыт фәлән нәсел кешесе дип хөрмәт итәр итүен. Әмма андый кеше әкренләп халыкның ихтирамыннан мәхрүм калачак. Нәсел-нәсәбе һәм һөнәре дә булмаган кешене борынгылар «әл-бәкару фис-сүратил бәшәр» (кеше сурәтендәге сыер) дип әйткәннәр.

Әй улым! Чыгышың, асылың затлы-зыялы нәселдән булса да, һөнәрең, осталыгың белән шөһрәт казан. Бу турыда гарәпләр әйткән: «Әш-шәрфү бил-гакьли вәл-әдәби, лә бил-асли вән-нәсәби».

(Кешенең бөеклеге аның акылына һәм әхлагына карап билгеләнә, чыгышына, нәсел-нәсәбенә карап түгел).

Атаң-анаң биргән исем, шөһрәт белән горурланма, үз һөнәрең һәм ирешкән эшләрең белән горурлансаң да ярый. Чөнки ата-анаң сиңа бары бер генә исем куша, ягъни Әхмәд яки Мәхмүд, яисә Габдулла һәм Габдрахман һ. б. Әмма сиңа үзең үзләштергән һөнәрең, тырышлыгың белән шөһрәт табарга тырышырга кирәк. Яман исем белән даның чыкмасын.

Әгәр кеше яхшы нәселдән булып та, аның ни белеме, ни һөнәре булмаса, андый бәндә белән гәп коруның мәгънәсе юк. Яхшы нәселдән булган һәм һөнәрле кешене очрата калсаң, аның белән аралашырга омтыл, андый кеше белән дуслашырга тырыш. Мондый кеше белән дустанә мөнәсәбәттә булсаң, үзеңә файдасы күп булыр. Шунысын да бел, улым: нәселсез, һөнәрсез, надан һәм ялкау кешене ил күзендә буш бәндә дип атыйлар. Андый җан иясеннән ерак булганың хәерле.

Әй улым! Һөнәрләрнең иң күркәме – сүз һөнәредер. Чөнки Хак Тәгалә адәмне башка җан ияләреннән ун тапкырга өстенрәк итеп яраткан. Бу өстенлекләрнең бишесе адәмнең эчендә яшеренгәннәр, ә калган бишесе тыштан ук күренеп тора. Болар: уйлый белү, хәтер, хыяллана белү, аера һәм сөйләшә белү, ишетү, күрү, кул белән тотып танып белү, ис тою, тел белән татып тоя белү. Бу сыйфатларның кайберләре хайваннарда да бар, ләкин кешедә булган кадәр дәрәҗәдә түгел. Шуңа күрә кеше – барлык хайваннар өстеннән хакимлек итә алучы патша ул.

Санап чыккан бу ун көчнең иң хикмәтлесе – тел осталыгы һәм күркәм сүзлелек. Шуны аңла һәм матур сөйләшергә өйрән, һәрвакыт йөзең мөлаем, сөйләгән сүзләрең мәгънәле булсын. Сүзеңне урынсызга сөйләмә. Кирәксез, урынсыз урында сөйләгән сүз, яхшы булса да, яман итеп кабул ителер. Файдасыз сүзне дә сөйләмә. Чөнки андый сүз үзеңә зыян гына китерер. Сөйләгән сүзең мәгънәле, телең татлы, йөзең якты булсын. Татлы телле кешенең дуслары күп булыр дип юкка гына әйтмәгәннәр борынгылар. Татлы телле кеше сүзнең җаен тапмый торып сүзен әйтмәс. Урынсызга сөйләнгән сүз, ничаклы гына тәмле булса да, ачы булып тоелыр. Сөйли белеп сөйләмәсәң, зыяны үзеңә әйләнеп кайтыр, файдасы булмас. Шуңа күрә кайчагында дәшми калганың яхшырак.

Акыл ияләре сүзне шәрабка тиңләгәннәр, чөнки артыкка киткән шәрабтан баш авырта, чамасын белсәң, авыруына дәва да була ала икән.

Сорамаган нәрсәне сөйләргә кирәкми. Мәгънәсез, файдасыз сүзне сөйләүдән саклан. Колагыңа кергән, ишеткән һәр сүзне сөйләргә ашкынма. Синнән киңәш сорамаган кешегә киңәшеңне бирмә. Сүзләреңә колак салырга теләмәгән кешегә бер генә сүзеңне дә әрәм итмә. Әгәр берәүгә киңәш бирсәң, халык арасында әйтмә, чөнки бу хәл кешенең башына гаебе белән суккан кебек кабул ителер. Шуңа күрә нәсыйхәтеңне аулак урында бирү яхшырак булыр.

Явыз холыклы, киребеткән, юлдан язган кешене төзәтү максаты белән янына барма. Мондый бәндәне үгет-нәсыйхәт белән генә дөрес юлга кертеп булмас. Кәкре үсеп картайган агачны турайтып булмый, аны кисеп алырга һәм балта белән юнырга кирәк була.

Тозлы, уңдырышсыз туфракка орлык чәчмә, шытым бирмәс, хезмәтең генә бушка китәр. Ягъни яхшылыкның кадерен белмәгән кешегә игелек эшләү тозлы туфракка орлык чәчүгә бәрабәр булыр. Әмма яхшылыкка лаек булган кешегә игелегеңне кызганма һәм ул кешегә дә игелекле эшләрне эшләргә өйрәт. Бу уңайдан борынгылар: «Яхшылыкны эшли белгән кеше икенче кешеләрне дә яхшылыкка өйрәтер», – дигәннәр.

Әй улым, кылган игелекле эшләреңне «ник дип әле мин моны, тегене эшләдем» дип кызганып йөрмә. Югыйсә моның җәзасын бу дөньяда ук татырсың. Әгәр син берәүгә яхшылык эшләсәң һәм ул кеше шатлык кичерсә, синең күңелең тагын да күбрәк сөенер. Усаллык белән дә шулай ук: әгәр син кемгә дә булса берәр усаллык эшләсәң һәм ул кеше борчу кичерсә, син үзең тагын да артыграк борчылырсың. Әгәр кемгә дә булса яманлык эшләсәң, үзеңә явызлык булып кайтыр. Димәк, яхшылык та, начарлык та җавапсыз калмый булып чыга.

Әй улым, шикле урынга утырма, ярамас юлда йөргән кешегә юлдаш та булма – ул сине явызлыкка өйрәтмәсен. Андый кешеләрдән ерак бул, гафил булма. Явыз, бозык табигатьле кешенең яманлыгы бер тимәсә бер тияр.

Яхшы табигатьле булсаң, шул сыйфатыңны беркайчан да үзгәртмә. Әгәр үзгәртсәң, ил-халык арасында кадерең югалыр. Үзеңнең кайгыңа сөенмәсеннәр дисәң, кешенең кайгысына сөенмә, гәр-

чә ул дошманың булса да. Яхшылык эшләргә кулыңнан килмәсә, усаллык эшләүдән саклан. Халыкны игелекле эшләргә өндә. Әгәр бер кеше икенче берәүне игелекле булырга өндәсә, ул игелекне үзе эшләгән кебек булыр. Кешегә хыянәт итүдән саклан. Әйткәнемчә, игелекнең дә, хыянәтнең дә җәзасы дөньяда вакытта ук үзеңә кайтыр. Көчеңнән килгән кадәрле игелек эшләргә омтыл, үзеңә дә рәхәт булыр.

*Хикәят.* Багдад шәһәрендә Мөтәвәккил хәлифәдә Фатыйх исемле яшь кенә бер кеше хезмәт иткән. Ул бик күп һөнәрләрне үзләштергән, алтын куллы, булдыклы кешеләрдән саналган. Белмәгән һөнәрләрне өйрәнергә тырышкан. Бу хезмәтче үзенең тырышлыгы, яхшы мөгамәләсе белән хәлифәгә бик ошый, һәм ул аны улыннан да артыграк күрә башлый.

Бер заман Фатыйхта йөзәргә өйрәнү дәрте туды. Хәлифә аның теләгенә каршы килмәде. Фатыйх көймәчеләрдән берничә көн эчендә йөзәргә өйрәнде. Ләкин сабыйлыгы беләнме, күнегүләрне тиешенчә үзләштереп бетерергә сабырлыгы җитмәде. Шуңа да карамастан, үзен оста йөзүче дип саный иде. Шулай бер көнне Фатыйх ялгызы гына су буена килде, чишенеп, суга кереп китте. Суның көчлерәк аккан урынына туры килепме, әллә инде күрәчәге булдымы, су агымы аны эчкә алып кереп китте. Фатыйх ничаклы гына ярга чыгарга тырышса да булдыра алмады, су агымы аны шәһәрдән еракка агызып алып китте. Суның агымы бик көчле иде. Фатыйх салкын суда йөзә-йөзә бик арыды һәм, ниһаять, су уртасындагы утрау сыман кечкенә генә корылыкка чыга алды. Яр да ерак түгел-түгелен, ләкин ул кеше йөри торган урын да түгел иде. Шулай аптырап торганда Фатыйх Диҗлә елгасының кырыенда дулкын ясаган бер чокырны күреп алды һәм, азаплана торгач, шул чокырга кереп утырды. Беркадәр ял иткәннән соң ул үз-үзенә: «Моның ни буласын белмим, әмма җанымны саклап кала алдым», – дип шөкер итте. Җиде көн дәвамында Фатыйх шул чокыр эчендә утырды. Югалган көнендә үк көймәчеләр аны эзләп карадылар, ләкин су буендагы киемнәрен күргәч, суга батып үлгән булса кирәк дигән нәтиҗә ясадылар. Мөтәвәккил хәлифәгә кайтып: «Суга агып киткән, ярга чыга алганмы-юкмы икәнлеген белмибез», – диделәр. Бу хәбәрне ишеткәннән соң, хәлифә тәхетеннән сикереп үк торды һәм бик күп күз яшьләрен түкте. Соңыннан ул, көймәчеләрне

чакырып: «Кем дә кем Фатыйхның мәетен табып кайтса, шул кеше мең алтын акча алачак», – дип боерды. Көймәчеләр су буйларыннан эзләргә керештеләр. Шул вакыт көймәчеләрнең берсе Фатыйх утырган чокырны күрде, аның исән икәнлеген белде. Көймәче бу турыда берәүгә дә әйтмәде һәм, көймәсен кире борып, хәлифә янына кайтты, аңарга болай диде: «Йә мөэминнәрнең әмире, Фатыйхның мәетен табып китергән кешегә мең алтын вәгъдә иттең, аны исән-имин хәлдә табып кайтучыга күпме алтын бирер идең?» Хәлифә әйтте: «Фатыйхны исән-имин килеп табып китерүче биш мең алтын алачак».

Көймәче, барып, Фатыйхны алып кайтты. Хәлифә дә үзенең вәгъдәсен үтәде – биш мең алтынны көймәчегә бирде һәм вәзирләренә әйтте: «Хәзинәне ачыгыз, яртысын ярлыларга садака итеп өләшегез һәм бирегә ризыклар китерегез. Чөнки Фатыйхның җиде көн ашаганы юк».

Фатыйх: «Йә мөселманнарның патшасы, мин ач түгелмен. Аллаһка шөкер, карыным тук», – диде.

Хәлифә әйтте: «Йә Фатыйх, синең Диҗләдән су эчеп карының тукмы әллә?»

Фатыйх җавап бирде: «Җиде көн дәвамында һәркөн бер савыт эчендә егермеләп икмәк агып килә иде. Ләкин мин аларның икесен генә ашый идем. Минем исән калуымның сәбәбе әнә шул ризыкта. Һәр икмәкнең өстендә «Мөхәммәд бин Хәсән әл-Әскәр» дип язылган иде».

Мөтәвәккил хәлифә: «Бу кеше кем булса да минем яныма килсен», – дип фәрман бирде. Күп вакыт үтмәде, бер кеше килеп: «Мин башмакчы Мөхәммәд бин Хәсән», – диде. Хәлифә әйтте: «Моны нәрсә белән исбатлый аласың?»

Башмакчы әйтте: «Дәлилем шул: һәр икмәкнең өстендә минем исемем язылган».

Хәлифә әйтте: «Дәлилең дөрес, ләкин син кайчаннан бирле болай эшли башладың?»

Башмакчы: «Бер ел бардыр», – диде.

Хәлифә сорады: «Син моны нинди максат белән эшләдең соң?»

Башмакчы: «Йә мөэминнәр әмире! Бервакыт ишеткән идем: яхшылык эшлә дә дәрьяга ташла, кайчан да булса үзеңә файдасы тияр дигән сүзне. Шуны истә тотып эшләдем мин бу гамәлне.

Башка игелекләрне эшләргә минем кулымнан килми, көчем җиткән эшем икмәкне дәрьяга агызу булды. Ел буена дәрьяга агызган икмәкләрем өчен миңа файда кайчан килер икән дип көтә идем».

Хәлифә әйтте: «Әй Мөхәммәд! Инде менә игелекле эшеңнең файдасын таптың».

Хәлифә башмакчыга биргән алтыннарга өстәп Багдад шәһәре янындагы биш авылны бүләк итте. Ул башмакчының Багдадта балалары яши иде. Каим Биллаһ хәлифәлек иткән заманда мин хаҗ-шәрифкә барганда Багдад шәһәренең картларыннан бу хикәятне ишеттем. Алар ул башмакчының улының улларын күрсәттеләр.

Әй улым! Булдыра алган кадәр игелек эшләргә тырыш. Игелекле эшләрдән, күпме генә михнәт чиксәң дә, зыян булмас, ахыры рәхәт булыр. Яхшылык эшләүдән туктама, максатыңа ирешерсең. Күпме генә игелек эшләсәм дә, файдасын күргәнем юк әле дип әйтмә. Игелек җирдә ятмый, дигәннәр борынгылар.

Халык алдында изге гамәлләрең белән дан казан. Халык күзенә бер тапкыр яхшы күренеп, соңыннан яман сыйфатта күренмә. Ягъни бодай күрсәтеп арпа сатма. Халык алдында яхшы булып кыланып, аулакта ярамаган эшләр эшләмә. Мондый сыйфат монафикъларга, икейөзле кешеләргә генә хас.

Нинди генә эшне башкарсаң да, гаделлек белән башкарырга тырыш, залимлек белән түгел, һич онытма: гаделлегең дә, залимлегең дә үзеңә кайтыр.

Әй улым! Кешенең ике халәте була: бере – шатлыкта, бере – кайгыда. Бу халәтләреңне үзеңне дус күргән, синең белән шатлана һәм кайгыра белгән кешеңә генә белдер. Ләкин шатлыгыңны да, хәсрәтеңне дә башкаларга белдермәвең хәерлерәк. Акыл ияләре ахыры кайгы белән тәмамланган шатлыкны шатлык димәгәннәр һәм ахыры шатлык белән тәмамланган кайгыны да кайгы димәгәннәр.

Өметсезлеккә бирелмә. Тулысынча өметсезлеккә төшкән хәлдә дә өметеңне өзмә. Икенче берәүләрнең хезмәтен хөрмәт ит, аларның хәленә керә бел, аңларга өйрән. Якын туганнарыңа көчең, хәлең җиткәнчә ярдәм итәргә тырыш. Үзеңнең нәселеңдәге карт-корыларны кадерлә, хөрмәтлә. Кешеләр белән кырыс яисә кычкырып сөйләшмә, сөйләгән сүзең ишетелер-лек кенә булсын. Әгәр берәү синең белән дорфаланып, тупас итеп сөйләшсә дә, син

аңарга йомшак тел белән җавап кайтар. Ахмак кешеләргә җавап бирмә. Гарәпләрдә мондый әйтем дә бар: «Җавабүл ахмака әс-сүкүт», ягъни «ахмак өчен җавап – дәшми тору».

Рәсүл галәйһиссәлам боерган: «Әш-шәйху фи-кабиләтиһи», ягъни һәр пәйгамбәр үзенең өммәте арасында нинди хөрмәткә лаек булса, карт кеше дә үз кабиләсендә шулай хөрмәт ителер. Үз өммәте эчендә бер пәйгамбәр дөнья һәм ахирәт эшләренә кагылышлы булган мәсьәләләрне хәл иткән кебек, ул карт шәех тә үз кабиләсендәге һәртөрле мәсьәләләрне хәл итә.

Картларның гаебен күрсәң дә, күрмәмешкә салыш, син аның күзе белән кара, аның тормыш тәҗрибәсен күрә бел. Шул чагында үзең өчен күп гыйбрәтләр табарсың. Әгәр берәү начар эш эшләсә, син аңарга да гыйбрәт күзлеге аша кара, ул тегеләй, болай итте дип сөйләп йөрмә. Ягъни: «Әлхәмдүлилләһи, Аллаһ Тәгалә безне шундый хәлгә төшермәде», – дип шөкер ит.

Әй улым! Әгәр син танымаган, белмәгән кеше белән дуслаша калсаң, тиз арада аңардан аерылу ягын кара, имин булырсың. Чөнки сыналмаган, белмәгән кешене дус итсәң, төрле борчулардан, хәтәрләрдән хали булмассың. Мәсәлән, бер кеше сиңа ашау-эчүдән берәр нәрсә бирсә һәм синең күңелеңдә бу ризыкның яки эчемлекнең агуы, фәләне юкмы икән дигән шик туса – мондый ризыкның зарары гына булыр. Үзең өчен хәтәр барын сизсәң, аңардан саклану чарасын күр. Әгәр берәр кешенең сиңа карата яман нияте барлыгын сизеп алсаң, ваемсыз булма, мондый ваемсызлык үзең белә торып агу эчү белән бәрабәр булыр.

Кешенең байлыгына кызыкма, аның һөнәренә соклан. Фәлән кешенең мал-мөлкәте күп, ул – данлыклы кеше, димә. Чөнки байлыкны син дә таба аласың. Байлык белән дан казануга караганда һөнәрең һәм белемең белән шөһрәт казану яхшырак. Көнеңне, вакытыңны бушка уздырма. Моны белмәгәннән генә миңа зыян килмәс әле дип, үзеңне тынычландырма.

Әй улым! Җаһил, ялкау булма. Локман хәким әйткән: «Яхшы һөнәрле булудан да әйбәтрәк нәрсә юк, гыйлемнән дә бөегрәк төшенчә юк, ояла белүдән дә матуррак бизәк юк, әшәкелектән дә яманрак дошман юк». Шуның өчен, улым, белем үзләштерергә тырыш, бер генә сәгатеңне дә бушка уздырма. Акыллы һәм әдәпле бул.

Локман хәкимнән сорадылар: «Әдәпле булырга кемнән өйрәндең?»

Ул: «Әдәпсезләрдән өйрәндем», – дип җавап бирде. Димәк, җаһил, надан кешедән дә гыйбрәт алырга була икән. Чөнки аның күзенә, йөзенә карап, нәрсәне эшләргә ярамаганлыкны белергә мөмкин.

Искәндәр патша әйткән: «Барлык дусларымның да яхшылыкларын тоеп-сизеп яшим, әмма дошманнарымнан күбрәк мәнфәгать табам. Чөнки дусларым минем начар якларымны үземә әйтмиләр, дуслык хакына яшерәләр һәм мин үземнең гаепләремне белмичә калам. Дошманнарым исә җитешсезлекләремне йөземә бәреп әйтәләр һәм мин ул гадәтләремнән арынырга тырышам».

Әй улым! Хәлеңнән килгән чагында яхшылык эшләп калырга тырыш. Телең белән бер нәрсәне сөйләп, күңелең белән икенчене уйлама. Юкка-барга көенеп яки сөенеп йөрмә. Бу – сабыйларга гына хас сыйфат.

Кешеләрнең эшләгән эшен күрә һәм аларның файдалы яисә зарарлы якларын аера бел. Үзең белмәгән һөнәрләрне өйрәнергә омтыл. Һөнәр үзләштерергә вакытым юк, әле болай, әле тегеләй дип сәбәп эзләмә. Һөнәр өйрәнү өчен махсус вакыт билгеләнмәгән. Шуңа күрә вакытың бармы-юкмы, һөнәр үзләштер. Белем үзләштерү өчен күп тырышлык куярга кирәк. Ялкаулык, эшсезлек җаныңны һәм тәнеңне дә авыруга сабыштыра. Тырышлык белән бәдәнеңне үзеңә буйсындыра алмасаң, сау-сәламәт булырмын һәм дәрәҗәләргә ирешермен димә. Бәдәнең тик торырга күнексә, ул сиңа буйсынмас. Үз бәдәнен үзенә буйсындыра, ялкаулыгын җиңә алган кеше гыйлем, мәгърифәтне дә үзләштерер һәм бәхет-сәгадәткә дә ирешер. Белемлелек, мәгърифәтлелекнең нигезен әдәплелек, тыйнаклык, оятны белү кебек күркәм сыйфатлар тәшкил итәргә тиешле.

Үз эшеңә зыян китерерлек дәрәҗәдә оялчан булу да ярамый. Бозык эшләрдән, саран, ялганчы булудан оял, дөрес сүздән, мәгънәле эштән оялма. Шундый кешеләр дә була: алар үзләренең оялчанлыклары аркасында максатларына ирешә алмыйлар. Артык оялчанлык ризыксыз калдырыр дигән хәдис тә бар: «Әл-хәйаэ юмнигъур-ризка». Тыйнаклык – матур сыйфатларның берседер. Тыйнак кешенең иманы да нык булыр, тыйнаксыз кешенең исә иманы

да камил булмас. Иманы камил булган кеше үзенең эшләрен изге ният белән башкарыр. Тыйнаклык, оялчанлык иманлылык билгесе булганы кебек, ярлылык та шулар аркасында була. Шуңа күрә кайда тыйнак, оялчан булу тиешлеген белергә кирәк.

Әй улым! Җаһил, надан кеше белән гәп корма. Югыйсә ул үзенең наданлыгын аңламас, гаять күп белә дип хис итәр. Надан, җаһил бәндәне – кеше дип, игелекле эш кыла белмәгән галимне гыйлем иясе дип санама. Үзләренең яхшы эшләренә күрә ат казанган кешеләр белән аралаш. Андыйлар белән аралашсаң, яхшы ат казанырсың, җаһилләр, түбәнгә тәгәрәгән бәндәләр белән аралашсаң, яман атың чыгар. Әгәр сүм-сүм исемле үсемлек маена хуш исле гөл чәчкәләрен салсаң, аны сүм-сүм мае димәсләр, хуш исле гөлдән ясалган май диярләр.

Хәзрәте Рәсүлуллаһ әйткән: «Кем дә кем бер кабилә белән кырык көн буена сохбәт корса, ул үзе дә шул кабилә кешеләреннән булыр».

Әй улым! Гыйлем ияләренең үзеңне мактаганнарын ишетеп канәгатьлек кичерсәң дә, наданнарның мактавыннан качарга кирәк.

Хикәят. Бер көнне Әфләтун хәким ялгызы гына уйланып утыра иде. Шәһәр түрәләреннән берәү, килеп, аңарга сәлам бирде һәм төрле хәбәрләрне сөйләде. Сүз уңаеннан: «Әй хәким, мин фәлән кешене очраткан идем, ул сине мактады, хөрмәтләп телгә алды. Шуны сезгә җиткерәсем килгән иде», – диде. Әфләтун бу сүзләрне ишеткәч кайгыга төште, елап җибәрде. Әлеге түрә, аптыраштa калып, Әфләтуннан сорады: «Йә хәким, мин сезне рәнҗеттемме әллә? Күңелегезгә охшамаган сүзне әйткән булсам, кичерә күрегез, нигә болай кайгырасыз?»

Әфләтун хәким: «Минем кайгымның сәбәпчесе син түгел, ә теге наданның сүзләредер. Мине шыр надан мактап сөйләгән икән, димәк, мин аның күңеленә ятышлы эшне эшләгән буламын, һәм инде үзем дә шул наданнар хисабыннан булам түгелме соң? Шуңа күрә кайгырмый хәлем юк», – дип җавап бирде.

Галимнәр белән җаһилләр бер-берләренә каршылыкта булырлар. Чөнки гыйлем ияләренә хас булган сыйфатларны җаһилләр беркайчан да хупламаслар, җаһилләрнең эшен галимнәр хупламас. Менә шуңа күрә наданның мактавыннан саклануың хәерлерәк. Шуңа охшашлы тагын бер хикәят бар.

Күренекле галим Мөхәммәд Зәкәрия әр-Рази үзенең шәкертләре белән урамда барган чагында бер дивана, аның каршына килеп, берәүгә дә илтифат итмичә, йөзенә туп-туры карап көлеп җибәрә. Мөхәммәд Зәкәриягә бик уңайсыз булып китә, һәм ул барган юлыннан кире борылып өенә кайта һәм әфтимун[14] кайнатып эчә. Моны күреп, шәкертләре аңардан: «Йә хәким-остазыбыз, мондый эчемлекне элегрәк эчми идегез, ә хәзер эчтегез, моның сәбәбе нәрсәдә?» – дип сорадылар.

Мөхәммәд Зәкәрия: «Ул дивана минем йөземә карап көлде, шуның өчен эчтем. Бу көнгә кадәр аның миңа илтифат иткәне булмады. Әгәр минем битемдә берәр билге күрмәгән булса, ул миннән көләр идемени? Димәк, ул мине дә үз ишләреннән дип санады». Борынгылар болай дигәннәр: Күгәрчен белән күгәрчен, каз белән каз – Барысы да үз ишләре белән булырлар пәрваз[15]. Гарәпләрнең дә шундый ук әйтемнәре бар: «Күллү таирун мәгъә шәклиһи» – һәр кош үз җенесе белән очар.

Әй улым, игелек эшләгәннәрнең кадерен бел, синнән игелек өмет итүчеләрнең өметләрен өзмә. Бик юаш та, бик кызу канлы да булма. Бик мөлаем булсаң, таптап узарлар, бик тиз кызып китүчән яки усал булсаң, синнән качарлар. Халыкчанрак итеп әйтсәк, юаш булсаң басарлар, усал булсаң асарлар. Син боларның уртасында бул. Шул чагында дусларың да сине үз итәрләр, дошманнарың да сиңа зарар китерә алмаслар һәм үзең дә максатыңа ирешә алырсың. Иң мөһиме: сине берәү дә начар эшкә тарталмас.

Әй улым, берәүне дә начар эшкә өйрәтмә. Чөнки начарлыкка өйрәтү шул начарлыкны үзең эшләгән кебек булыр. Гайбәт сөйләмә. Гайбәтне сөйләгән яисә тыңлаган кеше зур гөнаһ эшләгән булып саналыр. Берәүне дә рәнҗетмәскә тырыш. Әгәр сине нахакка рәнҗетсәләр, усаллык белән җавап кайтарма. Шул чагында син чын егетлек күрсәткән булырсың. Шәһәр җирендә яшәсәң, яхшы кешеләр арасында яшәргә тырыш. Күршеләрең яхшы, игелекле булсалар, алар белән яшәү җиңел булыр. Яхшы күңелле, шәфкатьле, игелекле дусларыңның киңәшләрен тыңла, кабул ит. Әмма ул киңәшләрне аулактарак тыңларга кирәк. Халык арасында бирелгән киңәш колакка кермәс һәм шелтә кебек кабул ителер.

[14] *Әфтимун* (фарсы) – чормавык, кычыткан ефәге.

[15] *Пәрваз* (фарсы) – тиң.

Әй улым, бу үгет-нәсыйхәтләреңне сиңа бәян иттем, син аларны, укып, кирәк вакытында файдалана бел. Ләкин син күпне белсәң дә, беләм дип тәкәбберләнмә. Күпне белсәң дә, үзеңне надан дип сана. Әгәр наданлыктан котылам дисең икән, ул чагында: «Минем белмәгән нәрсәләрем күп икән әле», – дип әйт. Чын галим яисә күп һөнәрләрне белгән кешегә «белмим» дип әйтүдән дә зуррак һөнәр булмас. Моның шулай булуын түбәндәге хикәят мисалында да күрергә мөмкин.

Хикәят. Нәүширвән патшаның Бозурҗмиһер исемле вәзире бар иде. Бервакыт Рум иленнән илче килде. Иран патшалары гадәтенчә, Нәүширвән патша Рум илчесен тәхетенә утырып кабул итте. Илчене кабул итү мәҗлесенең рәсми өлеше тәмам булгач, дөнья хәлләре турында сүзгә күчтеләр. Нәүширвән патша, илчегә үз вәзиренең белемле булуын күрсәтәсе килеп: «Йә вәзир, синең бу дөньяда белмәгән нәрсәң юктыр, шулаймы?» – дип сорады, патшаның үз вәзиренең «беләм» дигән җавабын ишетәсе килгән иде. Әмма Бозурҗмиһер хәким: «Юк, падишаһым-солтаным, белмим», – дип җавап бирде. Нәүширвән патша вәзиренең җавабыннан уңайсыз хәлдә калды һәм бик оялды. Күңелендә вәзиренә кинә саклаган хәлдә аңардан тагын: «Һәммә нәрсәне кем белә соң?» – дип сорады.

Вәзир әйтте: «Бер кеше белә, ул – бөтен галәмгә тиң кеше. Әмма андый кешенең хәзергә анадан туганы юк». Нәүширвән патша вәзиренең бу сүзләрен камиллеккә ирешкән гыйлем иясенә лаек сүзләр дип кабул итте. Бозурҗмиһер вәзирнең акыллы җавабы Рум илчесенең күңеленә хуш килде.

Әй улым, никадәр генә укымышлы булсаң да, үзеңне тыйнак тот, миннән дә артыграк белүчеләр бардыр дип, үзеңне аз белүчеләр рәтенә куй. Сократ хәким бөек галим булса да: «Әгәр кем дә булса Сократ хәким укымышлы кеше, аны бөтен дөнья белә дип әйтсә, мин бернәрсәне дә белмим һәм белергә көчем дә җитми, дип җавап бирер идем, тик мин бу сүзне әйтмәячәкмен. Миннән соң киләчәк буын галимнәренең, Сократ хәким зур дәгъва белдергән дип, мине гаепләүләреннән куркам», – дигән.

Әй улым! Мин укымышлы кеше дип, мин-минлегеңне күрсәтмә. Барлык эшләреңне дә киңәшеп эшләргә тырыш. Киңәшеп эшләүне гаепкә санама. Әгәр киңәшергә кеше тапмасаң, башыңдагы бүрегең белән булса да киңәш, дигәннәр борынгы бабайлар.

Гадел һәм тәҗрибәле, акыллы дуслары белән киңәшмичә, үзе дигәнчә генә эшләгән кешегә соңыннан үкенергә туры киләчәк. Акыллы картларның киңәшләрен тыңласаң да яхшы булыр. Хәзрәте Рәсүл пәйгамбәр булса да, Аллаһ Тәгалә аңарга да «киңәш» дип боерды. Аллаһ Тәгалә үзенең пәйгамбәренең эшен һич киңәшсез дә дөрес итә ала иде. Әмма Ул аңарга: «Әй хәбибем, һәр эшеңне сәхабәләрең белән киңәшләшеп эшлә! Киңәш-табыш итү сездән, аны дөрес итү миннән», диде.

Әй улым, шуны исеңдә тот: ике кешенең акылы бер кешенең акылы белән тигез түгел. Ике күз белән күрү бер күз белән күрү кебек түгел. Әгәр бер табиб үзе авырып китсә, ул, үз белеменә генә таянмыйча, башка бер табибны чакырып киңәшләшер, гәрчә үзе ул табибтан белемлерәк һәм тәҗрибәлерәк булса да.

Якын кешеләреңнең сиңа йомышлары, үтенечләре булса, син аларга телең беләнме, көчең беләнме ярдәм итәргә тырыш, дошманың булса да игелегеңне кызганма. Аңарга авыр чагында ярдәм итүең ике арада булган дошманлыкны киметер.

Әй улым! Әгәр галим, зыялы кешеләр синең хәл-әхвәлеңне белергә дип килсәләр, аларга хөрмәт күрсәт, шәфкатьле бул. Шундый булсаң, үзеңне якын иткән кешеләрең сине күрергә ашкынып торырлар, алар өчен һәрвакыт мөхтәрәм кеше булырсың. Яхшы кешеләр белән мәҗлестәш булсаң, үзең дә алар рәтеннән саналырсың, андый мәҗлесләрдән качма. Зобани, саран, бозык табигатьле кешеләрнең хәлен белергә дип барәү дә килмәс, гәрчә ул бик галим булса да.

Яхшы кешеләр мәҗлесендә, никадәр генә белемле булсаң да, күп сөйләргә ярамый. Кешенең авызыннан чыккан һәрбер сүзе җәүһәргә тиң һәм хикмәтле булсын. Әгәр күпкә китсә, андый сүзнең дә хикмәте калмас, мәгънәсе дә булмас. Күпсүзле булмыйм, үземнең кадеремне җуймыйм дисәң, сүз сөйләү өчен нинди ал-шартларның булу кирәклеген өйрән.

## Сүз сөйли белүнең шартлары

Һәр кеше тәмле телле булырга, яхшы сөйләшә белергә һәм сөйләүче кешене тыңлый белергә тиеш. Әй улым, дөресен сөйләргә тырыш, туры сүзле кеше булып дан казан, ялганчы дигән яма-

натың чыкмасын. Әгәр дөрес сүз булып та, ул кеше ышанмаслык, ялганга охшаган сүз булса, аны сөйләмәвең хәерлерәк. Дөрескә охшаган ялган сүз ялганга охшаган дөрес сүздән яхшырак. Чөнки андый ялган сүз яхшы, дөрес сүз буларак кабул ителә. Кабул ителми торган дөрес сүзне сөйләүдән сакланырга кирәк.

Хикәят. Аллаһ Тәгаләнең фарызлары өстемдә бар иде. Хаҗдан башкасын үтәп килдем. Ходаем анысын да насыйп итте: хаҗга да барып кайттым. Кайтканнан соң яу чабу теләге уянды. Моңарчы да күп тапкырлар Һиндстанга яу белән барган идем. Аннан соң Рум иленә яу чабарга ниятләдем. Зур әзерлекләрне күргәннән соң Күһстаннан Рум иленә юнәлдем. Рум иленә чиктәш Гәнч исемле бер ил бар иде. Аның патшасы Әмир Шапур бин әл-Фазыл бик җитди һәм олуг патша иде. Ул зирәк акыллы, баһадир, җор телле һәм бик динле, пакь күңелле асыл зат иде. Аның башкарган эшләре дә дөрес иде. Шулай бер көнне ул, мине юлда очратып, үзенә кунакка чакырды, зурлап кунак итте. Минем хәлләремне сорашты, сораулар бирде. Ул минем җавапларымнан канәгать калды һәм мине үз дәүләтендә кунак булып калуымны үтенде. Китәргә рөхсәт сорасам да, риза булмады. Мин рөхсәтсез китәргә базмадым һәм беркадәр вакытка калырга ризалаштым, мәҗлесләрендә катнаштым. Ул миннән төрле вакыйгалар, борынгы заманнарда яшәгән патшалар тарихы һәм башка нәрсәләр турында сораша иде. Мин исә үземнең белгәннәремне сөйләргә, аңлатырга тырыша идем. Шулай бервакыт ул безнең Күһстан, Табаристан дәүләтләре турында сораша башлады, анда булган кызыклы гадәтләр, хәлләр турында сөйләвемне сорады. Мин аңарга бер кызыклы йоланы бәян иттем:

«Гургән җирендә урнашкан авылларның берсендә бер чишмә бар. Хатыннар ул чишмәгә суга барганда үзләре белән куллары буш булган тагын бер хатын-кызны ияртеп баралар. Алдан баручы бу хатын юлда очраган кортларны читкәрәк алып ташларга һәм юлны чистартып барырга тиеш. Әгәр тулы чиләкләр белән чишмәдән кайтучы хатын-кыз, ялгыш кына басып, берәр кортны үтерсә дә, чиләкләрдәге су нәҗесләнгән дип санала һәм түгеп ташлана. Ул яңадан чишмәгә барырга, чиләкләрен юганнан соң яңадан су тутырып алырга мәҗбүр була. Бу хәл берничә тапкырлар кабатланырга да мөмкин. Шул сәбәпле бер көянтә су артыннан ике хатын

баралар», – дип, мин сүземне төгәлләдем. Патшаның, хикәятне тыңлап бетергәннән соң, кашы-күзе җимерелде, йөзе караңгыланды һәм берничә көн дәвамында миңа якты чырай күрсәтмәде. Мин моның сәбәбен аңламадым.

Патшаның Дәйлеми исемле бер вәзире бар иде, җаен табып, мин аңардан бу турыда сорадым: «Патша хәзрәтләре элгәре миңа мондый мөнәсәбәттә түгел иде, хәзер исә минем белән сөйләшмәс булды, сәбәбен белмисезме?» – дидем.

Вәзир әйтте: «Патшаның сиңа хәтере калган булса кирәк. Үзе шундый камил акыллы кеше, ә үзе минем мәҗлесемдә балалар да ышанмый торган сүзләрне сөйләде. Җитди һәм галим кешегә мондый буш сүзне сөйләү бер дә килешми», – диде.

Бу сүзләрне ишеткәч, дөреслекне исбат итү өчен мин Гургәнгә бер кешене җибәрдем, кулына хат язып бирдем. Хатта Гургән галимнәренә үзем белән патша арасында булып узган вакыйганы бәян иттем һәм, сүземнең хаклыгын дәлилләр белән раслап, тиз генә җавап язып җибәрүләрен үтендем. Дүрт ай дигәндә хатыма җавап килде. Ул хатны патшага да укыттым. Ул миңа, көлемсери төшеп: «Синең кебек кешенең патша каршысында ялган сөйләмәгәнлеген дә беләидем. Ләкин дөреслеген исбатлау өчен дүрт ай вакыт кирәк булган сүзне нигә сөйләргә иде», – диде.

Әй улым, кешеләр өч төрле булган кебек, сөйли торган сүзләр дә дүрт төрле була.

Бар шундый кешеләр: үзе күп белә һәм белгәнлеген дә таный – монысы галим кеше. Икенчесе бик күпне белә, ләкин үзенең белгәнен аңламый – монысы йоклаган кеше, аны уятырга кирәк. Өченчесе үзе белми, ләкин үзенең белмәгәнлеген дә танымый, монысы җаһил кеше булыр, андый кешедән ераграк булганың яхшы.

Сөйләнә торган сүзләр дүрт төрле була, дидек: беренчеләре – белергә дә, сөйләргә дә ярамый торганнары, икенчеләре – белергә һәм сөйләргә яраганнары, өченчеләре – сөйләргә яраса да, белергә мәҗбүри булмаганнары, дүртенчеләре – белергә ярый, ләкин сөйләргә ярамый торганнары. Аларны тагын аерып аңлатырга була.

1. Белмә дә, сөйләмә дә дигәне шундый сүзләр: аны сөйләсәң, динеңә һәм дөнья эшләреңә зарар килер. Мондый сүзне сөйләүдән тыелырга кирәк. Чөнки аны ялган дип атыйлар.

2. Бел дә, сөйлә дә дигәне – кешенең диненә дә ярый, дөнья эшләре өчен дә файдалы булган сүзләр. Алары дөрес сүзләр. Бу сүзләрнең сөйләүчегә дә, тыңлаучыга да файдасы тияр.

3. Сөйләргә яраган, ләкин белергә зарури булмаган сүзләр – Хак Тәгаләнең Коръәндә боерган сүзләре. Тыштан караганда мәгънәләре төрле, әмма әйтелешләре охшаш булган сүзләрне галимнәр төрлечә тәфсир итәләр. Бу сүзләрнең чын мәгънәләрен Аллаһ Тәгаләнең үзеннән башка берәү дә белми. Шуңа күрә бу аятьләрне укып, тирән мәгънәләрен белү һич мәҗбүри түгел.

4. Белсәң ярый, ләкин сөйләргә ярамый торган сүзләр. Мәсәлән, бер түрәнең яисә якын дустыңның берәр гаебе сиңа мәгълүм була. Түрәнең гаебен ачып салсаң, ул сиңа ачу саклар, әгәр дустың булса, ул сиңа үпкәләр. Димәк, ике очракта да үз башыңа зур хәсрәт алырсың, гауга чыгуга сәбәпче булырсың. Шулай булгач, бу сүзне белсәң дә сөйләргә кирәкмәс. Сиңа бәян иткән сүзләрнең тагын ике ягы бар: яхшы ягы һәм начар ягы. Халык алдында чыгыш ясаганда сүзләрең халыкка барып җитсен дисәң, мөмкин кадәр матур һәм дөрес итеп сөйлә. Борынгылар әйткәннәр: кешенең дәрәҗәсен аның сөйләгән сүзеннән танып белергә була. Кеше сүзне танытмый, ә сөйләгән сүзләре кешене таныта.

Хәзрәте Гали Кәрәмуллаһ әйткән: «Әл-мәрьү мәхҗүбүн тәхтә лисаниһи». (Сүзенә карап, адәмнең кем икәнлеге, нинди мәртәбәгә ия булуы мәгълүм булыр).

Әй улым, сүзнең урынын белеп сөйлә, кирәксез урында сүз сөйләүдән саклан. Сөйләшкәндә кычкырып сөйләшмә, матур итеп сөйләш. Шул чакта тыңлаучыга да, үзеңнең җаныңа да рәхәт булыр. Бер сүз белән кешенең күңелен көйдереп алырга яисә сөйдерергә дә мөмкин булуын исеңнән чыгарма.

*Хикәят.* Һарун әр-Рәшид бер төш күргән. Төшендә авызындагы барлык тешләре дә коелып беткән, имеш. Иртән торып, ул бер төш юраучыны чакыртып ала һәм аңарга үзе күргән төшен сөйләп бирә, моны ничек юрарга була дип сорый.

Төш юраучы: «Әй мөэминнәрнең әмире, барлык туганнарыгыз да сездән алда үлеп бетәчәкләр, бер ялгызыгыз гына калырсыз», – диде.

Һарун әр-Рәшид төш юраучының бу сүзләрен яратмады һәм аңарга йөз камчы сугарга боерды. Сабак булсын дип, төш юраучы-

га әйтте: «Әй сөйли белмәгән надан. Мондый куркыныч һәм кайгылы сүзләрне битемә бәреп әйттең. Әгәр минем карендәшләрем үлеп бетсәләр, бу дөньяда миңа ялгыз яшәүдән ни файда калыр соң?» – дип, төш юраучыны куып чыгарды. Һарун әр-Рәшид икенче бер төш юраучыны чакыртты, ул әйтте: «Әй мөселманнарның әмире, син барлык кардәшләреңнән дә озаграк яшәрсең». Һарун әр-Рәшид күңеленә бу төш юраучының сүзләре хуш килде. Ул әйтте: «Акылның юлы бер үк, ике могъбир дә бер нәтиҗәне ясадылар, ләкин беренчесенең әйткән сүзләре белән икенчесенең әйткәне арасында зур аерма бар», – дип, икенче төш юраучыга йөз алтын бирергә боерды.

Әй улым! Сөйләгән сүзләреңнең мәгънәләрен белмичә сөйләсәң, тутый кошка охшап калырсың. Тутый кош үзе сөйли, әмма нәрсә сөйләгәнен белми. Әгәр борчулы вакытыңда синнән нәрсә булса да сорасалар, сабырлык белән җавап бир.

## *«Кәлилә вә Димнә» әсәреннән бер гыйбрәтле хикәят*[16]

### Кеше үзенең кулыннан килми торган эшкә тотынса, теләгенә ирешә алмас һәм булганын да югалтыр

Һиндстан патшасы Дабшалим браһман Байдабага әйтте: «Әй остаз, син – зур акыл иясе, белемең дә камил, миңа шундый кешенең хәлен бәян ит – кем үзенең кулыннан килмәгән эшкә алынып, аны башкарып чыга алмыйча, элеккеге һөнәрен дә югалткан?»

Хәким Байдаба әйтте: «Әй падишаһым, дөньяның таянычы! Олугълар «Ликүлли мәйданин риҗәлүн», ягъни Ходай Тәгалә һәр кешене бер эшкә ярардай итеп яраткан һәм аның күңеленә шуңа муафыйк фикерләр салып, хәерле эшенә хәерле нәтиҗәне бирә. Шулай булгач, һәркем үзенең мөмкинлекләрен белеш һәм кем булырга яратылганын тоеп, шул юлда, зур тырышлык куеп эшләргә, югары сузылмаска тиеш була. Шулай булса гына Ходай Тәгалә аның һәр эшенә теләктәшлек күрсәтер, башлаган эше уңышлы тәмамланыр, яхшы җимешен бирер.

Әгәр берәү үзенең көче җиткән, кулыннан килгән эштән йөзен чөереп, табигатенә килешмәгән һәм башкарып чыгу өчен беле-

[16] Хикәят хәзерге телгә Хөсәен Фәезханов тәрҗемәсеннән күчереп бирелә.

ме, сәләте җитенкерәмәгән кәсепне эзләсә, әлбәттә, ул теләгәненә ирешә алмас, булган һөнәрен дә югалтыр һәм зыяннан башка нәрсә тапмас. Шулай булгач, һәркем, Ходай нинди эшкә яраклы итеп яраткан булса, шуңа канәгать булып күңелен ерак чаптырмасын һәм, хыял диңгезенә кереп китеп, үзенә насыйп булган нигъмәтен кулыннан ычкындырмасын. Моны исбатлый торган дәлилләрне күпләп китерергә мөмкин. Шуларның берсе – бер яһүди заһид белән нәфесле мөсафирның кыйссасы.

Фәләстыйн йортында бик динле бер заһид бар иде. Һәрвакыт үзенең Ходаена гыйбадәттә булып һәм күңел көзгесен яман холыклардан сөртеп, нәфесен камил һәм мөкатдәс иткән иде.

Караңгы хөҗрәсе илаһи нурлар белән яктыртылган иде. Барлык көчен кешеләргә ярдәм итү һәм аларны дөрес юлга күндерү өчен сарыф итә иде. Нурлы күңелен дөньяви уйлардан пакьләп, раббани илһамлар белән балкыткан иде. Үзе шәһәрдән читтә яшәсә дә, аның кечкенә хөҗрәсе һәрвакыт юлчылар, кунаклар белән тулы була иде. Хәзинәсендә булган нигъмәте кунак сыйлау өчен өстәленә куелган була иде. Шулай бер көнне аның хөҗрәсенә бер мөсафир килеп керде. Заһид, гадәтенчә, хуш килдең, дип, ачык йөз белән аны кабул итте. Алдына бер ашны куеп, аны кунак итте. Соңыннан: «Әй сылу кунак, сез кем дигән газиз буласыз, кайлардан килдегез һәм кайларга барасыз? Зур авырлыклар чигеп, без фәкыйрьнең куышына рәхим иттегез. Безнең кебек моңлыны шатландырырга сиңа нәрсәләр сәбәпче булдылар?» – дип, аңардан хәл-әхвәлләрен сорашты.

Мөсафир әйтте:

«Әгәр бу сәфәремнең кыйссасын сөйләсәм, бик озын күренер, һәм башымнан кичкән вакыйгаларны яза калсам, ничәмә-ничә китап язылыр иде. Әгәр аерып кына сөйләсәм, сезне ялыктырырмын һәм сезнең тынычлыгыгызны качырып, башыгызны авырттырырмын дип куркам».

Заһид: «Әй газизем, әгәр кешенең күңеле гамьсезлектән керләнмәгән һәм күңел күзен ваемсызлык пәрдәсе капламаган булса, һәр кыйссадан гыйбрәт алыр, башкаларның хәлен күреп, үзе өчен нәтиҗә ясар. Шулай булгач, син дә башыңнан узганны сөйләп, дөньяга шикаятең булса, бу мәҗлестә белдер», – дигәч, мөсафир әйтте: «Әй олугъ остазым, хәзер минем торган җирем Төркестан,

әмма асыл ватаным Фәрәнгистан. Анда мин икмәк пешерүче оста кеше буларак билгеле идем. Минем анда күп заманнардан бирле таныш бер игенче дустым бар иде. Ул һәрвакыт миңа он китереп сата һәм акчам булмаган чакта да һич тә йөзен чытмас, бурычка биреп китәр иде. Гәрчә ут тирәсендә газап чиксәм дә, аның ярдәме белән эшем уңышлы гына, тапкан ризыгым көннеке-көнгә җитеп бара иде. Бервакыт ул дустым мине үз бакчасына кунакка чакырды һәм кунакчыллыкның бөтен шартларын җиренә җиткереп хөрмәтләде. Ашап-эчкәннән соң, төрлесеннән сөйләшеп утырдык. Сүз арасында ул минем шөгылем һәм аның файдасы турында да сораштырды. Мин бераз зарланыбрак: «Бу кадәр интегеп, иртәдән кичкә кадәр ут тирәсендә янып-пешеп эшләсәм дә, тапкан акчам өемнең чыгымнарын капларга җитәр-җитмәс кенә», – дидем. Ул әйтте: «Сөбханаллаһ, синең кәсебеңне бу дәрәҗәдә файдасыз дип белмәгән идем».

Мин сорадым: «Әй дустым, синең кәсебең ничегрәк соң, кереш-табышың күпме, файдасы бармы?» Ул миңа: «Минем кәсебемнең чыгымнары аз, әмма аңардан кергән табышы күп. Аз гына орлык чәчәбез дә чәчкәнебез кадәр утыз-кырык, ә кайбер елларда илле-алтмыш тапкырга артыграк табыш алабыз. Җәй көннәрендә өч ай газапланып эшләсәк тә, башка вакытларда рәхәтлектә гомер уздырабыз. Шуның өчен «алтын юлы ясау» дигәннең мәгънәсе иген игү дип әйткәннәр», – диде.

Игенчедән бу сүзләрне ишеткәч, күңелемдә төрле фикерләр туды, һәм миңа да иген игәргә кирәк дигән уй керде. Шуннан соң икмәк пешерү эшен калдырып, игенче булу хәстәрен күреп йөри башладым. Минем күршемдә бик сабыр һәм күп фикерле бер дәрвиш яши иде. Ул минем һөнәремне ташларга җыенып йөрүемне белеп, шәфкать йөзеннән бер көнне мине үз янына чакырып болай диде: «Әй күрше, күреп торам, син, үз һөнәреңне ташлап, яңа эшкә керешмәкче буласың кебек. Буш хыялларга бирелеп ялгышасың. Аллаһ хәзинәсеннән бирелгән насыйбыңа канәгать булсаң, дөньяда ризыксыз калмассың, әгәр ачкүз, нәфесле булып югары сузылсаң, булган ризыгыңнан һәм тапкан малыңнан да мәхрүм калырсың».

Мин әйттем: «Әй газиз күршем, нишлим соң, мин бу һөнәрем белән никадәр генә тырышсам да, файдасы бик аз, хәтта көч-хәл белән генә өй-җәмәгатемнең чыгымнарын капларга җитә. Игенчелекнең файдасы күп икәнен үзең дә беләсең, ә нигә дип әле син мине шелтәлисең?»

Ул: «Игенчелек кәсебе – күп хезмәт куюны сорый торган бик нәзберек эш, һәм аның күп шартлары бар. Әгәр аз гына ялкаулык күрсәтсәң, яки бер шартын үтәмәсәң, барлык куйган хезмәтең бушка китәчәк һәм кирәксез эшең аркасында хезмәтеңнең җимешеннән мәхрүм калырсың. Үз дәрәҗәсенә лаек булмаган эш белән мәшгуль булган торнага килгән бәла синең башыңа да килер», – диде.

Мин аңарга: «Ул ничек булган соң, сөйләп бир, эчтәлеген ишетеп гыйбрәт алыйм», – дидем.

Дәрвиш сөйли башлады: «Диҗлә елгасы буенда бер торна гомер сөрә һәм сазлыктан тапкан кортларны ашап көнен күрә иде. Бер көнне моның күз алдында карчыга симез генә күгәрченне аулады һәм аның итен ашап тама-гын туйдырды, калганын калдырып китте. Торна барып шул калган иттән авыз итеп караган иде, бу аның күңеленә бик хуш килде. Шул вакыт ул, аучылык яхшы һөнәр икән дип, үз-үзенә сөйләнде. Күр әле бу йомры кадәрле генә карчыганы, һәркөн нинди тәмле аш белән тамагын туйдыра. Минем зур гәүдәм, озын муеным, киң канатларым, көчле аякларым була торып та, хәшәрәтләр итен генә ашыйм, анысы да зур мәшәкатьләр белән табыла. Мин дә шул сасы хәшәрәтләрдән ваз кичәм һәм һәркөн яхшы кош итләрен генә ашап тамак туйдырачакмын», – дип торганда, бер күгәрченнең Диҗлә елгасыннан су эчәргә килгәнен күрде. Шунда ук, аны аулап тотыйм әле, дип, артыннан очты. Күгәрчен су янына төште. Ачкүз торна да аның артыннан шул җиргә атылды. Әмма ул җир баткак икән, торна озын аяклары белән балчыкка кереп батты. Чыгам дип күпме генә канатлары белән талпынса да һәм муенын ары-бире сузса да, һич файдасы булмады, сазга тирәнрәк бата барды.

Моны, гаҗәпләнеп, баштан ахырга чаклы бер гарәп күзәтеп торды. Торна сазлыкка килеп төшү белән, барып торнаны эләктерде һәм, муенына җеп тагып, ияренә асты да өенә кайтып китте. Юлда бер дусты очрап: «Әй дустым, бу ганимәт сиңа кайдан килде һәм мондый кошны коралсыз-нисез генә ничек эләктерә алдың?» – дип сорашты. Җавабында ул: «Үз һөнәрен ташлап карчыга, лачын һөнәрен сайлады һәм кош ауларга ниятләде, ләкин теләгенә ирешә алмады, үзе ауга төште», – диде.

Бу мәсәлне сөйләп бетергәч, дәрвиш миңа болай диде: «Әй күрше, бу мәсәлдән гыйбрәт алып, син дә Ходай үзеңә ачкан юлдан чыкма, һәм юк белән мавыгып әвәрә булма».

Ул дәрвишнең сүзләре никадәр дөрес булса да, минем колагыма кермәде, ихлас белән миңа әйткән нәсыйхәтләре дә минем күңелемдә кабынган ялкынымны-теләгемне һич сүндерә алмады. Мин ниятемдә нык тордым һәм иген икмәкче булдым, икмәк пешерә торган эш коралларын сатып, игенчелек өчен кирәклеләрен алдым. Тиз генә баеп китү теләге белән тәмам исереп китеп, бер елсыз игеннең өлгермәслеген дә онытып, булган акчамның бер тиенен дә калдырмыйча «җиргә салдым». Ул арада ашарга ризыгыбыз да бетеп, ачлыктан киң дөнья безгә тараеп калды һәм якты көн күзебезгә караңгы булып күренде. Мин үз-үземә әйттем: «Ялгыштың, яхшы кешеләрнең киңәшләрен тыңламадың, булыр-булмас эшкә керештең һәм, ашыгып, кулыңда булган һөнәреңне ташладың, үз кулың белән үзеңне ризыктан мәхрүм иттең». Нишлим, иске эшемне җайга салып җибәрәм дип, зур кыенлыклар белән бурычка акча таптым. Шуның белән икмәк кибетен ачып җибәрдем. Игенчелек һөнәре белән кибеттә утырып булмый, шуңа күрә икенче берәүне кибетемә сату итәргә дип утырттым. Үзем исә иген эшләре белән әле кырга йөгердем, яки кибетем эшләре артыннан базарга бардым. Шулай итеп кичләремне дә, көннәремне дә тынычсызлыкта үткәрдем. Гомер шулай уза торды. Бер көнне кибетемдәге сатучым юк булды. Тикшереп карасам, мин ышанып утырткан кешем сәүдәдән кергән табышны һәм бурычка алган акчамның яртысыннан артыгын урлап качып киткән. Җитмәсә, белер-белмәс чәчкән игенем дә уңмады, хәтта тотылган чыгымнарымның уннан бере дә кулыма кайтып кермәде. Аһ-ваһ итеп, үзем эшләгән ялгышыма үкенеп, нишләргә дә белмәдем. Гаиләмне тәрбияләргә җаен тапмадым. Ул арада бурыч иясе килеп, акчасын сорый башлады. Барлык малымны хисаплап караган идем, бурычымның уннан беренә дә җитмәслек булды. Ул да, моны сизеп, казыйга шикаять итәргә китте. Минем төрмәгә эләгәсем килмәде, шул ук сәгатьтә качып кына шәһәрдән чыктым да нишләргә дә белмичә күзем караган тарафка китеп бардым. Күпмедер вакытлар шулай каңгырып йөргәннән соң, безнең шәһәрдән килүче бер кәрванга очрап, йорт-җирем һәм бала-чагам хәлен сораштым. Алар әйттеләр: «Җәмәгатең, бала-чагаң ачлык

ачысын йотып һәм төрле мәшәкатьләр күреп, һәммәсе мохтаҗлыкта үлеп беттеләр. Калган йорт-җиреңне, өй җиһазларыңны сатып, бурыч ияләренә бүлеп бирделәр. Болар бурычларыңны капларга җитмәгәч, сине кайткач төрмәгә ябарга карар иттеләр». Мин моны ишеткәч, ватаныма кайтудан өметемне өздем, аһ-ваһ итеп далаларда йөргәннән соң, менә сезнең хөҗрәгезгә килеп җиттем. Минем баштан узганнар менә шулар...»

Хөҗрә хуҗасы, бераз елмаеп торганнан соң, бу бичараның күңелен күтәрергә теләп әйтеп куйды: «Әй газиз кунак, чыннан да, синең башыңнан күп хәсрәтләр, мәшәкатьләр узган һәм сөйләгәннәреңдә дә гыйбрәтләр бар. Әмма үткән эшкә кайгырма, киләчәктә Аллаһның рәхмәтеннән өметеңне өзмә. Хәзер син, әлхәмдүлилләһ, һөнәрләр-эшләр турында тәҗрибә туплагансың, михнәт чигүгә этәргән сәбәпләрне дә беләсең. Моннан соң, иншаллаһ, сиңа бу мәшәкатьләрнең файдасы булмый калмас, рәхәт көннәр дә килер дип, кунагын юатты, төрле сүзләр сөйләп күңелен ачты. Мөсафир да бераз юанып, дәрвиш тә өенә кунак килгәнгә куанып, араларында сүзләре күп булды. Шул рәвешчә берничә көн узды. Дәрвиш төрле телләрдә сөйләшә белә иде. Әмма үзе, Исраил нәселеннән булмаганы өчендерме, гыйбри телен бик яратып, махсус мәҗлесләрдә дуслары белән гыйбричә сөйләшә иде. Фәрәнгистанлы кунак исә, үзен рәнҗеткәннәре өчендерме, яһүдиләрне бер дә өнәми иде. Ләкин шәехнең сөйләшүе аның күңеленә дә хуш килде, үзе дә шул телне өйрәнергә карар итте: бу телне өйрәнеп, ватанына кайткач, белеме белән мактану хыяллары башын әйләндерде. Шәех белән сөйләшеп утырганда, уңаен табып, мөсафир әйтеп куйды: «Әй юлдан язганнарны хак юлга салучы, һәм бер авыз сүз белән тасма теллеләрне сакау итүче, халык алдында оста итеп нотык сөйли белү-челәр дә синең хозурыңда бер генә сүз дә әйтә алмыйлар: Фирдәүси һәм Сәгъдине никадәр генә үткен телле дисәләр дә, синең бер юл бәетеңә тиңләшә алмыйлар. Синең нотыкларың Муса таягы кебек юлдан язганнарга юл күрсәтә. Арабызда һичбер танышлык булмаса да, миңа хөрмәт күрсәттең, лаек булмасам да, яхшы сүзләрең белән күңелемне юаттың. Инде мин бичарага бу телне өйрәтсәң иде, үзең белгәннәрнең меңнән берен генә булса да миңа белдерсәң иде. Бәлки мин шул һөнәр белән замана җәфасыннан котылыр һәм соңгы сулышыма кадәр сез остазыма дога укыр идем».

Заһид әйтте: «Әй газиз кунагым, минем синең белән сөйләшеп утыруымның бер максаты бар иде, ул – сине наданлык базыннан чыгарып, мәгърифәтле итү иде. Моны мин Аллаһ ризалыгын өмет итеп эшләдем. Мондый ялынуларың миңа кирәкми. Ләкин шуны бел: фәрәнг теле белән гыйбри теле арасында зур аерма бар. Алар бер-берсенә һич охшамыйлар, сөйләшү кагыйдәләре дә бер-берсеннән бик нык аерылалар. Өйрәнәм дип тырышуың ахырда җимешсез калыр, үз ана телең дә бозылыр, һәм минем газиз вакытым да бушка киткән булыр».

Мөсафир әйтте: «Сезнең кебек олы шәхескә мәгълүмдер: безнең фәрәнг халкы бик сәләтле һәм тырыш халык, аз гына вакыт эчендә дә күп нәрсәне өйрәнә ала, хәтта һәрберсе берничә телне беләләр. Мин аларның берсе булгач, ничек бу телне өйрәнә алмыйм ди? Үземә файда китерә торган һөнәрне өйрәнмичә мөмкинме соң? Мин беләм: гыйлем өйрәнү кешене алдынгы сафка илтер. Күп телләрне белүнең файдасы зур. Синең бер аучы турындагы хикәятне ишеткәнең бармы? Шәкертләр гарәпчә бер генә сүзне белсәләр дә, файдасын күрделәр». Шәех, сөйлә әле, дигәч, мөсафир хикәятне сөйли башлады.

Хикәят. Бер шәһәрдә бер аучы егет яши иде. Һәркөн, ятьмәсен күтәреп, су буйларында йөреп балык тота иде, йә урманга барып тозак куеп, киекләр һәм кошлар тотып кайта иде. Беркөн гадәттәгечә урманда кош тотарга дип тозак корды һәм, орлык сибеп, үзе посып утырды. Күп вакыт көтеп утырганнан соң, якынга гына өч кош килеп кунды. Аучы, моны күреп, хәзер тозакка төшәләр дип торганда гына, ерактан кешеләр тавышы ишетелде. Алар якын килеп бу кошларны куркытмасыннар дип, яшеренгән урыныннан чыгып, аучы аларга каршы китте һәм ике шәкертнең бер-берсе белән кычкырып бәхәсләшеп килүләрен күрде. Тавышлары белән урманны шаулаталар. Аларга якын килеп сәлам бирде, һәм әдәп белән генә каршыларына ялварулы кыяфәттә килеп басты. Алар: «Син кем, сиңа нәрсә кирәк?» – дигәч, аучы аларга әйтте: «Әй шәкертләр, мин – бер аучы, монда тозак кордым һәм озак кына кошлар төшкәнен көттем, хәзер генә килеп төштеләр. Сездән үтенеп сорыйм, Аллаһ хакы өчен тавышланмагыз, тозагыма төшәчәк кошларга якын бармагыз».

Шәкертләр әйттеләр: «Синең безне тыярга ни хакың бар? Бу урманда йөрергәме, йөрмәскәме – һәр кешенең үз ихтыярында. Әгәр ул өч кошның икесен безгә бирер булсаң гына тавышланмабыз. Ләкин син дип кенә без бәхәсебезне туктатмыйбыз».

Аучы әйтте: «Әй шәкертләр, сезнең куйган шартыгыз мине гаҗәпкә калдырды. Минем тозагымның җепләрен мәдрәсә шәкертләре ишмәде, һәм укытучы әфәнде тозак янына бер генә данә ярманы да сипмәде. Шулай булгач, маңгай тиремне түгеп, җилкәмне авырттырып мин аулап кулыма төшергән нәрсәдә сезнең ни катнашыгыз бар? Моны хәләл дип раслау өчен шәригатьтән нинди дәлилләр табасыз?»

Алар әйттеләр: «Без гыйлемне халыкка файда китерер өчен һәм тормыш-көнкүрешләрендә аларга кирәк булачак нәрсәләрне өйрәтер өчен үзләштерәбез. Кичләрен йокламыйча һәм көндезләрен дә рәхәт тапмыйча һәрвакыт тырышабыз. Шулай булгач, Аллаһның биргән нигъмәте, үзең ашатып асрамаган кош, әгәр синең тозагыңа килеп эләксә, безгә дә өлеш чыгарга тиеш түгелмени? Гомерләре буена синең файдаңа тырышачак шәкертләрне бер көн генә булса да тамакларын туйдырмау сиңа оят түгелме?»

Араларында төрле сүзләр әйтелгәч, дөяң югалса, муллага очрамасын, аңа очраса, хәләлләп җибәрер дигән мәсәл аучының хәтеренә килде. Ягъни үтенүе файда бирмәслеген һәм сүз белән аларны җиңә алмаслыгын белде. Теләсә дә, теләмәсә дә сүзләренә күнде һәм ике кошны аларга бирмәкче булды. Кошлар эләккәнче посып утырып, ахырда аларны кулга төшерде. Вәгъдәләшкәнчә, үз көче белән аулаган ике кошны инсафсыз муллаларга биргәндә алардан сорады: «Әй әфәнделәр, әгәр сез халыкны өйрәтер өчен белем үзләштерәсез икән, һәм минем бу кадәр газап чигеп, сезгә шундый яхшы кошларны тотып биргәнем өчен рәхмәт йөзеннән минем бер соравыма җавап бирегез әле: нәрсә хакында бу кадәр кызып бәхәсләшә идегез?»

Алар, бераз көлемсерәп: «Безнең бәхәсебез мөхәннәс сүзенең мәгънәсе һәм хөнсаның мирасы хакында иде»,– диделәр.

Аучы: «Мөхәннәс ни дигән сүз?» – дип сорады.

Алар әйттеләр: «Мөхәннәс – гарәп сүзе. Кешедән кайчагында шундый бала туа: ул мөзәккәр дә булмый, мөәннәс тә булмый. Шуңа күрә аны мөхәннәс», – диләр.

Аучы шул кадәр кыйммәт бәяне түләп бу сүзнең мәгънәсен белгәч, кабатлый-кабатлый өенә кайтты һәм булачак муллалардан зарлана-зарлана бу хикәятне хатынына сөйләп бирде.

Икенче көнне иртүк су буена китте, кояш чыкканда бисмилләһи дип, ятьмәсен суга салып, бик матур бер балык тотты, аның тәне көмеш кебек ап-ак һәм мамыктай йомшак, сыртында төрле төсләр җемелди, канатлары исә кош канаты кебек ачыла, ә күзләре уттай уйный, караган кешене хәйран калдырырлык иде.

Балыкчы гомерендә мондый балыкны әләктерү түгел, күргәне яисә ишеткәне дә юк иде. Моны күреп бик сөенде һәм башына мондый уй килде: «Әгәр мин моны өемә алып кайтсам, җитсә бер көн ашарга җитәр, шуннан артыкка булмас. Әгәр моны патшага бүләк итсәм, миңа берәр яхшылык эшләми калмас», – дип, балыкны алып патша сараена юнәлде. Патша ул көнне йорт уртасындагы күлдә көймәдә йөзәргә, һәм күлдә асрала торган төрле балыкларны тамаша итәргә дип чыккан иде.

Балыкчы патша каршына килеп сәлам бирде һәм кулындагы балыкны күрсәтеп башын түбән иде. Патшаның үз гомерендә мондый матур балыкны күргәне юк иде. Балыкны бик яратып кабул итте һәм, үрчетергә дип, аны шул күлгә җибәрергә кушты, ә балыкчыга мең алтын бирергә боерды.

Патшаның бер вәзире яхшылык эшләү теләге белән булса кирәк, аның колагына пышылдап кына әйтте: «Әй падишаһым, дөнья солтаны, нигә болай юмартланасың? Мондый бүләкләр өчен меңәр алтын өләшә башласаң, хәзинәңдәге сандыкларың бик тиз бушар. Бер тиенлек балык өчен мең алтын түгел, бер алтын бирсәң дә, балыкчы нишләргә белмичә җүләрләнер. Алтынны берәмләп таратсаң да, бик тиз бетәр һәм хәзинәгә зарар килер», – диде.

Патша әйтте: «Дөрес сөйлисең, балык өчен моның кадәр бүләк бирергә ярамас, ләкин бер тапкыр әйткәч – сүзне кире кайтарып булмый».

Вәзир әйтте: «Курыкма, моның хәйләсе табылыр, сүзеңне дә үзгәртергә туры килмәс, алтыннар да хәзинәдә калыр. Син аны чакырып, бу балык мөзәккәрме йә мөәннәсме дип сора.

Әгәр мөзәккәр дисә, мөәннәсне китер, мөәннәс дисә, мөзәккәрне китер, аннан соң акчаны алырсың, дип боер. Ул вакыт балыкчы аптырашта калыр һәм кечкенә бүләккә дә риза булыр».

Патшага вәзиренең бу киңәше бик ошамаса да, балыкчыны чакырып: «Әй егет, бу балыгың мөзәккәрме, мөәннәсме?» – диде. Балыкчы зирәк иде, эшнең кая барганлыгын сизде һәм, һич тә икеләнеп тормыйча, нәкъ шәкертләрдән өйрәнгәнчә: «Солтаным, бу балык мөзәккәр дә түгел, мөәннәс тә түгел, бәлки мөхәннәс», – диде. Патша бу җавaптан канәгать калып, рәхәтләнеп көлде һәм әүвәлге бүләк өстенә тагын мең алтын бирергә боерды. Тапкыр җавабы өчен аны үзенә якын итте. Вәзиренең хәйләсен яратмады һәм аңа шелтә белдерде.

Шулай итеп, балыкчы бер генә гарәп сүзен өйрәнеп тә нинди байлыкка ия булды. Минем тырышлыгым да лаеклы бәяләнер, гыйлем үзләштергән өчен үкенергә туры килмәс», – дип, мөсафир сүзен тәмамлагач, заһид кеше аңарга әйтте: «Ярый алайса, бу кадәр ялынып сорыйсың һәм аңардан зур файда күрергә өметләнәсең икән, мин сиңа ул телне өйрәтергә тырышып карыйм һәм гыйбри теленең кагыйдәләрен мөмкин кадәр үтемлерәк итеп аңлатырмын. Ул телнең барлык нечкәлекләрен, матурлыкларын сиңа өйрәтмичә калдырмам». Мөсафир бу сүзне ишеткәч, Заһидның кулын үпте һәм аңарга күп рәхмәтләр укыды. Телне өйрәнә башлагач, ул һәрвакыт гыйбри телендә генә сөйләшергә тырышты, башка телдә бер генә сүз дә әйтмәде. Шулкадәр тырышты, көндезен ял итмәде, кичләрен йокламады. Заһид та телнең кагыйдәләрен мисаллар белән ачык итеп аңлата һәм мөсафирның күңелендә аларны мөмкин кадәр күбрәк калдырырга тырыша иде. Әмма табигать аңарга ярдәм итмәгәнгә күрә, мөсафир ул телне һич үзләштерә алмады, аның акылы, зиһене ул телнең серләренә керә алмады. Моны күреп торган заһид гыйбри[17] бер көнне аңарга болай диде: «Әй газиз кунак, син үзеңә туры килми торган бик авыр эшкә керештең. Болай интегүеңнең мәгънәсе булмас кебек күренә. Чөнки күреп торам: бу тел синең табигатеңә туры килми, шуңа күрә син аны үзләштерә алмыйсың. Шулай булгач, бу уеңнан кайт һәм кулыңнан килгән эш белән шөгыльлән. Атаң-анаң сөйләшмәгән телне өйрәнәм дип йөрүең дөрес түгел. Үзенең табигатенә ярашмаган эш белән мавыгып йөргән кешенең гомере бушка узган булып саналыр».

---

[17] *Заһид гыйбри* (гарәп) – дөнья эшләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән генә торучы яһүд кешесе.

Мөсафир әйтте: «Мин ата-бабаларым яшәгән караңгылыкта яшәргә теләмим һәм алар эшләгән хаталарны да кабатларга теләмим. Ата-бабага ияреп хак юлга кермичә калганнарны олуг Коръән дә хурлаган. Безгә кадәр дә шулай яшәгәннәр, дигән иске гадәтләрдән котылып, күзләре күргән урынга барып җиткәннәр генә теләкләренә ирешкәннәр. Шуңа күрә син ата-бабаларымны миңа гыйбрәт итеп куйма һәм алар яшәгән караңгылыкта, наданлыкта калуымны теләмә».

Заһид әйтте: «Мин дуслык һәм юлдашлык хакын гына үтим. Тырыша-тырыша сиңа бу эшнең асылын аңлатырга теләвем һәм үгет-нәсыйхәтләр бирүем дә бары тик шуның өчен генә. Син әле хәзергә фәрәңг телендә сөйләшә, фикер йөртә аласың. Күп вакыт булдыра алмаган эш белән мавыгып йөрсәң, гыйбри телен дә өйрәнә алмассың, үзеңнең ана телеңне дә онытырсың һәм ләкләк кебек йөрергә өйрәнергә тырышкан карга хәлендә калырсың».

Кунак сорады: «Ул ничек булган?»

Заһид сөйли башлады...

*Хикәят.* Бер көнне карга бер ләкләкнең бакча янында матур кыяфәт белән йөргәнен күреп бик сокланды һәм күңелендә аның йөрешен үзләштерү хыялы туды. Тора-бара ул бу хыялны тормышка ашырырга уйлады. Үзенең кәсебен калдырып, ул һәркөн, ләкләккә ияреп, аның кебек йөрергә өйрәнә башлады. Ләкин күпме генә тырышса да, ләкләкнең йөрешен үзләштерә алмады. Карганың бер адымга да үзеннән калмыйча һәм оялмыйча ияреп йөргәнен күреп, ләкләк эче пошып әйтте: «Әй бәхетең кара, күзең ала, ни өчен, оятсызланып, мин кая барсам, син шунда ияреп барасың? Минем гүзәл йөрешемә күзеңне текәп карыйсың, моңардан сиңа ни файда бар, нәрсәне уйлап болай ияреп йөрисең?»

Карга әйтте: «Әй матур йөзле, зифа буйлы, матур басып йөрүче кош! Синең йөрешеңә бик сокланам, күпме вакыттан бирле өйрәнмәкче булып артыңнан йөрим. Үз җенестәшләрем арасында мин иң зәвыклы кош булырга телим».

Ләкләк, бу сүзләрне ишеткәч, каһкаһә белән көлеп, болай диде: «Әй мескен бичара, бигрәк тә буш уйлар белән мәшгуль икәнсең, салкын тимергә сукмакчы буласың. Син кем дә мин кем. Минем гүзәл йөрешем – миңа табигать тарафыннан бирелгән йөреш. Әгәр сиңа

аны табигать бирмәгән булса, өйрәнеп кенә булмый шул. Бу файдасыз һәм мәгънәсез эшеңне туктат, барыбер теләгеңә ирешә алмассың».

Карга әйтте: «Бу эшкә керешкәнмен икән, максатыма ирешкәнче мин ул эштән туктамам. Аның нәтиҗәсе булсын өчен, күпме генә мәшәкатьләр кичәргә туры килсә дә чыдармын. Барыбер максатыма ирешермен яисә шул юлда очраган каршылык дулкыннары астында калып үләрмен», – дип, ләкләкнең сүзен колагына алмады һәм әүвәлгечә, ләкләк кая барса, артыннан ияреп йөрде. Халыктан оялмыйча, ару-талуны белмичә, көнен-төнен өйрәнәм дип ияреп йөрүен дәвам итте. Бу хәл ничәмә-ничә айларга, елларга сузылды, әмма ләкләкнең йөрешен үзләштерә алмады. Алай гына да түгел, үзенең асылындагы йөрешен дә онытты...

Бу мәсәлне шуның өчен сөйләдем, әгәр кем дә кем үзенең Ходай биргән кабилиятенә лаек булмаган эшкә керешсә, аның тырышуы файдасыз булыр...

Әлеге гыйбрәтле хикәятләр мәгърифәтче галим Хөсәен Фәезханов тәрҗемәсендә бирелә. Әлбәттә, бу тәрҗемәләр шактый ирекле. Гарәпчә шәкеле исә мондый гыйбрәтле сүзләр белән тәмамлана: «Бәйдаба философ патшага әйтте: Иң надан кеше генә кулыннан, хәленнән килмәгән эшкә ябышыр». Бу сүз бигрәк тә ил җитәкчесенә кагыла. Ил белән идарә иткәндә бигрәк тә сак, игътибарлы булырга кирәк. Үзенең дошманнарын тар-мар итәргә уйлаган ил башы бу эшкә әзерлексез керешмәсен, кулыннан эш килми торган кешеләргә үзләре лаек булмаган вазифаларны тапшырмасын. Аларга бер эштән икенче эшкә күчеп йөрергә юл куймасын. Хөкүмәт эшләрендә һәр кешене үзенә лаек булган хезмәткә билгеләү дә зур осталыкны таләп итә.

Бер әзерлеге булмаган, надан, түбән җанлы кешеләр дәрәҗәле урыннарга билгеләнсәләр һәм бу эш гадәткә әйләнсә, хөкүмәт оешмаларында тәртипсезлек көчәер, әдәп-әхлак кануннары бозылыр: эшнең рәтен белмәгән, гыйлеме дә, әзерлеге дә булмаган кешеләр белән эшне тиешенчә башкара белүчеләр арасында низаглар башланыр. Моның нәтиҗәсендә илбашына итагатьсезлек кебек ямьсез күренешләр пәйда булыр, ил эчендә тотрыксызлыкка, һәлакәткә юл ачылыр.

Үзенә лаек булган һөнәрне ташлап, хәленнән килмәгән эшкә ябышкан кешенең нинди халәттә калачагы югарыда китерелгән хикәятләрдә ачык чагылыш тапкан.

## *«Кабуснамә»дән хикәятләр*

Әй улым! Үзеңне башкалардан өстен куйма, артык усал да булма, һәр эштә уртача бул. Нинди генә эшкә керешсәң дә, түземле бул, ашык-пошык эшләмә. Сереңне үзеңнән башка берәү дә белмәсен. Әгәр сереңне кешегә әйтсәң, аны сер дип санама. Кешеләр арасында булганда берәүнең колагына сүз сөйләмә, бу килешсез эш булыр. Ул яхшы сүз булса да, читтән күзәтүчеләр өчен начар сүз булып кабул ителер. Кешеләрдә мондый сүзгә шик-шөбһә туар. Чөнки күпчелек кешеләр бер-берләреннән шикләнәләр.

Һәр сүзне кызулык күрсәтмичә генә тыңла. Нинди генә сүз булса да, синең дөньяви эшләрендә ярарлыкмы ул, түгелме, син аны игътибар белән тыңларга өйрән. Уйламыйча сүзеңне сөйләмә, һәр сүзеңне уйлап сөйлә, соңыннан үкенергә туры килмәсен. Күпне белсәң дә, аз сөйләш, азны белсәң, күп сөйләшмә. Чөнки акылсыз кеше генә күп сөйли. Акыл ияләре: «Телеңне тик тота белү – сәламәтлек билгесе», – дигәннәр. Күп кешеләр сүз аркасында авыруга сабышалар. Күп сөйләгән кешене, бик акыллы булса да, халык акылсыз дияр, әгәр акылсыз кеше дәшми генә утырса да, андый кешене акыллы дип санарлар.

Сүзеңне тыңлаучы булмаса сөйләмә. Мәсәлән, мәҗлестә берәү сөйләсә, тыңлабрак тор. Ул кеше сүзен бетергәч кенә, сүзеңне башларга мөмкин. Кеше сүзенә кушылып, аның сүзен өзмә. Адәм белән үзеңне адәмчә тот, дөньяда адәм күп, әмма чын кеше булганнары гына азрак.

Әй улым! Халкың сөйләгән сүзне тыңларга өйрән. Сиңа кадәр яшәгән һәм хәкимлек иткән патшаларның эшләреннән гыйбрәт ал, сүзләрен укы, аңла, нәтиҗә ясА. Аларның нәсыйхәтләрен тот һәм тиешле урында файдалана бел.

Борынгы хәлифәләр турындагы бер кыйссада болай язылган: «Бер көнне хәлиф Мәэмүн Һарун әр-Рәшиднең улы, Нәүширван патша каберенә баргач, аның дәхмасында[18] патшаның череп бет-

[18] *Дәхма* (ф а р с ы) – борынгы фарсыларның мәет күмү урыны (склеп).

кән тәхетен, ә тәхет өстендә туфракка әйләнгән гәүдәсен күргән. Тәхет өстендәге дәхма ишегендә алтын хәрефләр белән пәхләви телендә берничә сүз язылган. Хәлиф Мәэмүн, пәхләви телен белүчене чакыртып, бу язуны гарәпчәгә тәрҗемә иттергән. Язуда болай диелгән була:

«Тере вакытымда Ходайның барлык бәндәләре минем гаделлегемнән файда күрделәр, миңа хезмәт иткән һәр кеше минем шәфкатемне тоеп рәхәт күрде. Әмма картлык, гаҗизлек вакыты килде һәм миңа менә шул сүзләрне язудан башка чарам калмады. Кем дә кем минем каберемә килсә, бу сүзләрне укып гыйбрәт алсын, файдасын күрсен. Бу нәсыйхәтләрем исә каберемне зиярәт итүчеләргә минем рәхмәтем булып кабул ителсә иде». Нәүширван патшаның үгет-нәсыйхәтләре менә шулардай гыйбарәттер:

«Нәүширван патша әйтте:

• Көн белән төн берсе артыннан берсе килгән кебек, адәм баласы да бер халәттән икенче халәткә күчә, ягъни, шатлыктан соң кайгы килә, кайгы китеп шатлык килә, бу – табигый халәт һәм моңарга гаҗизләнергә кирәкми.

• Белемсез кеше белән дус булма, чөнки ул ни дуслыкка, ни дошманлыкка ярамас.

• Әгәр бер эшне эшләгәч, ник эшләдем икән дип үкенгәннән соң, икенче тапкыр ул эшкә керешмә.

• Үзен белемле дип санаган надан кешедән читтә бул.

• Әче булса да, дөресен сөйлә.

• Сереңне дошманың белмәсен дисәң, дустыңа сөйләмә.

• Кешенең белеме булып та, шул белемгә лаек акылы булмаса, ул белем аңарга зарар китерер.

• Әгәр кешене тормыш остазы өйрәтмәсә, аны өйрәтәм дип көчеңне дә, белемеңне дә әрәм итмә, тырышлыгың бушка гына китәр.

• Үзең турында халкыңның яхшы сөйләвен телисең икән, үзең халкың турында яхшы сүзләрне сөйлә.

• Халкың өчен тырышлыгың бушка китмәсен дисәң, халкыңның синең өчен чиккән михнәтен юкка чыгарма.

• Җиңеллек белән тормыш итүне теләсәң, үз эшеңне кулыңнан ычкындырма.

• Төрле авырлыклардан, каршылыклардан читтәрәк торырга теләсәң, бетереп булмый торган эшкә керешмә.

• Әгәр үзеңне җүләр бу диюләрен теләмәсәң, табылмый торган нәрсәне эзләмә.

• Әгәр оятка калырга теләмәсәң, үзең эшләмәгән эшне мин эшләдем димә.

• Әгәр артымда көлмәсеннәр дисәң, үз кул астыңда булган кешеләргә рәхимле була бел.

• Әгәр үзеңне кадерле итәргә теләсәң, үз халкыңның кадерен белергә өйрән.

• Халкыңның синең күрсәтмәләрең белән эшләвен теләсәң, син дә үз сүзең белән эш итәргә тиешсең.

• Үз халкыңа яхшы күреним дисәң, акылы булмаган кешегә сүзеңне ачып салма.

• Бар халыктан да югары булыйм дисәң, яхшы исемеңне, шөһрәтеңне югары күтәр.

• Әгәр халкың үзеңне яратсын дисәң, аның кайгысын кайгыртып яшә.

• Әгәр телеңнең озын булуын теләсәң, кулыңны кыска тот».

Әй улым! Нәүширван-Гадел патшаның киңәш-нәсыйхәтләре менә шулар. Бу киңәшләрне син егет вакытында ук күңелеңә салып куйсаң, картлык көнеңә кадәр борчылулардан имин булырсың.

Әй улым, егет вакытында да акылың картларныкы кебек булсын. Мин сиңа, егетләргә охшарга тырышма, димим. Егет булсаң, чын егет бул, җиңел табигатьле булма. Аристотель – хәким әйткән: «Әшшәбәбү нәүгъүн минәл-җүнүн», ягъни: егет чак ул җүләрлекнең бер төре. Ләкин син җаһил егетләрдән булма. Чөнки җаһиллектән бәла туа. Егет чагыңның кадерен бел, рәхәтен күр, ләззәт таба бел. Картайгач, аларны таба алмассың. Картайгач, әрәмгә узды яшьлегем, егет чакларым дип уфтанып, елап утырудан мәгънә булмас. Яшь булсаң да, беркайчан да үлемне исеңнән чыгарма. Әҗәл угы картларны да, яшьләрне дә аяп тормый.

Егетләрнең гадәте – картлардан көлү, чөнки алар картларны егетлеккә мохтаҗ дип уйлыйлар. Ләкин егетләр дә үзләрен зуррак, олыгайтыбрак күрсәтергә телиләр ич. Картлар үз теләкләренә ирешәләр, әмма егетләр үз теләкләренә ирешә алаларммы юкмы – монысы билгеле түгел. Егет кеше үзен башкалардан белемлерәк дип саный һәм шуның белән ул үзенең наданлыгын күрсәтә дә инде. Син, улым, андый-

лардан булма. Өлкәннәрне хөрмәтлә, алар турында яман сүз әйтмә, аларның алдында үзеңне әдәпле тот, алар белән сөйләшкәндә түбәнчелекле бул. Әгәр картлар сиңа сорау бирсәләр, ашыгып, уйламыйча гына җавап бирмә. Мондый вакытта: «Җавабын үзегез беләсез», – дип әйтсәң дә ярый. Чөнки зирәк акыллы картларның сүзен тыңлап утыру – үзе дә акыллылык билгесе.

Хикәят. Бер шәһәрдә йөзьяшәр бер карт яшәгән. Аның төсе, кыяфәте бозылган, биле бөкрәйгән иде. Бер көнне бу карт, җәя кебек бөгелеп, зур кыенлыклар белән каядыр бара иде. Урамда аны бер егет, очратып: «Әй бабай, бу җәяне кайдан сатып алдың, бәясе күпме тора, әйтсәң, мин дә сатып алыр идем», – диде. Егетнең теләге картны үртәү, аның җәя кебек сыгылып, бөкрәеп баруыннан көлү иде.

Карт әйтте: «Гомереӊ озын булса, сиңа да бу җәяне һәм таякны бушка бирерләр, сатып алуның хаҗәте булмас. Ләкин бу җәя сиңа эләкмәс шул, син аңарга лаек түгел (ягъни яшьли үләрсең)».

Егет бик оялды һәм мондый сүзләрне ник әйткәненә бик үкенде.

Картларның тормыш тәҗрибәсе белемле яшьләрнекеннән артыграк булуы шиксез. Монда мин үзенең гомерен акыл хезмәтенә багышлаган, күпне күргән картларны күздә тотам.

Әй улым! Егетлек вакытлары узганнан соң, картлык көннәреңдә егетләрдәнераграк бул. Чөнки карт кеше егетләрнең кыланышларын кабатласа, бик ямьсез күренер. Картайган көнеңдә егетлек хыяллары белән янып яшәмә, егетләр көчен өмет итмә, картлыкның үлемгә якын булуын онытма.

Кешенең гомере кояшка охшаш: егет кешенең кояшы көнчыгышта, карт кешенеке көнбатышта. Көнбатышка җиткән кояш тиз бата. Шуңа күрә карт кешегә егетләрчә кылану һич тә килешми.

Әй улым! Картларга рәхимле, шәфкатьле бул. Картлык ул бер авыру кебек. Үлемнән башка һичкем аның дәвасын белми, чөнки карт кеше үлгәнчегә кадәр картлык газабыннан котыла алмый. Кешенең, картлыктан башка нинди генә авыру белән авырса да, сәламәтләнергә өмете кала, әмма картлык авыруы көннән-көн көчәя, яхшыруга өмете кимегәннән-кими бара. Тагын бер мисал: яшь җимеш куагы чәчәк ата, җимешен бирә, әмма карт агач үзеннән-үзе корый һәм аны кисеп ташлыйлар, егетлек тә, картлык та шулар кебек.

Бер китапта шундый хикмәтле сүзләрне укыган идем: кешенең көче, куәте утыз дүрт яшькә кадәр көн саен арта бара, утыз дүрт яшьтән соң нәкъ көн уртасына җиткән кояш кебек артмый да, кимеми дә, йөрешен акрынайта бара. Кырыктан иллегәчә кеше үзендә моңарчы булмаган үзгәрешләрне тоя һәм көченең кими баруын сизә башлый. Илледән алтмышкача һәр айны кире якка үзгәреш булуын тоя. Әгәр яше алтмыштан узса, һәр сәгатьтә моңарчы үзендә булмаган борчулардан, авырулардан газап чигә башлый. Алтмыштан җитмеш яшькәчә кеше һәр атнада үзендә моңарчы булмаган үзгәрешләрне күрер. Җитмештән сиксәнгәчә көн саен кешенең җаны да, тәне дә аһ-зар дәрьясына чума, хәлсезләнә барыр... Гомернең чиге – кырык яшь. Кешенең гомере баскычка охшый: кырыгынчы баскычка менеп җиткәннән соң, югарыга юл табып булмый һәм шуннан соң кирегә, ягъни аска таба төшәргә мәҗбүр була, шул рәвешчә әүвәлге баскычка төшеп җителә.

Әй улым! Сиңа картлык ирешкәч, бер урында гына яшә. Чөнки картлыкта сәфәргә чыгу – акылсызлык ул. Ярлы хәлдә дә сәяхәткә чыкмаска кирәк, чөнки картлык – бер дошман, ярлылык – икенче дошман, диләр. Бу ике дошман белән юлга чыгу зур җаһиллек.

Гомереңне бушка уздырма, һәр эшеңнең үз тәртибе булсын. Аллаһ Тәгаләне исеңнән чыгарма. Аллаһка никадәр итагатьле булсаң, Ул кушканча яшәсәң, дөрес юлдан тайпылмасаң, тормышың да матурлыкта, бәхетле көннәрдә узар.

Әй улым, егетлек һәм картлык турындагы хикәятемне тәмамладым, минем киңәшләремне, нәсыйхәтләремне кабул итәрсең, аларны тормышыңда, эшләреңдә файдаланырсың дип өметләнәм. Аларны үз улларыңа һәм оныкларыңа тапшырып калдыруны сиңа васыять итеп калдырам.

## Үзеңне тота белү, тыйнаклык һәм ашау-эчү тәртибе турында

Кеше ике төрле була: игътибарсызы һәм игътибарлысы – яки акыл белән эш итүче, барлык эшләрне дә мәгълүм бер тәртип белән башкаручы зат. Игътибарсыз кеше вакыты туры киләме-юкмы, аны карап тормыйча, үзенчә эшләргә керешә. Әмма игътибарлы кеше бер эшне икенчесе белән бутамас. Шуңа күрә андый кешенең барлык эшләрендә дә тәртип була.

Барлык эшләрнең башында ризык тора. Ашарга гаиләң, якыннарың белән бергә утыр. Ризыгыңны ашыкмыйча гына, үзең белән бер табында утыручылар белән сөйләшә-сөйләшә аша. Әмма башыңны иебрәк утыр, табындашларыңның ризыгына карама, кеше кулындагы ризыкка карап утыру әдәпсезлек билгесе санала.

Хикәят. Бер вакыт Сахиб Исмәгыйль исемле бер кеше үзенең дуслары һәм карендәшләре белән мәҗлестә утыра иде. Араларыннан берәү кулына бер кабымлык ризык алды. Аның ризыгына бер чәч бөртеге ябышкан иде. Сахиб Исмәгыйль моны күрде һәм: «Әй фәлән туганкай, кашыгыңдагы ризыкка бер чәч ябышкан, шуны алып ташласаңчы», – диде. Ул кеше кашыгын куеп торып чыгып китте. Сахиб Исмәгыйль исә аны кире алып керергә боерды. Күпмедер вакыт узгач, кунакны кире борып алып кайттылар. Сахиб Исмәгыйль сорады: «Йә туганкай, ашыңны ашамыйча нигә чыгып киттең?» Теге кунак: «Минем ризыгымдагы чәчне күргән кешенең ашын ашап утыру дөрес түгел», – дип җавап биргәч, Сахиб Исмәгыйль бик оялды...

Әй улым! Мәҗлесеңә килгән кешеләрне озак көттермә. Кешеләр җыелып бетмәс борын табынга аш куярга кушма. Ашаган вакытыңда үзең белән генә мәшгуль бул. Кеше ашап туктагач, табындагы ризык беркадәр вакыт куелган урынында калсын, аннан соң гына җыеп алырга ярый.

Игътибарлы кешеләр дә ике төрле булалар: бәгъзеләре табактагы ризыкны беренче булып үзенә ала да аннан соң гына башкаларга тәкъдим итә; икенчеләре исә иң әүвәл ризыкны башкаларга тәкъдим итә һәм аннары гына үзенә ала. Беренчесе сәясәтчеләргә хас гадәт, әмма икенчесе юмарт һәм киң күңелле кешеләр гадәтедер.

Бер-бер артлы төрле ризыкларны китертеп, аларны ашыгып кире җыярга кушма. Чөнки берәүләр бирелгән ризыкны тиз ашасалар да, икенчеләре әкрен ашыйлар, алар барысы да бертигез ашап туйсыннар. Әгәр синең каршыңда затлы ризыклар булып, башкаларның алдында булмаса, ул ризыкларны бүтәннәргә дә тәкъдим итү ярашлы булыр.

Табын янында кашларыңны җыерып, сөмсерең коелып утырма: аш хуҗасының ризыгын уңган, уңмаган яисә ашының тозлы-тозсызлыгын тикшермә. Табында ризыкны тәнкыйтьләү бер дә килешми.

Әй улым! Ашау тәртибен белдең, ә хәзер шәраб эчү тәртибен дә бел. Чөнки аның да үз урыны, тәртибе, кагыйдәсе бар.

## Шәраб эчү турында

Эчү турында нәрсә әйтим икән соң? Чөнки харамны эчү үзе харам нәрсә ич. Аның акылга да, тәнгә дә зыяны бик зур. Шәрабны эчмәсәң, Аллаһ Тәгалә синнән разый булыр, халык синең исемеңне олылап телгә алыр. Үзең дә дивана кебек тилереп йөрмәссең, малың-мөлкәтең дә тузмас. Әгәр минем сүзләремне кабул итсәң, сөекле улым булырсың.

Әмма син – яшь егет. Белеп торам: яшьтәшләрең эчерми торып тынычланмаслар. Шуңа күрә яман дуслар белән бергә утыруга караганда ялгызың гына утыруың хәерлерәк. Әгәр шәраб эчәргә уйласаң, тәүбә итәргә кирәклеген дә онытма. Шәрабны белмичә эчсәң, ул сиңа зыян китерер, белебрәк эчсәң, агуга каршы торыр, монысы хакыйкать. Ризык та шулай: чамасын белмичә ашасаң, ул да авыруга сабыштыра.

Яшьлек шуклыгы белән шәраб эчсәң, ашаганнан соң ук эчмә. Гомумән, ашаган ризыгың сеңгәнче нинди дә булса эчемлекне эчү ашказанына зур зыян китерә. Эчемлекне ашап туйганнан соң ике-өч сәгать узгач кына эчәргә ярый. Шул вакытта гына ашаган ризыгың тәнеңә, җаныңа көч бирер. Сиңа шунысы да мәгълүм булсын: ашказаны өч сәгать дәвамында ашаган ризыкны сеңдерә һәм бавырга илтеп җиткерә, бавыр аны кешенең барлык әгъзаларына бүлә, әгәр нәрсәдер артык булса, аны эчәккә уздырып җибәрә. Сигез сәгатьтән соң ашказаны бушап кала, әгәр ашказаны шундый көчле булмаса, ул ашказаны түгел, ә кабак корсак була.

Әй улым! Шәраб эчсәң, кичен эч. Халык сине сәрхүш хәлендә күрмәсен, гаебең халык күзенә күренмәсен. Өлкән яшьтәгеләр каршысында сәрхүш булып утыру да зур гаепкә саналыр.

Әй улым! Сәрхүш булганчы эчүнең ике төрле зарары бар: берсе тилелек, икенчесе авыру-хәстәлек. Чөнки эчкән кеше исерә дә махмырлый. Әгәр кеше йә диванага, йә авыруга сабыша икән, аңа эчәргә дә кирәкми.

Әй улым! Белеп торам, син мин китергән дәлилләргә карап кына шәраб эчүдән бөтенләй ваз кичмәссең. Әгәр эчәргә туры килсә, зинһар, улым, чамасыз эчүне гадәт итеп алма.

*Шәраб турында Гомәр разый Аллаһу ганьһүнең сүзләре.* Гомәр разый Аллаһу ганьһүнең улы атасыннан мондый сүзләрне ишетүен бәян итә: «Пәйгамбәр галәйһиссәлам бер көнне мөнбәргә чыгып әйткән: «Әй кешеләр, шәрабның харамлыгы турында аять инде. Ул биш нәрсәдән – йөземнән, хөрмәдән, балдан, бодайдан һәм арпадан ясала. Акылны китәрә торган эчемлекне шәраб диләр». (Хадис. Ал-Жомиъ ас-Сахих 3. – Тошкент, 1995. – 205 б).

## Кунак чакыру турында

Әй улым, чит-ят кешеләрне һәркөнне кунакка чакырма. Чөнки көн саен кунакны лаеклы итеп сыйлау мөмкин түгел. Иң элек үзең өчен шуны ачыкла: айга ничә тапкыр кунакны өеңдә кабул итә аласың, шуннан чыгып эш ит. Әгәр өч тапкыр кунак сыйлау мөмкинчелегең булса, ул чагында бер тапкыр кунак чакыр һәм шул мәҗлескә өч тапкырлык сыеңны куй. Шулай эшләсәң, табының мул һәм көнчеләрнең дә теле кыска булыр.

Кунакларың бусагаңнан атлап керүгә, син аларны якты йөзең, яхшы сүзең белән каршы ал. Чөнки тәмле тел татлы ризыктан да артыграк. Әгәр җиләк-җимеш вакыты булса, табынга утырганчы кунакларыңны җиләк-җимеш белән сыйла. Алар белән бераз әңгәмә корып утырганнан соң, кайнар ашларыңны чыгар. Әгәр кунаклар: «Безгә болары да җиткән, бик канәгать, безнең белән бергә утырып кына тор әле», – дисәләр, «Минем сезне хөрмәтлисем, сыйлыйсым килә», – дип әйтү ярашлы булыр. Әгәр тагын да кабатлап: «Безнең белән утыр», – дип әйтсәләр, ул чагында алар белән сөйләшеп утыр.

Кунакларыңа: «Әй фәлән туган, ашап утырыгыз, бер дә ашамадыгыз ич, мин сезгә бу юлы зур сыйлар әзерли алмадым», – дип үтенмә һәм: «Аллаһ насыйп итсә, киләсе табынымны яхшырак әзерләрмен»,– димә. Боларны абруйлы кешеләр түгел, ә бәлки гавам халкы һәм елга бер тапкыр да кунак чакыра алмаган сәүдәгәрләр генә әйтә. Мондый сүзләрне ишеткәч, кунак кеше уңайсыз хәлдә кала, ашаудан туктый һәм тамагы туяр-туймас торып китәргә мәҗбүр була.

Әгәр гөнаһлы булмыйм дисәң, мәгънәсез, тәртипсез эшләрне эшләмә. Минем киңәшләремне тот, кунак хакын хакла һәм моны лаеклы итеп башкаруны зарури бурычың итеп сана.

Әй улым! Кунакларыңа караңгы чырай күрсәтмә, ачык йөзле бул. Үзең күп ашама һәм күп эчмә. Сәбәпсезгә кычкырып көлеп утырма, чөнки урынсызга көлеп утыру да – диваналык билгеседер, һәм ул төрле күңелсезлекләрне китереп чыгарырга мөмкин. Әй улым, үзең яхшы белмәгән кешенең өенә кунак булып барма, дәрәҗәң төшәр һәм очраклы гына танышкан, ахмак, надан кешене кунак итеп өеңә чакырма. Табыныңнан ризыгыңны ашап та соңыннан гаебеңне сөйләп, яманлап йөргән кунакның хакын хаклау кирәкмәс. Үзең кунакка барганда да ач карын белән яисә бик туйган килеш тә барырга ярамый. Кунак табынында ашамыйча утыру килешмәс, күп ашасаң, башкаларның күзенә ямьсез булып күренерсең.

Кунак өендә үзеңә лаеклы урынга утыр. Ул синең бик яхшы танышың булса да, мин монда үземне өемдәге кебек хис итәм, теге ризыкны бирегәрәк, монысын тегендәрәк куй, дип өйрәткәләп утырма. Кунак табыныннан нәрсәне булса да алып кесәңә салма, бу – зур оятлы эш. Кунакка барганнан соң эчеп исерү кешене рисвайлыкка калдыра. Исерткеч шәрабны эчкән кеше дивана хәленә килә, ул каты итеп кулларын чәбәкли һәм көлә, яисә тиктомалдан елый башлый, бер үк сүзне кабат-кабат сөйли. Әгәр сиңа чарасызлыктан берәр чокыр шәрабны эчәргә туры килсә дә, өеңә кайтып кергәнче исереккә әйләнмә, кешелек кыяфәтеңне бозма.

Үз кул астыңда булган кешеләрне рәнҗетмә, гауга чыгарма, синең мондый начар гадәтләрең булмасын!

## Шаяру, уен-көлке сөйләү турында

Әй улым! Зинһар кешеләр белән сөйләшкәндә сүзеңне уен-көлкегә борма. Гарәпләрнең акыл ияләреннән берәү: «Шаяру – усаллыкның башы булыр», – дип әйтеп калдырган (әл-Мәзәхү мүкаддимәтүш-ширри). Дөрес, уен-көлке гаеп түгел, әмма аның да чамасы бар. Мөхәммәд пәйгамбәр дә кайчагында мәзәк сөйләп күңелләрне күтәрә торган булган. Моны түбәндәге риваять тә раслый.

Хәзрәте Гайшәнең өендә бер карчык яшәгән. Бер көнне бу карчык: «Йә Рәсүлүллаһ, Аллаһ Тәгалә мине оҗмахка кертсен өчен син миңа шәфәгатьче бул», – дигән. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйткән: «Иннәл-гаҗизә лә тәдхулүл-җәннәтә» (карчыклар җәннәткә кермәсләр). Бичара карчык, бу сүзләрне ишеткәч, бик борчылды, елады. Пәйгамбәр галәйһиссәлам, елмаеп: «Әй карчык, кайгырма да, елама да, чөнки мин дөресен әйттем. Җәннәттә карт-корылар булмаслар. Ахирәткә мөселман булып күчкән барлык кешеләр дә җәннәткә яшәреп керерләр», – диде. Пәйгамбәрнең әйткән сүзләре карчыкның күңеленә дә хуш килде.

Әй улым! Дошманыңның гаебен дөрес булган тәкъдирдә дә сөйләп йөрмә, чөнки бу сүзләрне ул дошманлык белән генә сөйли диярләр. Кычкырышкан вакытта да фәлән-төгән дип усал сүзләр әйтмә. Дошманың яман сүз әйтсә дә, син мөмкин кадәр сабыр булырга тырыш, аңарга яхшы сүз белән җавап бир.

Әй улым! Барлык эшләреңне дә акыл үлчәвенә салып башкарырга өйрән, шул чагында үзең сәламәт булырсың һәм халык арасында йөзең якты булыр.

## Мунчаның файдасы һәм зыяны турында

Әй улым, шуны бел: мунчага кергәндә тук карынга кермә, зур зыян күрерсең. Мөхәммәд Зийад: «Кеше тук карынга мунчага кереп үлми калса, бу бик гаҗәп хәл булыр», – дигән. Борынгылар исә мунча керүне дөньяда булган рәхәтлекләрнең яртысын татып карауга тиңләгәннәр. Ләкин һәркөн мунча керергә ярамый. Атнага бер тапкыр керсәң, шул җитә. Югыйсә мунчаның сихәте зәхмәткә әверелә. Мунчага еш кергән кешенең сеңерләре йомшара, кул-аяклары калтырый башлый, хәлсезләнә һәм буыннары чыгу куркынычы туа. Көн саен мунча керү кешенең холкы бозылуга да китерә. Әгәр дүрт-биш көнгә бер тапкыр мунча керелсә, алай да ярый, файдасы булмый калмас.

Җәен яисә кышын мунчага кергәч, бик эссе һәм бик салкын да булмаган, уртача һавалы бер бүлмәдә бераз гына утырып торырга кирәк. Шуннан соң эссе бүлмәгә дә керергә ярый. Эсседә тәнеңә, буыннарыңа рәхәтлек килгәннән соң уртача һавалы бүлмәгә чыгып, хәл алып утыру яхшы, ә соңыннан юынырга һәм коенырга да

була. Мунчада озак утыру да зарарлы. Бик салкын яисә бик кайнар суны өстеңә коярга ярамый, исәнлеккә зыян килер. Мунчада суның уртача җылылыкта булуы яхшы. Әгәр мунчада кеше аз булса, бу мунча керүченең бәхетенә булыр. Чөнки акыл ияләре, мунча буш булса – бәхет елмайган була, дигәннәр.

Мунчадан чыкканда юеш чәч белән урамга чыгарга ярамый, чәчне һәм тәнне яхшылап сөлге белән корытырга кирәк. Тирләүдән тәмам туктаганнан соң гына чиста киемнәрне кияргә һәм мунчадан чыгарга мөмкин. Шул чакта гына тәнгә сихәтлек, күңелгә хушлык киләчәк.

Мунчада су эчү дә бик зарарлы, ул сары су авыруына сәбәпче булыр. Бик каты сусаган чакта бер-ике генә йотым су эчәргә ярый. Мунчага күп ашап керергә ярамаган кебек, ач килеш керергә дә ярамый, монысы бәдәндә корылыкны тудыруга сәбәпче була. Ашаганнан соң бер-ике сәгать узгач кына мунчага керергә ярый.

Румлыларда бер гадәт бар: алар мунчадан соң аерым бер бүлмәдә бераз ятып йоклап алалар һәм шуннан соң гына өйләренә кайтып китәләр. Ләкин бу гадәт башка халыкларда юк, шуңа күрә аны мәҗбүри дип әйтеп булмый.

## Йоклауның файдасы һәм зарары турында

Йокыны кече үлем дигәннәр борынгылар. Шуңа күрәдер, бәлки, үлгән кешене «йоклаган кеше кебек» дип әйткәннәрдер. Аларның икесенең дә дөнья эшендә гамьнәре юк. Әмма беренчесе үле – аның җаны юк, ә икенчесе җанлы, ләкин үлек кебек. Димәк, йокы бәндәне бер халәттән икенче халәткә күчерә. Күп йоклау зыянлы булган кебек, йокысызлык та зарар китерә. Әгәр кеше өч тәүлек дәвамында йокламаса, аның үлеп китүе мөмкин. Бар эшнең дә үз тәртибе, чамасы бар. Акыл ияләре әйткәннәр: «Бер тәүлектә 24 сәгать бар. Шуның өчтән икесендә кеше уяу, ягъни эш белән мәшгуль булырга тиеш, бер өлешен йоклап уздырырга, әгъзаларга ял бирергә тиеш».

Җаһил, ялкау кешеләр исә тәүлекнең 16 сәгатен йоклап уздырырлар, ә калган 8 сәгатен уяу булырлар. Хак Тәгалә төнне адәм балалары, эшләп арыгач, йоклап рәхәт тапсыннар өчен яраткан. Хак Тәгалә хикмәтсез нәрсәне бар итмәгәндер.

Әй улым! Көндезен йоклаудан сакланырга кирәк. Әгәр бик теләсәң, бераз гына ятып торырга ярый. Йокы бит ул төн белән бәйле: әгәр кеше көндез йокласа, ул төнне көн иткән кебек булыр. Әмма бик эссе илләрдә, мәсәлән, гарәп илләрендә, җәйнең бик эссе көннәрендә көндезен салкынча урында сөйләшеп утыру яисә бераз йоклап, ял итеп алу гадәте бар. Әмма бу гадәтне үтәү һәр кешегә зарури түгел. Гомереңнең күбрәк өлешен уяулыкта уздыруың яхшырак. Чөнки без, вакыты җиткәч, бетмәс-төкәнмәс йокыга (ягъни үлем йокысына) талачакбыз.

Әй улым, кояш чыкканчы йокыдан торырга гадәтлән. Кояш офыкка күтәрелгәнче йоклаган кешенең ризыгы мул булмас. Тиешле вакытта йокыңнан торып, Хак Тәгалә кушкан гамәлне башкар (ягъни: тиешле булган намазыңны укы, гыйбадәт кыл мәгънәсендә), шуннан соң башка эшләреңне эшләргә кереш.

## Мал-мөлкәт туплау турында

Әй улым! Хәләл мал табарга тырыш. Ләкин, мал артыннан куып, гадел булмаган, хәвефле эшкә алынма. Хәвефсезлек белән табылган хәләл малның гына бәрәкәте, савабы булыр. Харам юл белән табылган мал кулыңнан китәр, әмма бәласе калыр.

Кулыңа кергән малны саклап тота бел, кирәксезгә туздырма. Чөнки малны саклап тоту аны табуга караганда кыенрак. Күп кешеләр малны таба белсәләр дә, саклый белмиләр. Әгәр кирәк эш өчен малыңны сарыф итсәң һәм аның урынын тутырмасаң, Карун хәзинәсе дә җитмәс. Мал-мөлкәтең бик күп булган тәкъдирдә дә чыгымнарың керемнәреңнән артмасын, чамасын югалтма. Малым һәрвакыт булачак дип тынычланып калма, тырышлыгыңны киметмә. Малың үзеңә никадәр генә кадерле булса да, дусларыңнан кызганма. Чөнки тапкан мал-мөлкәтеңне гүреңә алып китә алмыйсың. Тагын шуны да онытма, улым: чыгымнарың кереме ңнән бераз гына кимрәк булуы яхшырак.

Синең яхшы эшең булса, аны беркайчан да кулыңнан ычкындырма, мохтаҗлыкка калма. Чөнки эшсез һәм малсыз калган кешенең кадере калмый. Булган малыңны кадерләп тота бел, әрәм-шәрәм итеп бетермә. Кулыңа аз гына мал керсә дә, моның файдасы аз дип әйтмә, аны сакларга тырыш. Аз нәрсәне сакларга

өйрәнмәгән кеше күпне саклый белмәс. Берәр дустың яки мөселман кардәшең үзенең малын сиңа ышанып, әманәт итеп тапшырса, ул малны үзеңнекеннән дә артыграк игътибар белән сакла. Моның өчен Аллаһ Тәгалә синең малыңны да саклар һәм үзең дә халык арасында әманәткә турылыклы кеше булып танылырсың.

Әй улым, ялкау һәм пошмас булма. Болар – хәерчелеккә илтүче сыйфатлар. Мәшәкатьсез, җиңел эшнең файдасы да аз була, мәшәкатьле эшнең генә файдасы күп булыр.

Кешегә бурычка акча бирмә, бигрәк тә дусларыңа. Чөнки дустың үзе белеп тиешле вакытында бурычын кайтармас һәм сиңа кабат сорарга туры килер. Сорасаң, арагызда дуслык киселер. Дустыңа биргән малыңны үземнеке димә, кайтарып биргәнче сабыр ит. Югыйсә дуслыкка зарар килер. Дусны дошман итү бик җиңел – монысы җаһилләр эше. Кулыңнан килгән игелегеңне кызганма, кеше малына кызыкма. Халык арасында үзеңне ышанычлы, әманәткә турылыклы, игелекле кеше дип мактасыннар.

## Өйләнү турында

Әй улым, өйләнгәннән соң хатыныңны хөрмәт ит. Иң кадерле нәрсәңне дә хатыныңнан, балаңнан кызганма. Өйләнергә теләсәң, яхшы тәрбия күреп үскән кызны хатынлыкка ал, аңардан мал таләп итмә. Булачак хатының бик матур булмасын, югыйсә аны башкалар да сөярләр. Хатынның кыска теллесен, саф табигатьлесен, иренә дус булырга теләгәнен, йорт эшләрен алып бара белгәнен сайла. Үзеңнән югарырак дәрәҗәле, баерак гаиләдән булган хатынны алма.

Искәндәр патшадан сорадылар: «Ни өчен Иран патшасы Дарийның кызын алмыйсың? Бу җиһанда аның гүзәллегенә тиңнәр табылмас...»

Искәндәр патша әйтте: «Бу зур гаеп эш булыр иде. Чөнки дөньядагы халыкларны, илләрне җиңгән кешегә үзенең хатынына буйсынып яшәү бер дә килешмәс иде».

Хатының бик яшь булмасын: буйга җиткән, ата-анасының хуҗалыкта башкарган эшләрен күреп үскән булсын. Син аңарга беркайчан да усаллыгыңны күрсәтмә, көнләшмә һәм кулыңда булган малыңны аңардан кызганма. Аңарга яхшы мөнәсәбәттә бул,

аны һәрвакыт ихтирам ит. Хатыныңа шундый мөнәсәбәттә булсаң, ул сине ата-анасыннан да артыграк хөрмәтләр һәм синең аңардан да дусрак, якынрак кешең булмас. Әгәр син аны җәберләсәң, хурласаң, ул сиңа дошманыңнан да усалрак булыр. Чит-ят дошманнан сакланырга була, әмма хатының дошман булса, аңардан сакланып бетү бик кыен булыр.

Хатынлы булгач, улың да булыр, аны ничек тәрбияләрсең икән?

## Ир баланы тәрбияләү турында

Әй улым! Әгәр синең улың туса, иң элек аңарга яхшы исем куш. Чөнки атаның баласы алдындагы беренче бурычы – баласына матур исем кушу. Икенчесе – вакыты җиткәч ир-баланы сөннәткә утырту һәм бу вакыйга уңаеннан бәйрәм мәҗлесе уздыру. Аннан соң баланы Коръән укырга өйрәтә башларга кирәк. Үсеп җиткәнче ул аны дөрес һәм матур итеп укырга өйрәнсен, башка фәннәрне һәм һөнәрләрне дә үзләштерсен – атта йөрергә дә, суда йөзәргә дә өйрәнсен, хәрби һөнәрләрне дә белсен.

Әй улым! Улыңа төрле һөнәрләрне өйрәтергә тырыш, дөнья көткәндә аларның файдасы тими калмас. Балаңа әдәп һәм һөнәрләрне өйрәтүне аңарга калдыра торган мирас дип бел. Шәмсүл-Мәгъали әйткән: «Мән ләм йүъәддәбәһү вәлидәһү әддәбәһү әлләйлү вәннәһәру». (Әгәр баланы ата-анасы тәрбияли алмаса, ул төн белән көн карамагында калачак.)

Әй улым, аталык бурычыңны үтә, чөнки бала дөньяга килгәндә үзен ниләр көтәчәген белми. Аллаһ Тәгаләгә баланың язмышы туганда ук мәгълүм була: ул ничек язган булса, аның язмышы да шулай булачак. Ләкин син үзеңнең аталык бурычыңны тулысынча үтәргә тиешсең. Дөньяның төрле михнәтләре, җәфалары җитәрлек. Аларны җиңәргә өйрәтү – синең иң беренче бурычларыңнандыр. Кирәк чакта йомшаклык белән, кирәк чагында, таләпчәнлек итеп, улыңны әдәпле булырга өйрәт. Зур байлыгы булган патша балаларына да белемле, һөнәрле булу зарур.

Хикәят. Гүштасп исемле патша малыннан-мөлкәтеннән мәхрүм калды. Аның үз тәхетен югалтуы турындагы хикәят бик озын. Шуңа күрә аны тулысынча сөйләп бетерү мөмкин түгел. Бу патша, ватаныннан аерылып, Рум иленең Кустанта исемле шәһәренә

килде. Аның кесәсендә бер тиен акчасы, кулында һөнәре дә юк иде. Яшь чагында ул атасының сараенда тимерчеләрнең эшләгәнен күргәне бар иде һәм үзенең дә аларга ярдәм иткәләгән чаклары булды. Ул шул чагын исенә төшерде һәм тимерче алачыгына барды. Тимерче аны үзенә ярдәмче итеп эшкә алды. Шулай итеп ул ризыклы булды. Күпмедер вакыт узганнан соң, ул үзенең ватанына кайта алды һәм яңадан тәхеткә утырды. Тәхеткә утырган көнендә үк: «Барлык аксөякләр, байлар үз балаларына һөнәр өйрәтергә бурычлы һәм бу эшне гаепкә санамасыннар», – дип фәрман чыгарды. Чөнки шундый вакытлар була: байлык та, батырлык та, юлдашларның күплеге дә файда итми, әмма берәр һөнәрне белсәң, бу һөнәр ризык табарга ярдәм итә. Патшаның бу фәрманыннан соң илдәге барлык түрәләр һәм аларның балалары арасында берәр төрле һөнәрне үзләштермәгән кеше калмады.

Әй улым, инде ир балаңны ничек тәрбияләргә кирәклеген белдең, кыз балаңны тәрбияләү тәртибен дә өйрән. Кызың үсә төшкәч, аны укытучы кулына тапшыр. Кызың балигъльıкка ирешкәч, аны үз динеңдәге кешегә кияүгә бир, аңарга шәфкатьле, мәрхәмәтле бул. Чөнки кыз баланы «атаның әсире» дигәннәр. Ир бала атасыз булса да үзенә эш табар, тормышын җайлый алыр. Кыз бала исә алай түгел. Нәрсәгә генә ия булсаң да, иң беренче булып кызыңа ярдәмеңне күрсәт. Кызыңны өйләнмәгән, буйдак кешегә иргә бир. Ир күрмәгән кыз белән өйләнмәгән егетнең бер-берсенә булган мәхәббәтләре ныграк була.

*Хикәят.* Гомәр хәлифә заманында бер патшаның Шәһребану исемле бик матур кызы бар иде. Ислам гаскәре Иранның Мәдәин шәһәрен алганнан соң, патша шәһәрдән качып китә, ләкин аны, тотып алып, Гарәбстандагы Мәдинә шәһәренә әсирлеккә озаталар. Хәзрәте Гомәр патша кызы Шәһребануны сатарга боерык бирә. Гали разый Аллаһу ганьһү исә Мөхәммәд пәйгамбәрнең мондый сүзләрен искә төшереп: «Калән-нәбийү галәйһиссәлам ләйсәл-бийгъу гъалә әбнәъил-мүлүк» (Пәйгамбәр галәйһис-сәлам әйткән: «Патшаларның балаларын сатарга ярамый»), – дигән. Хәзрәте Галинең бу искәрмәсеннән соң, Шәһребануны кияүгә бирергә карар итәләр. Бу җаваплы эшне Салман Фарисигә йөклиләр. Шәһребануга да сине кияүгә бирәчәкләр дип белгертәләр. Ул исә: «Миңа ир буласы кешене күрсәтсеннәр, үзем күрмичә ризалыгымны бир-

мәячәкмен. Мин аны тәрәзәдән генә булса да күрергә тиешмен», – дип җавап бирә. Аның теләгенә каршы килмиләр һәм Салман Фариси: «Бу фәлән кеше, монысы фәлән кеше» дип, тәрәзә каршыннан кияү булырга дәгъвалаучыларны уздыра. Шәһребану игътибарсыз гына утыра бирде. Хәзрәте Гомәрне күргәч: «Бу кем?» – дип сорады. Салман Фариси: «Бу хәлифә Гомәр разый Аллаһу ганьһү», – диде.

Шәһребану: «Бик мәһабәт кеше икән, әмма карт күренә», – диде. Аңардан соң хәзрәте Гали узды... Шәһребану аны күргәч: «Бу бик олугъ һәм миңа лаек кеше икән, ләкин аның хәләл җефете хәзрәте Фатыйма икән, әгәр аңарга көндәш булсам, күзенә дә күренә алмамын», – диде. Гали хәзрәтнең улы Хәсәнне дә күрсәттеләр. Шәһребану әйтте: «Бу кеше дә миңа лаек, әмма аның хатыннары күп дип ишеттем». Аннан соң Хөсәен узды. Аның да кем икәнлеген белгәч, Шәһребану сорап куйды: «Хөсәеннең өйләнгәне бармы?» Салман Фариси: «Аның өйләнгәне юк, ул – егет кеше», – дип җавап бирде.

Шәһребану әйтте: «Минем ирем шул булсын. Ир күрмәгән кыз хатын күрмәгән егеткә иргә чыгарга тиеш. Мин дә ир күргән кыз түгел, димәк, без бер-беребезгә лаек, мин Хөсәенгә чыгарга риза», – диде.

Әй улым, кызыңны матур кешегә кияүгә бир, караңгы чырайлы, ямьсез, килбәтсез кешегә иргә бирмә. Чөнки кызың аны яратмас һәм үзеңнең дә, киявеңнең дә яманаты чыгар. Киявеңнең йөзе ак, сүзе дә, намусы да пакь, хуҗалыкны алып барырлык кеше булсын. Ләкин аның байлыгы да, дәрәҗәсе дә синекеннән түбәнрәк булуы кирәк, ул синең белән горурланырлык булсын. Шул чагында кызыңа да аның белән матур итеп гомер кичерү мөмкин булыр.

## *Хәдисләр*

***Гыйлем үзләштерү турында.*** Кулыңнан килсә, форсат тисә, галим бул, әгәр монысы насыйп булмаса, гыйлем эстәүче бул, бу да мияссәр булмаса, мәҗлесләрдә гыйлем тыңла, бу да булмаса, гыйлемне дус күр. Гыйлемне-фәнне дошман күрергә ярамый.

***Хатынынның хакы турында.*** Габдулла ибне Әмер ибне әл-Гас сөйләгәннәрдән: «Рәсүлүллаһ әйтте: «Йә Габдулла, син көн-

дезен ураза тотасың, төннәрен гыйбадәттә уздырасың икән». Мин исә: «Әйе шул, йә Рәсүлүллаһ», – дидем.

Рәсүлүллаһ миңа әйтте: «Син алай эшләмә, уразаңны да тот, авыз да ач, төннәрен гыйбадәттә дә бул, йокла да. Боларның барысын да үз вакытында башкар. Чөнки тәнеңнең дә, күзеңнең дә, хатыныңның да синдә хакы бар!» – диде.

***Ирләрнең саны кимер, хатын-кызларның саны ишәер.*** Әбү Муса риваять итә: «Рәсүлүллаһ салаллаһу галәйһиссәлам: «Син әле ирләрнең саны кимеп, хатын-кызларның ишәеп китүен һәм бер ир артыннан кырык хатын-кызның йөргән вакытны күрерсең», – диде.

Әнәс разый Аллаһу ганьһү риваять итте: «Мин сезгә үзем Рәсүлүллаһтан ишеткән бер хәдисне әйтәсем килә, миннән башка аны берәү дә сезгә ирештерә алмас. Мин аның болай әйткәнен ишеттем: «Кыямәтнең якынаюын күрсәтүче билгеләрнең берсе шул булыр: ислам диненә игътибар кимер, җаһиллек көчәер, зиначылык артыр һәм ир-атларның саны кимер, хатын-кызларның күбәер, хәтта илле хатын-кызга бер генә ир-ат туры килә торган булыр».

***Ризыкны уң кул белән ашау турында.*** Гомәр ибне Әбү Сәламә риваять итә: «Шулай бервакыт мин Рәсүлүллаһ салаллаһу галәйһиссәлам итәгендә утырган чагымда табынга ризык белән тулы табакны чыгарып куйдылар. Мин ризыкларны табакның әле бер кырыеннан, әле икенче кырыеннан ала башладым. Рәсүлүллаһ миңа: «Әй бала, Аллаһ Тәгаләнең исемен әйтеп, уң кулың белән үз алдыңнан гына алып аша», – диде. Ягъни Аллаһ Тәгаләнең исемен әйтү белән кеше үз алдындагы ризыктан шайтанны куып җибәрә. Ризыкны тегеннән-моннан сузылып ашау исә – әдәпсезлек, ачкүзлелек билгесе ул. Болай ашау синең белән бер табында утыручыларның күңелләрен рәнҗетә, табынның ямен боза. Ризыкны уң кул белән алып ашау – чын мөселман кешесенең күркәм гадәтедер.

***Ризыкка хөрмәтле булу турында.*** Күренекле галим Исмәгыйль әл-Бохари җыеп туплаган хәдисләр китабында Аллаһ Тәгаләнең ризык турындагы мондый сүзләре китерелә: «Аллаһ Тәгалә: «Без сезгә ризык итеп биргән пакь нигъмәтләрне ашагыз! Маңгай тирегезне түгеп тапкан нигъмәтләрдән сәдака

өләшегез, яхшы эшләрне эшләгез. Мин – сез эшләгән эшләрнең барысын да күреп, белеп торучы», – диде.

***Кыямәт көне турындагы риваять.*** Әбү Һүрәйра разый Аллаһу ганьһү риваять итте: «Рәсүлүллаһ салаллаһу галәйһисссәлам бер көнне кешеләр белән сөйләшеп утырганда, аның янына бер ят кеше килеп: «Әй Аллаһның Рәсүле, иман нәрсә ул?» – дип сорады. Рәсүлүллаһ аңарга: «Иман Аллаһка, аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә, Аллаһ белән кыямәт көнендә йөзгә-йөз очрашуга, тәкъдиргә, ахирәт көнендә яңадан терелүгә ышану», – дип җавап бирде.

Әлеге ят кеше яңадан: «Әй Аллаһның Рәсүле, ислам нәрсә ул?» – диде. Җәнабе Рәсүлүллаһ аңарга: «Ислам – ул сезнең Аллаһка гыйбадәт кылуыгыз, аңарга тиңдәшне эзләмәвегез, намаз укуыгыз, фарыз булган зәкятны бирүегез һәм рамазан аенда ураза тотуыгыз», – диде.

Ят кеше тагын: «Әй Аллаһның Рәсүле, ихсан нәрсәдер?» – диде.

Җәнабе Рәсүлүллаһ: «Ихсан – ул Раббыгызны үзегез күреп торган кебек аңарга гыйбадәт кылуыгыз, гәрчә сез аны күрмәсәгез дә, ул сезне һәрвакыт күреп, күзәтеп тора», – диде.

Ят кеше тагын сорау бирде: «Әй Аллаһның Рәсүле, кыямәт көн кайчан булачак?» – диде.

Җәнабе Рәсүлүллаһ: «Бу турыда мин сорау бирүчедән белемлерәк түгел. Ләкин сезгә кыямәтнең билгеләре турында әйтеп бирә алам: хатын кеше анасының сүзен тыңламый, ә бәлки киресен эшли торган баланы дөньяга тудырса – бу кыямәтнең якынлашуын күрсәтүче билге булыр. Әгәр ялангач кешеләр илгә баш булсалар, монысы да шундый билгеләрдән булыр. Биш нәрсәнең вакытын бары Аллаһ Тәгалә үзе генә беләдер, алар: кыямәтнең кайчан булачагы, кайчан яңгыр явачагы, ана карынындагы баланың кем булачагы, иртәгә кемнең һәм кайсы урында нинди ризыгы булачагы, кемнең кайда һәм нинди үлем белән үләчәге». Бу сүзләрне ишеткәч, баягы ят кеше чыгып китте. Җәнабе Рәсүлүллаһ аны тиз генә кире борырга боерды, әмма кешеләр, аның артыннан тышка чыккач, беркемне дә күрмәделәр. Җәнабе Рәсүлүллаһ: «Бу хәзрәте Җәбраил галәйһиссәлам иде, кешеләргә диннәрен өйрәтү өчен килгән», – диде.

***Коръәннең бербөтен булып тупланауы турында.*** Зәйд ибне Сабит разый Аллаһу ганьһү әйтте: «Ямома сугышыннан соң Әбү Бәкер Ситдыйк разый Аллаһу ганьһү мине бер кеше аркылы үзенә чакыртып алды. Мин барып кергәндә аның янында Гомәр ибнел-Хаттаб разый Аллаһу ганьһү утыра иде. Шунда Әбү Бәкер миңа: «Минем яныма Гомәр килеп, Ямома сугышында Коръән укый белүчеләрнең күпчелеге һәлак булды. Башка сугышларда да карийлар болай кырылсалар, Коръәнне яттан белүчеләр калмас дип куркам. Шуңа күрә Коръәнне бербөтен итеп тупларга әмер бирүегезне теләр идем», – диде.

Мин Гомәргә: «Рәсүлүллаһ салаллаһу галәйһиссәлам үзе эшләмәгәнне мин ничек башкара алырмын икән?» – дидем. Хәзрәте Гомәр: «Аллаһ хакы өчен дип әйтәм, бу бик хәерле һәм мөбарәк эш булыр», – диде.

Хәзрәте Гомәр миңа менә шулай кабат-кабат әйтә килде һәм Аллаһ Тәгалә минем күңелемә бу эшне башкарырга кирәклеген ирештерде. Мин үзем дә моның гаять мөһим һәм яхшы эш булачагына инандым. Өстәвенә Әбү Бәкер миңа: «Син – акыллы һәм яшь кеше, без синең беркайчан да начарлык эшләгәнеңне күргәнебез булмады. Моның өстәвенә син җәнабе Рәсүлүллаһка иңдерелгән вәхиләрне язып ала идең. Шулай булгач, Коръәнне бербөтен итеп туплауны синә үз өстеңә алырга кирәк», – диде. Аллаһ белән ант итеп әйтәм, әгәр миңа бер тауны икенче урынга күчерергә кушсалар, ул эш миңа Коръәнне бербөтен итеп туплауга караганда җиңелрәк булыр иде! Мин аларга: «Рәсүлүллаһ салаллаһу галәйһиссәлам башкармаган эшне ничек эшләрбез соң?» – дидем. Ниһаять, мин бу эшкә керештем, шома ташларга, хөрмә яфракларына язылган Коръән аятьләрен һәм кешеләрдән сорашып аятьләрне язып алу, аларны бергә туплау эшен башладым. «Тәүбә» сүрәсенең ахырын: «Әй бәндәләр, сезгә үз арагызда булган, сезнең кайгы-хәсрәт чигүегезне күреп борчылган, сезнең хак дин юлына басмавыгызны күреп көенүче һәм барлык мөселманнарга да мәрхәмәтле, миһербанлы бер пәйгамбәр килде. Һаман да йөзләрен чөерсәләр, ул чагында аларга әйтегез: «Миңа Аллаһның үзе җитәр, башка бернинди дә илаһи көч юк! Ул гына бардыр һәм Ул бердәнбер. Мин аңарга ышандым, Ул – күк тәхетенең хуҗасыдыр!» – дигән аятьләрне Әбү Хузәймәдән язып алдым. Аңардан башка кешедән мин бу аятьләрнең барлыгы турында ишетмәдем

һәм очратмадым. Сүрәләр язылган төргәкләр[19] Әбү Бәкер Ситдыйкның кулында сакланды. Аның вафатыннан соң бу төргәкләр – Гомәр разый Аллаһу ганьһүдә, ул үлгәннән соң, Хафса бинти Гомәр кулында калды».

***«Әл-галякъ» сүрәсенең иңдерелүе турында.*** Пәйгамбәр галәйһиссәламның хатыны Гайшә разый Аллаһу ганьһә риваять итте: «Рәсүлүллаһ салаллаһу галәйһиссәламгә беренче булып иңдерелгән нәрсә – рас (чын) төшләр иде. Җәнабе Рәсүлүллаһ таң шәфәгы калыкканда нурга төрелгән төшләрне генә күрә иде. Аннан соң ул ялгыз калып җитди уйлар дәрьясына чумып утыруны муафыйк күрә башлады. Хира тавындагы мәгарәгә барып, берничә кич рәттән гыйбадәт белән мәшгуль булды. Гыйбадәтләреннән соң гаиләсенә кайтып, Хәдичә анабыздан азык-төлек алып, тагын мәгарәгә килә иде.

Һәм, ниһаять, бу бөек затка хакыйкать иреште. Бер көнне җәнабе Рәсүллүллаһ Хира тавындагы мәгарәдә утырган вакытта бер фәрештә килеп: «Укыгыз!» – диде. Рәсүлүллаһ салаллаһу галәйһиссәлам: «Мин укый белмим», – диде. «Шул чагында, – диде җәнабе Рәсүлүллаһ, – фәрештә мине шундый каты итеп кысты, минем сулыш алырга хәлем калмады. Ул мине бераз гына җибәрә төшеп тагын: «Укыгыз!» – диде. Мин: «Укый белмим», – дидем. Ул мине өченче тапкыр кысканда мин тәмам хәлсезләнгән идем. Соңыннан фәрештә, мине иркенәйтә төшеп, болай диде: «Әй Мөхәммәд, барлык җан ияләрен бар иткән Аллаһыгыз исеме белән укыгыз! Ул адәм баласын кан төереннән яратты. Укыгыз, Аллаһыгыз – инсаниятне каләм белән язарга өйрәткән зат. Ул зат адәм баласына белмәгән нәрсәләрен өйрәтте».

Рәсүлүллаһ салаллаһу галәйһиссәлам бу вакыйгадан куркып дер-дер калтыраган хәлдә өйләренә кайтып җитте һәм, Хәдичә анабызның янына килеп: «Мине берәр нәрсә белән урагыз», – диде. Җәнабе Рәсүлүллаһны куркуы басылганчы урап куйдылар. Соңыннан ул Хәдичә анабызга: «Миңа бер-бер нәрсә булмагае дип, үз-үземнән куркып калдым», – дип, үзе белән булып узган вакыйганы сөйләп бирде. Хәдичә анабыз исә: «Ходай хакы өчен дип әйтәм, сезгә һич тә куркырга түгел, ә киресенчә, шат һәм канәгать булу кирәк. Аллаһ Тәгалә сезне авыр хәлгә куймас. Чөнки сез

[19] Коръән аятьләре язылган «сухуф», ягъни төргәкләр.

карендәшләрегезнең мәнфәгатен кайгыртасыз, дөресен сөйлисез, икенче берәүләрне авыр хәлләреннән котылырга ярдәм күрсәтәсез, ачыкканнарны туйдырасыз, изгелек юлында үзегезне аямыйсыз», – диде. Шуннан соң ул җәнабе Рәсүлуллаһны агаларының улы Вәрака ибн Нәүфәлнең янына алып барды. Вәрака җаһилият заманында насраи диненә күчкән була. Ул гарәпчә хат язу тәртибен дә яхшы өйрәнгән. Аллаһ Тәгалә кушканча, ул Инҗилне гарәпчәгә әйләндереп яза иде. Үзе бик карт һәм күзләре дә авырта иде. Хәдичә анабыз аңарга: «Әй мөхтәрәм кардәшебез, ир туганыгызның улы сөйләгәннәренә колак салыгыз!» – диде. Вәрака: «Йә кардәшем, ниләрне күрдең, миңа нәрсәләр сөйләргә телисең, рәхим ит, сөйлә, мин тыңлыйм», – диде. Җәнабе Рәсүлуллаһ үзе күргән нәрсәләр турында барысын да сөйләп бирде. Вәрака аңарга: «Бу – хәзрәте Җәбраил, ул Мусага да вәхи белән җибәрелгән фәрештәдер», – диде. Җәнабе Рәсүлуллаһ аңардан: «Кавемем мине куып чыгармасмы соң?» – дип сорады. Вәрака: «Әйе, шулай булачак. Әмма моңарчы берәү дә сез китергән нәрсә белән килмәде, әгәр килгән булса, аны да кыйнаган булырлар иде. Әгәр мин сез яшәгән көннәрдә үз көчемдә булсам, һичшиксез, сезгә ярдәм иткән булыр идем!» – диде. Күп тә үтмәде, Вәрака вафат булды. Моңардан соң Рәсүлуллаһка беркадәр вакыт вәхи килми торды. Пәйгамбәр галәйһиссәлам борчуга төште».

***Җаббар бин Габдуллаһ сөйләгәннәрдән.*** «Рәсүлуллаһ салаллаһу галәйһиссәлам вәхинең иңә башлавы турында болай дигән иде: «Бервакытны юлда барганда миңа күктән бер тавыш ишетелде. Югарыга карасам, баш өстемдә бер фәрештә, ягъни Хира тавының мәгарәсендә каршыма килгән фәрештә, күк белән җир арасында тәхеттә утыра. Моны күреп куркуга төштем һәм тиз генә өйгә кайттым да: «Мине берәр нәрсә белән урагыз», – дидем. Мине урадылар, бераз тынычлана төштем. Шул чагында миңа Аллаһ Тәгалә: «Әй уралып ятучы бәндәм, торыгыз, кавемегезгә белдерегез, Раббыгызны олылагыз, киемегезне пакьләгез һәм пычраклыктан ерак торыгыз!» – дигән аятьләрне иңдерде.

***Каберләрне зиярәт итегез, бу сезгә ахирәтне искә төшерер.*** Каберләрне зиярәт итүнең төп сәбәбе ахирәтне искә төшерү икәнлеге бу хәдистә ачык күренә. Хәзрәте Госман кабер янына барып басу белән елый башлый иде. Бер вакытны аңардан: «Оҗмах белән

тәмугны искә төшергән вакытыгызда еламасагыз да, кабер янына килгәч елыйсыз, моның сәбәбе нәрсә?» – дип сорадылар.

Хәзрәте Госман: «Рәсүлүллаһтан ахирәт сәфәренең иң әүвәлге мәнзиле[20] – кабер. Әгәр кабердә яхшы булса, аннан соңгысы да яхшы булыр, әгәр кабердәге эшләр куркыныч булса, аннан соңгылары бигрәк тә яман булыр дип ишеттем. Шул сүз хәтеремә төшү сәбәпле елыйм», – дип җавап биргән иде.

Каберләрне зиярәт итү[21] – саваплы эш. Зиярәт иткән вакытта мәетләр рухына дога кылу тиешле. Рәсүлүллаһ һәм сәхабәләре[22]*, кабергә баргач, мәетләр рухына догалар укыйлар иде. Әмма үлеләрдән ярдәм сорап зиярәткә бару дөрес түгел. Ислам дине, шәригать кануннары моны тыя. Шуңа күрә изгеләр, әүлиялар каберләренә табыну максаты белән ерак җирләргә баруның кирәге юк. Гыйбрәт алу һәм ахирәтне искә төшерү өчен зиярәт кылырлык каберләр һәр шәһәрдә, һәр авылда була. Рәсүлүллаһ хәзрәтләре гомере буена үзенең өммәтен ширектән һәм төрле хорафат, уйдырмалардан саклап калу[23] юлында булды.

Пакь тормыш итүче бабаларыбыз юк ителгәннән соң, чит-ят диннәрнең гореф-гадәтләре һәм раһбанилыклары[24] арабызга үтеп кергәннән соң, мөселманнар кабер белән мөбтәля булдылар[25]. Үзләрен әүлия дип уйлаган кешеләрнең каберләрен мәлҗәэ[26] кылдылар. Каберләр инде олугъ бер кәсеп базары булды. Ислам рухыннан гафил калган бичаралар, кәрван-кәрван булып, вәлиләр каберләренә баралар, кабер ияләреннән максатларына ирешү өчен ярдәм итүләрен сорыйлар.

***Каберләр хөрмәтләп, карап тотылырга тиешле.*** Ләкин аларны истимдад урыны итү һәм ул җирләргә барып тезләнү, сәҗдә кылу, кул ку-шырып оеп утырулар дөрес түгел. Моны һәрбер мөселман белергә, белгәннәр белмәгәннәргә белдерергә бурычлы.

---

[20] *Мәнзил* (г а р ә п) – йорт.

[21] *Каберләрне зиярәт итү* (г а р ә п) – каберләргә бару.

[22] *Сәхабәләр* (г а р ә п) – көрәштәшләр.

[23] *Өммәтен ширектән саклау* (гарәп) – мөселманнарны Аллаһка тиңдәш эзләүдән саклау.

[24] *Раһбанилык* (г а р ә п) – монахлык.

[25] *Мөбтәля булу* (г а р ә п) – авырып китү, начар гадәт белән мавыгып китү.

[26] *Мәлҗәэ* (г а р ә п) – табыну урыны.

Рәсүлүллаһ үзе дә каберләргә бара иде. Үз анасының каберенә зиярәт иткәндә бик тәэсирләнеп елый, янында булганнарны да елата иде. Каберләргә зиярәт вакытында аның: «Әссәләмү галәйкүм дәру каумин мүэминнийнә, вә иннә иншә Аллаһ бикүм ләхикун», – дип укыганы риваять ителә. (Тынычлык ирешсен сезгә – мөэминнәрнең йортына; Аллаһның насыйбы белән без дә сезгә кушылырбыз).

Каберләргә бару турында хатыннар ирләр белән бер хөкемдәме, түгелме? Бу турыда галимнәр арасында төрле карашлар бар. Рәсүлүллаһның хәзрәте Гайшәгә каберләрне зиярәт иткән вакытта уку өчен дога өйрәтүе һәм хәзрәте Фатыйманың һәр җомгада хәзрәте Хәмзәнең каберенә баруы һәм ахирәтне искә төшерүе – боларның барысы да зиярәтнең хатыннар өчен дә дөрес булуын күрсәтүче дәлилләрдер.

## *Татарча Коръән тәфсирләреннән кыйссалар*

***«Әл-Гыймран» сүрәсенең иңдерелүе турында.*** Рәсүл галәйһиссәлам: «Әл-Гыймран» сүрәсен укыган кешене Ходай Тәгалә сират күпереннән җиңел генә үткәрер, әгәр кем дә кем бу сүрәне җиде тапкыр укып чыкса, аның өстендә булган бурычлары җиңеләер», – дип аңлата торган булган.

«Әл-Гыймран» сүрәсенең баштагы сиксән аяте иңдерелүгә «вәфдү Нәҗран» вакыйгасы сәбәпче булган. Нәҗран җиреннән бер төркем нәсаралар Мәдинә шәһәренә килгәннәр иде. Аларның теләкләре Рәсүл галәйһиссәлам хәзрәтләре белән Гайса галәйһиссәлам турында бәхәс кору иде. Рәсүл галәйһиссәлам аларны ислам диненә керергә өндәде. Нәҗранлылар әйттеләр: «Безнең үз динебез – хак һәм дөрес дин». Рәсүл галәйһиссәлам җавап итеп аларга болай диде: «Сез Ходайның улы бар дип әйтәсез һәм тәрегә табынасыз, мондый эшләрегез сезне хак диннән чыгара түгелме соң?»

Нәсаралар әйттеләр: «Без Гайсаны Ходайның улы дип әйтәбез һәм бу сүзебез дөрестер. Әгәр Гайса Ходайның улы түгел икән, ул чагында аның атасы кем була соң?»

Рәсүл галәйһиссәлам әйтте: «Гайсаны сез үзегез вафат булды дисез, шулай булгач, ул ничек Ходай булсын? Үзегез үк икърар кыласыз: Гайса башка адәмнәр кебек үк кеше сурәтендә, ашый, эчә,

йоклый, уяна һәм кешеләргә хас булган башка ихтыяҗлары да бар иде дисез. Ходай Тәгалә боларның барысыннан да пакь һәм өстен тора! Шулай булгач, Гайса ничек Ходайның улы булсын? Барлык галәмнәрнең хуҗасы – Ходай Тәгалә! Ул гына идарә итүче һәм ризык бирүче. Гайса һичбер нәрсәгә хуҗа түгел. Ходай Тәгалә – булган нәрсәләрнең барысын да белеп, күзәтеп торучы. Ходай Тәгалә белдермәсә, Гайса бернәрсәне дә белә алмый. Димәк, аның Ходайның улы булуы һич мөмкин түгел».

Нәсара галимнәре, Рәсүл галәйһиссәламнән бу сүзләрне ишеткәч, аңарга җавап бирә алмыйча өнсез булып калдылар, хәзрәтнең мәҗлесеннән торып чыгып киттеләр. Шуннан соң сүрәнең баштагы сиксән аяте иңде.

Бу аятьләр – нәсара галимнәренең бәхәс-дәгъвалары – Гайса галәйһиссәламнең Аллаһ тарафыннан җибәрелгән булуы һәм Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлеге турында иде. Шуның өчен Хак Тәгалә сүрәнең башында Ходайның бердәнбер булуы, аның мәңге терелеге турында бәян иткәннән соң, Мөхәммәд галәйһиссәламнең хак пәйгамбәр булуы исбатлана: «Нәззәлә галәйкәл-китәбә бил-хәкъ» (Ходай Тәгалә сиңа Корьәнне хаклык белән иңдерде). (Тәсһийлул-Бәйан фи тәрҗемәтил-Корьән: 1, 118 – 119 б.)

***Хәзрәте Мәрьямнең тууы турында риваять.*** Хәзрәте Мәрьямнең атасы Гыймран Сөләйман пәйгамбәр нәселеннән булган бер изге кеше иде, Хәнна исемле хатыны бар иде. Хәннаның кыз туганы Зәкәрия галәйһиссәламнең хатыны иде. Бер көнне Хәнна Бәйтүл-Мәкъдискә килде. Анда дин юлында хезмәт итүчеләрне күреп бик яратты, әгәр Ходай Тәгалә миңа бер ир бала бирсә, шушы Бәйтүл-Мәкъдискә алып килер идем, дип, күңеленнән уйлап куйды. Күп тә үтми, Хәнна балага узды, карынымдагы баламны Ходай Тәгалә юлында хезмәт итүче итеп мөхәррәр кылдым, дип, нәзер әйтте.

Элеккеге халыкларда шундый бер гадәт булган: атасы яки анасы улыбыз Ходай Тәгалә юлында хезмәт итәр, дип нәзер әйткәннәр. Андый бала ата-ана хезмәтеннән азат ителгән һәм мәчетләрдә Ходай Тәгаләгә гыйбадәт кылу белән генә мәшгуль булган. Мондый тәртиптә нәзер ителгән баланы «мөхәррәр», ягъни «хезмәттән азат ителгән» дип атаганнар. Гыймран хатыны Хәнна үзенең карынын-

дагы баласын мөхәррәр итеп Бәйтүл-Мәкъдискә китерермен, дип нәзер әйтте. Әмма аның карынындагы баласы кыз бала – хәзрәте Мәрьям иде. Хәнна үзе ир бала булыр дип көткән иде. Кыз бала тугач, бик кайгырды: «Илаһи, мин бу баламны синең юлыңда хезмәт итүче булыр дип нәзер атаган идем, инде мин нишлим, кыз баланы дөньяга китердем», – дип, Раббысыннан ярдәм сорап ялварды. Ходай Тәгалә, аңарга мәрхәмәт итеп, ир бала урынына кыз баласын кабул итте. (Т.Б. 1, 130–131 б.)

***Әхәд сугышы кыйссасы.*** Һиҗрәтнең өченче елында, шәүвәл аеның җиденче көнендә Әбү Суфьян гарәп мөшрикләре кабиләләреннән өч мең атлы һәм җәяүле гаскәр белән, сугышка дип, Мәккәдән Мәдинә шәһәренә юл тоттылар. Мәдинәгә якын булган Әхәд тавы тирәсенә төшеп, сугышка әзерләнеп тордылар. Рәсүл салаллаһу галәйһиссәлам, бу хәбәрне ишеткәч, Мәдинәдән читкә чыкмыйча, ә бәлки шәһәрдә калып сугышуны мәгъкульрәк күрде. Бу турыда, сәхабәләрне чакырып, киңәш-табыш корды. Сәхабәләрнең бәгъзеләре, әүвәл хәзрәтнең фикерен мөнасиб күреп: «Шәһәрдән чыкмыйча гына сугышуыбыз яхшырак булыр», – диделәр. Бәдер сугышында катнаша алмаган пәһлеваннар исә шәһәрдән читкә чыгып сугышырга теләделәр. Гакыйбәт[27] пәйгамбәребез галәйһиссәлам шәһәрдән чыгарга карар итеп, мөһаҗирләр һәм әнсарлылардан булган сәхабәләрдән бер мең кеше белән, коралланып, дошманга каршы торырга дип, Мәдинәдән чыктылар. Юлда Габдуллаһ бин Әбү Мөнафикъ мөнафикълардан өч йөз кеше белән: «Без ни өчен үзебезне һәм бала-чагаларыбызны үтертергә тиеш?» – дип, сугышка бармыйча кире кайтып киттеләр. Әнсарлылардан Гомәр бин Хәрзәҗ аларның артларыннан җитеп: «Пәйгамбәрне ташлап кая барасыз, Ходайдан курыкмыйсызмы, болай эшләмәгез», – дип, күп үгетләп тә карады, ләкин мөнафикълар аны тыңламадылар: «Әгәр бу сугышны хак һәм тиешле дип белсәк, сезгә иярер идек, ләкин, безнең уебызча, бу сугыш – куркыныч һәм кирәксез сугыш. Шулай булгач, без ни өчен үзебезне һәлакәткә салыйк?» – диделәр.

Әнсарлылардан хәзрәҗ кабиләсеннән бәну Сүлмә һәм ус кабиләсеннән бәнүл-Харис җәмәгатьләре һәм Габдуллаһ бин Әбигә ияреп юлдан кире борылып кайтып китмәкче булганнар иде. Хак сөбханә вә Тәгалә аларның күңелләрен ныгытты һәм алар әүвәлге

[27] *Гакыйбәт* (г а р ә п) – нәтиҗәсе соңыннан.

фикерләреннән кире кайттылар. Рәсүл салаллаһу галәйһиссәлам хәзрәтләре калган җиде йөз кеше белән Әхәд тавы янында дошманга каршы тору өчен сафка тезелделәр, аларның арткы тарафында Әхәд тавы һәм каршыларында Мәдинә шәһәре иде. Рәсүл хәзрәтләре Әхәд тавы арасыннан чыга торган юлга илле укчы егетне каравылга куйды: «Бу урыннан китәргә ярамый», – дип, аларны бик нык кисәтте.

Һәр ике тараф гаскәре, кара-каршы сафка тезелеп басканнан соң, сугышырга керештеләр. Корәйшлеләр гаскәренең сугыш тәртибен белүче галимнәре берсе артыннан берсе һәлак булдылар. Мөшрикләр дә җиңелеп кача башладылар. Мөселманнар дошман гаскәре торган урынга килеп җитү белән, аларның барлык булган нәрсәләрен, малларын җыярга тотындылар. Тау арасыннан чыга торган юлны сакларга куелган укчы егетләр дә, малга кызыгып, пәйгамбәр галәйһиссәлам боерыгын боздылар, урыннарын калдырып киттеләр. Башлыклары аларга: «Китмәгез!» – дип, никадәр генә ялынса да, укчы егетләр аны тыңламадылар. Шул вакытта мөшрикләр юлның ачыклыгын күреп качып китә алдылар, Габдуллаһны һәм аның белән бергә калган юлдашларын шәһид иттеләр. Мал җыю белә н мәшгуль булган мөселманнарга мөшрикләр искәртмәстән яңадан һөҗүм оештырдылар. Моның нәтиҗәсендә ислам гаскәре качарга мәҗбүр ителде. Имам Хәмзә һәм сәхабәләрдән җитмеш кеше шәһид булдылар, мөселманнарга зур кайгы килде... (Т.Б., 1, 159 – 160 б.)

***Кәгъбәтуллаһның ачкычы турында.*** Мәккәне фәтех иткән көндә Рәсүл салаллаһу галәйһиссәлам хәзрәтләре Кәгъбәтуллаһның ачкычын бирүләрен таләп итте. Кәгъбәтуллаһның ачкычы корәйш кабиләсенең олыларыннан булган бәну Талха кулында саклана иде. Талханың улы Госман, ачкычны анасыннан алып, Рәсүл галәйһиссәламгә китереп бирде. Әүвәл хәзрәт ачкычны Госман кулыннан алмакчы булып мөбарәк кулларын сузганда, хәзрәте Габбас торып: «Йә Рәсүлүллаһ, зәмзәм коесын минем карамакка тапшырганыгыз кебек хаҗиблекне, ягъни Кәгъбәнең ачкычын саклауны да, миңа ышанып тапшырсагыз иде», – диде.

Талханың улы хәзрәте Габбасның сүзен ишеткәч, ачкычны бирәсе килмичә сузган кулын кире алды. Рәсүл салаллаһу галәйһиссәлам: «Ачкычны миңа бирче», – дигәннән соң, хәзрәте Габбас,

ачкычны үзенә бирүне сорап, яңадан кулын сузды. Хәзрәте салаллаһу галәйһиссәлам Талханың улына: «Әгәр Ходайга һәм аның Рәсүленә ышансаң, ачкычны миңа бир», – дигәннән соң гына, Талха улы: «Алыгыз, йә Рәсүллүллаһ, Ходайның әманәте булсын», – диеп, ачкычны Рәсүл галәйһиссәламгә бирде. Әүвәл хәзрәт, Кәгъбәтуллаһны ачып, эчкә керде. Кәгъбәдән чыккан вакытында ачкыч әүвәл хәзрәтнең мөбарәк кулында иде. Гали хәзрәт, аның хозурына килеп: «Йә Рәсүлүллаһ, зәмзәм коесын әһле-бәйткә бирдегез, хаҗиблек вазифасын да бирсәгезче», – дип, ачкычны үзенә бирүне үтенде.

Шул вакыт Җәбраил галәйһиссәлам, килеп, бу аятьне ирештерде. Аяттә – ачкыч иясенә, ягъни Талха улына тапшырылырга тиешлеге турында белдерелде. Рәсүл галәйһиссәлам, хәзрәте Галигә мөрәҗәгать итеп: «Мин сезгә шундый эшләрне тапшырырмын: ул эшләрдән халык өчен файдасы булыр, әмма бу эш өчен халыктан сезгә файдасы булмас. Бу эш исә сезгә мөнасиб түгел», – диде. Соңыннан пәйгамбәр галәйһиссәлам, Кәгъбә ачкычын Талха улы Госманга сузып: «Алыгыз бу ачкычны, әй Талха уллары, сездән аны бирәү дә алмас, алса да залим генә алыр», – диде. Госман бин Талха, Рәсүл галәйһиссәламнең рөхсәтен алып, Кәгъбәтуллаһ ачкычын үзенең карендәше Шибә бин Талхага тапшырды. Бүгенге көнгә кадәр Кәгъбә ачкычы Шибәнең варислары кулында саклана. (Т.Б., 2, 216 б.)

***Сәлам бирү турында риваять.*** Бер кеше, Ибне Габбас разый Аллаһу ганьһүгә сәлам биреп: «Әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү», – диде. Хәзрәте Ибне Габбас та аңарга шулай ук җавап кайтарды, һичнәрсәне арттырмады: «Сәлам бәрәкәтендә тәмам булды», – диде.

Рәсүл салаллаһу галәйһиссәлам хәзрәтләре янына бер кеше килеп: «Әссәламү галәйкүм», – диде. Пәйгамбәребез аңарга: «Сиңа ун изгелекнең әҗере булсын», – дип боерды. Соңыннан тагын бер кеше килеп: «Әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи», – диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам, аның сәламенә җавап биреп: «Сиңа егерме изгелекнең әҗере булды», – диде. (Т.Б., 1, 228 б.)

***Игелекле гамәл турында.*** Ибраһим галәйһиссәлам заманында ачлык булды. Ибраһим галәйһиссәлам элек-электән бик юмарт һәм игелекле кеше булганга күрә, аның янына ашарга сорап, һәр тарафтан ачлыктан интеккән кешеләр килә иде. Хәзрәте Ибраһим

берәүне дә буш җибәрми иде. Шул рәвешчә ул амбарларында булган ашлыкны халыкка өләшеп бетерде. Үзендә бернәрсә дә калмагач, хәзрәте Ибраһим үзенең Мисырдагы дустына, ашлык сорап, берничә дөясен җибәрде. Дусты: «Безнең үзебездә дә ачлык, әгәр Ибраһим үзе өчен сораган булса, бирер дә идек, кешеләргә өләшү өчен булгач, без бирә алмыйбыз», – дип, ашлык бирмичә, дөяләрне буш килеш кайтарып җибәрде. Хәзрәте Ибраһимның хезмәтчеләре, дөяләрне буш хәлдә шәһәргә алып керергә оялып, капчыкларга ком тутырып, аларны дөяләргә төяделәр.

Хәзрәте Ибраһим, бу хәлдән кайгыга чумып, гыйбадәт кылам дип, мәчеткә китте. Хатыны Сара, йокысыннан уянып тулы капчыкларны күргәч, шатланып, бер капчыкны чиште һәм бик матур бодай онын күрде. Тиз генә икмәкне пешереп, гаиләсен тукландырды, фәкыйрьләргә дә өләште. Ибраһим галәйһиссәлам, икмәк исен сизеп, мәчеттән өенә кайтты һәм: «Бу ризык кайдан килде?» – дип сорагач: «Мисырдагы дустыңнан килде», – дип җавап бирделәр. Хәзрәте Ибраһим әйтте: «Әйе, хәзинәсе һич тә кимеми торган дустан килгәндер, шул сәбәпле Ходай Тәгалә аны Халил дип атады...» – диде. (Т.Б., 1, 245–246 б.)

***Гайсаның күккә ашуы.*** Риваять ителде: Яһүдләрдән бер төркем, Гайса галәйһиссәлам һәм аның анасы хакында ярамас сүзләр сөйләп, аларны хурладылар. Ходай Тәгалә аларның табына торган сурәтләрен танымаслык итеп дуңгыз һәм маймыл кыяфәтенә кертте. Яһүдләр хәзрәте Гайса галәйһиссәламне үтерергә карар иттеләр. Ходай Тәгалә аларның бу кара эшләре турында хәзрәте Гайсага белдерде һәм аңарга күккә күтәреләчәге турында хәбәр бирде. Гайса галәйһиссәлам үзенең фикердәшләренә әйтте: «Сезнең кайсыгыз минем сурәтемә кереп, минем урынга асып үтерелергә риза булса, ул җәннәткә керер», – диде. Берсе риза булды, Хак Тәгалә аны хәзрәте Гайса сурәтенә кертте. Кяферләр, Гайса дип уйлап, аны дарга астылар. Ходай Тәгалә үз кодрәте белән хәзрәте Гайсаны күккә ашырды. (Т.Б., 1, 256 б.)

***Бәни Исраил һәм Муса галәйһиссәлам.*** Бәни Исраил һәм Муса галәйһиссәлам, Тийә сахрасында алты фарсах үлчәмендәге җирдә адашып, кырык ел йөрделәр. Һәркөн иртән торып чыгып китәләр дә кичкә кадәр йөриләр һәм, ахшам вакыты җиткәч, тагын иртә белән киткән урыннарына килеп чыгалар иде. Көндезен

аларның башлары өстендә болыт күләгә булып тора иде, кич белән нурдан бер багана пәйда булып, аларга яктылык бирә иде. Аларның ашый торган ризыклары күктән төшкән мән һәм сәлүә иде, сулары Муса галәйһиссәлам китергән таштан чыга иде. Хәзрәте Йушгъ берлә этеннән башка егерме яшенә ирешкәннәрнең һәммәсе шул сахрада йөргән чакларында вафат булдылар. «Без җаббарлар карьясенә кермибез», – дигәннәрнең барысы да Ирийха карьясенә керә алмадылар, Тийә сахрасында вафат булдылар. Кырык ел вакыт узганнан соң, Муса галәйһиссәлам аларның исән калганнары һәм балалары белән Ирийха карьясенә барып, аны үзләренә буйсындырдылар.

Икенче бер риваятьтә Муса галәйһиссәламнең вафаты шул Тийә сахрасында булды диелә. Кыскартып әйткәндә, бу риваятьтә Муса галәйһиссәлам Йушыгъ галәйһиссәламгә Ирийха карьясен үз кулына алырга васыять итеп калдыра. Йушыгъ галәйһиссәлам, барып, җаббарлар белән сугыша.

Сүдә рәхмәтүллаһи галәйһи әйтә: «Хак сөбханә вә Тәгалә Муса галәйһиссәламгә: «Карендәшең Һарунны вафат кылачакмын», дигән вәхи килде. Һарун белән бергә фәлән тауга бар», – дип боерды. Хәзрәте Муса Һарун белән шул тауга юнәлделәр, анда бер агачны күрделәр, андый агачны моңарчы бер дә күргәннәре юк иде. Шунда алар бер өй күрделәр. Өйнең эчендә бер сәрийр (ятак) бар, аның өстенә түшәк түшәлгән, аңардан хуш исләр килеп тора иде.

Һарун галәйһиссәлам, аны күреп, бик сөенде: «Бу түшәккә ятып йоклар идем дә бит, иясе килеп, миңа ачуланыр дип куркам», – диде. Муса галәйһиссәлам аңарга: «Курыкма, бу түшәккә ят, әгәр иясе килсә, мин аның күңелен табармын», – диде. Хәзрәте Һарунның түшәк өстенә ятуы булды, шунда җаны да чыкты. Ул өй һәм агач күздән юк булдылар. Муса галәйһиссәлам ялгызы гына исраиллеләр янына кайткач: «Һарунга хөсетлек итеп, аны үзең үтергәнсеңдер», – дип, Муса галәйһиссәламне гаепләделәр. Соңыннан Муса галәйһиссәлам, дога кылып, Ходай Тәгаләдән сорады. Ул түшәк түшәлгән ятак яңадан пәйда булып, аның өстендә Һарунның үле гәүдәсен күргәч, исраиллеләр Муса галәйһиссәламгә ышандылар. (Т.Б., 1, 275–277 б.)

***Гайсаның догасы.*** Ходай Тәгалә хәзрәте Гайсаның догасын кабул итте һәм аңарга ике болыт җибәрде. Кызыл төстәге аш

өстәле шул болытларның уртасында иде. Җир йөзенә якын килгәч, бу дәстәрхан, болытлардан аерылып, сөйләшеп утыручыларның алдына килеп төште. Гайса галәйһиссәлам бу хәлне күргәч елап: «Аллаһүммә әҗгальнә минәш-шәкирийн», ягъни: «Иләһи, Син безне шөкерана итүчеләрдән кылсаң иде», – диде. Тагын әйтте: «Иләһи, Син бу дәстәрханны безгә үзеңнең шәфкатең итеп ирештерсәң иде, газап һәм җәза өчен ирештермәсәң иде».

Шуннан соң тәһарәт алып, намаз укыды, соңыннан елап: «Бисмилләһи хәйру разикыйн», – дип, аш өстәленең өстенә ябылган ашъяулыкны ачты, күз алдында төрле нигъмәтләр белән тулы дәстәрхан пәйда булды. Анда бер балык бар иде, аның тиресе дә, кылчыклары да юк иде, майлары тамып тора иде. Балыкның баш очында тоз, койрыгы очында серкә бар иде, тирәсендә төрле яшелчә үләннәре ята. Ул дәстәрханда биш данә кәсә дә куелган: берсендә зәйтүн җимеше, икенчесендә бал, тагын берсендә май, башкаларында пәнир һәм катык бар иде. Мәҗлестә утыручыларның Шәмгун исемлесе: «Йә Рухуллаһи, бу ризыклар дөньяныкымы, әллә ахирәт ризыкларымы?» – дип сорап куйды.

Гайса галәйһиссәлам әйтте: «Берсеннән дә түгел, ә бәлки Ходай Тәгалә үз кодрәте белән сезнең өчен биргән ризыклар, теләгегез кабул булды, ашагыз сез аларны һәм шөкерана кылыгыз! Нигъмәтегез күп булыр», – диде.

Мәҗлестә утыручылар әйттеләр: «Йә Рухуллаһи, мондый нигъмәтләрне безгә яңадан бирүеңне телибез, могҗизаңны күрсәт, безнең ышанычыбыз тагын да арта төшсен, пешкән балыкны терелт», – диделәр.

Гайса галәйһиссәлам пешкән балыкка: «Терел», – диде. Хак Тәгаләнең кодрәте белән филхәл[28] балык җанланды, кыймылдый башлады. Хәзрәте Гайса: «Яңадан элеккеге хәлеңә кайт», – дигәч, балык әүвәлге хәленә кайтты. Мәҗлестә утыручылар, Ходай Тәгаләдән куркып, күбесе ул дәстәрханнан ашамадылар.

Гайса галәйһиссәлам: «Фәкыйрьләр, мескеннәр һәм сырхаулар бу дәстәрханнан теләгәнчә ашасыннар. Бу аларга Ходайның бүләгедер һәм шифасыдыр, башка кешеләргә бәладер». Мең дә өч йөз кеше ул дәстәрханнан ашадылар, әмма ризык һич кимемәде. Бу нигъмәтләрне ашаган фәкыйрьләр соңыннан баедылар, сырхаулар сәламәт-

[28] *Филхәл* (г а р ә п) – шундук, кичекмәстән.

ләнделәр. Соңыннан аш өстәле күккә күтәрелде, икенче көнне тагын килде. Фәкыйрьләр һәм байлар барысы да ашадылар, кырык көнгәчә аш өстәле һәр көн килде. Хак Тәгаләдән хәзрәте Гайсага вәхи килде: «Ул аш өстәленнән байлар ашамасыннар, фәкыйрьләр генә ашасыннар». Әмма байлар күңеленә бу сүзләр хуш килмәде. Алар бу аш өстәле турында «сихер бу» диделәр һәм соңыннан өстәл килмәс булды. Бу могҗизалы эшкә шик-шөбһә белдергән кешеләрне Хак Тәгалә дуңгыз сурәтенә кертте, өч көн шул кыяфәттә йөргәннән соң алар һәлак булдылар... (Т.Б., 1, 315–316 б.)

***Нәмруд патша һәм Ибраһим галәйһиссәлам.*** Нәмруд бин Кәнгань патша бөтен җир йөзендә бердәнбер патша иде, тәхете Бабил шәһәрендә иде. Бер кичне ул мондый төш күрде: имеш, күкнең бер тарафыннан бер йолдыз калыкты. Ул йолдызның яктылыгы шулкадәр көчле иде – ай белән кояш аның нурында күмелеп калдылар. Нәмруд, бик каты куркып, төшеннән уянды, филхәл шәһәрнең барлык галимнәрен, түрәләрен җыеп, алардан үзенең күргән төшен юрауны сорады. Төшнең тәгъбирен болай аңлаттылар: «Бабил вилаятендә бер изге, бәхетле ир бала дөньяга килер, ул барлык галәмгә нур чәчәр. Син үзең дә, мәмләкәтең халкы да шул углан кулыннан һәлак булырлар, дәүләтеңнең бетүенә шул углан сәбәпче булыр. Ул угланның яралгысы хәзергә атасыннан анасының карынына күчкәне юк», – диделәр. Шуннан соң, Нәмруд патшаның фәрманы белән, Бабил вилаятендә никадәр ирле-хатынлы кешеләр булса, шуларны бер-берләреннән аердылар. Бер генә ир кеше дә үз хатынына якын килмәскә тиеш булды. Бу боерыкның үтәлешен күзәтеп тору өчен өй саен каравылчы куйдылар. Хатыны белән сохбәтләшкән иргә үлем җәзасы биреләчәк дип, халыкны кисәтеп куйдылар.

Нәмрудның үзенә якын хезмәтчеләреннән булган Азәр исемле кеше каравылчыдан качып кына хатыны Әдинә белән якынлык кылды, хатыны йөкле булды. Шул көннең иртәгесен каһиннәр[29] Нәмрудка хәбәр бирделәр: «Бүген кичен әлеге бала анасы карынына күчте», – диделәр. Моны ишеткәч Нәмруд бик ачуланды, барлык йөкле хатыннарны барлап чыгарга һәм саклап тору өчен махсус сакчылар билгеләргә кушты: әгәр ир бала тапсалар, ул баланы тугач та үтерергә кушылды.

[29] *Каһиннәр* (г а р ә п) – күрәзәчеләр.

Йөкле хатыннарны тикшергәндә хәзрәте Ибраһимның анасында йөклелек әсәре беленмәгәч, аңарга сакчы куелмады, шуннан соң аңа һичкем илтифат итмәде. Бала туарга якынлашкач Әдинә: «Ир бала дөньяга килсә, Нәмрудның кешеләре бала тавышын ишетерләр дә баламны үтерерләр», – дип курыкты. Шул сәбәпле, халыктан качып кына шәһәрдән читтәрәк бер тау куышына барып, хәзрәте Ибраһимны шунда дөньяга китерде һәм шул тау куышында аны тәрбияли иде. Үзе шәһәргә кайтканда, баласын шунда калдырып, тау куышының тишеген ташлар белән каплап китә иде. Азәр хатынының йөкле икәнлеген белә иде: «Йөгең ничек булды?» – дип сорагач, хатыны: «Мин, Нәмруд сакчыларыннан курыкканым өчен шәһәрдән чыгып, баламны тау куышында тудырдым, балам вафат булды, шунда ук күмеп тә калдырдым», – дип җавап бирде.

Хәзрәте Ибраһимның анасы бер көнне тау куышына килгәч, баласының үз бармакларын имеп ятуын күрде. Аның бер бармагыннан сөт, икенчесеннән бал килә иде. Хак Тәгаләнең кодрәте белән Ибраһим бер көндә башка балаларның бер айда үскәне кадәр үсә иде. Җиде яшенә кадәр ул шул мәгарәдә яшәде, соңыннан анасы аның турында ире Азәргә сөйләп бирде. Азәр хәзрәте Ибраһимны күргәч бик яратты, аны шәһәргә алып кайтырга кушты... Ахшам вакыты иде. Анасы хәзрәте Ибраһимны мәгарәдән алып чыкты. Тау янында дөяләр һәм куй көтүләре утлап йөри иде. Хәзрәте Ибраһим: «Болар нәрсәләр?» – дип, анасыннан сорады. Анасы һәркайсының исемнәрен һәм нинди җенестән булуларын бәян итте.

Хәзрәте Ибраһим әйтте: «Бу җан ияләренең тәрбиячесе булырга тиештер ич», – дигәч, анасы: «Әйе, һәр җан иясенең хуҗасы, бар итүчесе бар», – дип җавап бирде. Хәзрәте Ибраһим бу сүзне ишеткәч: «Алай булса, минем пәрвәрдигәрем, Ходаем кем соң?» – диде. Анасы әйтте: «Синең һәм безнең пәрвәрдигәребез Нәмруд патша», – диде. Хәзрәте Ибраһим: «Нәмрудның Ходае кем?» – дип сорагач, анасы аңарга ачуланды: «Мондый куркыныч сүзләрне сөйләмә, улым», – диде.

Ул заманда берәүләр кояшка, икенчеләре айга һәм йолдызларга, ә кайберәүләр сыннарга табыналар иде. Бер төркем халык исә Нәмрудны Ходай дип, аңарга гыйбадәт кылалар иде. Хәзрәте Ибраһим анасы белән шәһәргә юл тоттылар. (Т.Б., 1, 340–342 б.)

***Әманәткә хыянәт итү.*** Сәхабәләрнең Бәдил исемлесе сәүдә эшләре белән Шам вилаятенә барган иде. Шунда ул авырып китте, аның хәле көннән-көн начарлана гына барды. Кяферләрдән Тәмимүддар һәм Гудә исемле кешеләр аның юлдашлары иде, Бәдил аларга: «Минем вафатымнан соң барлык әйберләремне варисларыма ирештерерсез», – дип васыять итте.

Бәдил вафат булгач, Тәмимүддар һәм Гудә аның булган нәрсәләре арасыннан өч йөз мыскал авырлыкта булган бер көмеш савытны үзләрендә калдырдылар, ә калган әйберләрен, алып кайтып, Бәдилнең варисларына тапшырдылар. Бәдилнең җәмәгате әйберләр арасыннан бер язулы кәгазьне тапты. Ул кәгазьгә Бәдил үзендә булган нәрсәләрнең барысын да берәм-берәм язып куйган иде. Шул язуда көмеш савыт турында да әйтелгән иде. Бәдилнең варислары көмеш савытны тапмагач, Гудә һәм Тәмимүддардан: «Ул савыт кайда?» – дип сорадылар. Алар исә: «Без белмибез, әтиегезнең безгә әйткәне юк, аның безгә калдырган әйберләре бары шулар гына», – диделәр. Шуннан соң Бәдилнең варислары, Рәсүл салаллаһу галәйһиссәлам мәхкәмәсенә мөрәҗәгать итеп, Тәмимүддар белән Гудәдән атасының көмеш савытын кайтарып бирүләрен таләп иттеләр. (Т.Б., 1, 310 б.)

***Әфәк (яла ягу) кыйссасы.*** Һиҗрәтнең бишенче елында хәзрәте пәйгамбәр галәйһиссәлам үзенең сәхабәләре белән рәбийгъ сугышына киттеләр. Хәзрәте Гайшә, Аллаһ аңардан разый булсын, ул сәфәрдә пәйгамбәр галәйһиссәламгә юлдаш булды. Сугыштан кайткан вакытларында алар бер йортта туктадылар. Хәзрәте Гайшә бер эше белән тышка чыккан иде һәм шунда муенсасын югалтты. Шуны эзләп, үзләре туктаган урыннан бик ерак китте. Хәзрәте Гайшәнең киткәнен берәү дә күрмәде. Ул киткәннән соң гаскәр дә башка урынга күченде.

Хезмәтчеләр хәзрәте Гайшәнең һәүдәҗен[30] дөягә йөкләгәндә аның эчен тикшереп тормадылар, хәзрәте Гайшә эчтә утырадыр дип уйладылар һәм эшләрен бетергәч китеп тә бардылар. Гайшә разый Аллаһу ганьһә үзләре туктаган йортка кайтканнан соң, ислам гаскәренең күчеп киткәнен күреп хәйран булды, ялгызы шунда утырып калды.

---

[30] *Һәүдәҗ* (г а р ә п) – тирәли пәрдә корылып, дөя өстенә куела торган утырып бару җайланмасы.

Сафуан бин Могатталхәзрәте пәйгамбәрнең боерыгы белән ислам гаскәренең артыннан бара иде. Моның сәбәбе, әгәр кәрваннан онытылып калган берәр нәрсә булса, яки аерылып калган кеше булса, шуны тикшереп, үзе белән алып, гаскәргә илтү иде. Шул Сафуан, югарыда искә алынган мәнзилгяһка[31] килеп, хәзрәте Гайшәне ялгыз утырган хәлдә күрде һәм аны чакырып китереп, дөясенә атландырды, үзе исә, дөяне җитәкләп, һумаюнга[32] китерде. Гаскәр туктаган урынга җиткәч, мөнафикълар каршысыннан үтеп барганда Ибн Әбү Мөнафикъ, хәзрәте Гайшәнең Сафуан дөясенә атланып баруын күреп, бозык табигатьле булганга күрә, Рәсүл салаллаһу галәйһиссәламнең җәмәгатенә лаек булмаган әшәке сүзләрне әйтеп, зур әдәпсезлекне күрсәтте. Гаскәр Мәдинә шәһәренә кайтканнан соң, бу хәбәр хәзрәте пәйгамбәр галәйһиссәламгә ишетелде. Анабыз Гайшә, Аллаһ аңардан разый булсын, сырхаулаган иде һәм бу сүзләрдән хәбәре юк иде. Хәзрәте пәйгамбәрнең үзенә илтифат итмәвен күргәч, аңардан рөхсәт сорап, атасы Әбү Бәкер Ситдыйкның, Аллаһ аңардан разый булсын, өенә берничә көн тору өчен кайткан иде. Шунда аңарга бу сүзләрне җиткерделәр, аларны ишетеп, хәзрәте Гайшәнең сырхавы тагын да көчәйде, кичен, көндезен елап уздыра иде.

Рәсүл салаллаһу галәйһиссәлам хәзрәте Гайшә турында мөхтәрәм аналар шурасыннан сорашып белде. Аларның һәркайсы хәзрәте Гайшәнең пакь һәм саф күңелле, турылыклы хатын булуын расладылар.

Шулай бер көнне Рәсүл хәзрәтләре Әбү Бәкер Ситдыйкның өенә килде һәм, хәзрәте Гайшәнең елаганын күреп: «Әй Гайшә, әгәр синдә берәр төрле гөнаһ булса, тәүбә ит, Ходай Тәгаләдән кичерүне сора», – диде.

Хәзрәте Гайшә, бик нык ачуланып һәм каушап, болай диде: «Дошманнар безнең турыда сүз тараттылар, инде мин нәрсә генә әйтсәм дә, халык минем сүземә ышанмас. Мин монда Йосыф галәйһиссәламнең әйткән сүзләрен искәртеп үтәсем килә: «Сабырлык – ул гүзәл нәрсә, Аллаһ Тәгалә сабыр итә белүчеләргә ярдәмен ирештерер», – дигән. Мин дә шул ук сүзләрне кабатлыйм һәм Ходай Тәгалә үзе бер хөкемен ясар дип ышанам».

[31] *Мәнзилгяһ* (г а р ә п – ф а р с ы) – йорт-җир, яшәү урыны.
[32] *Һумаюн* (ф а р с ы) – патша, император.

Гайшә, Аллаһ аңардан разый булсын, шул вакытта «Ягькуб галәйһиссәлам сүзләре белән диясе урында Йосыф галәйһиссәлам әйткән сүзне дип әйттем», дип, исенә төшерә торган булган.

Шулай итеп хәзрәте Гайшә, сүзен тәмамларга өлгергәнче үк, пәйгамбәрнең мөбарәк йөзендә вәхи әсәре пәйда булды, турылыклы Гайшә хәзрәтенең бәраъәте һәм пакьлеге хакында мондый аять иңдерелде: «Иннәл-лә-зийнә җәъү бил-ифки гүсбәтүм миңкүм лә тәхсәбүһү шәррал-ләкүм бәл һүә хайрул-ләкүм ликүлли әмрин минһүм мәктәсәбә минәлисми вәлләзий тәүәллә кибраһү минһүм ләһү гәзәбүн гәзыйм». («Нур» сүрәсе, 11 аять.) (Һичшиксез, бу бөһтанны (ялганны) уйлап чыгаручылар – үзегезнең арагыздагы бер төркем кешеләр. Үзегез өчен моны сез яманлык дип уйламагыз, бәлки ул сезнең өчен яхшылыктыр да әле. Ялган уйдырманы тудыручыларның һәрберсе, эшләгән гөнаһысына күрә җәзасын да алачак. Гөнаһның иң зурысын эшләүчегә газапның да иң зурысы булыр.) (Т.Б., 2, 172–173 б.)

***Карун, Муса һәм Һарун турында риваять.*** Карун, Муса һәм Һарун галәйһиссәламнәргә хөсетлек эшли, алар икесе дә пәйгамбәр булдылар, миңа һич насыйп булмады, дип, алардан көнләшә иде. Эчендә аларга кинә һәм дошманлык хисләрен саклый иде. Бәни Исраил кавеменә Хак Тәгалә зәкят бирүне фарыз итте: малның уннан бер өлеше, яки дүрттән бере фәкыйрьләргә бирелергә тиеш иде. Карун исә зәкят бирүне кабул итмәде. Муса галәйһиссәлам аның белән сөйләшкәннән соң, мең алтыннан бер алтын зәкят түләргә дип килешенде. Карун баштарак күнмәкче булган иде, хисаплап караганнан соң малының меңнән бер өлеше дә аңарга бик күп булып күренде. Аны саранлыгы һәм хәсислеге җиңде, бу кадәр малны ничек чыгарып бирергә кирәк, дип, килешүне кабул итмәде: «Мин бу зәкят дигән нәрсәне белергә дә теләмим», – диде, һәм, исраиллеләрдән бер төркем кешене үз янына чакырып, аларга әйтте: «Сез моңарчы Мусаның һәрбер фәрманына буйсынып килдегез, инде, зәкят дип, ул сезнең малларыгызны алмакчы була, сез нишләп торасыз?» – диде. Алар әйттеләр: «Син – безнең хөрмәт иткән кешебез, җитәкчебез, син ничек кушсаң, шулай булыр да, без синең ихтыярыңда», – диделәр. Карун әйтте: «Мин Мусаны халык арасында хур итәргә телим, моннан соң берәү дә аның сүзен тыңламасын».

Шуннан соң Карун Сирә исемле бер фәхишә хатынны чакыртып китерде һәм аңарга ике янчык алтын бирде: «Фәлән көнне Муса пәйгамбәр, Исраил халкының олысын-кечесен җыеп, аларга вәгазь укыячак, син шунда бул, Муса минем белән зина кылды дип әйтерсең, икрар итәрсең», – диде. Хатын, алтынга кызыгып, бу эшкә ризалашты.

Муса пәйгамбәрнең халык алдында вәгазь сөйләү көне дә килеп җитте. Исраил халкы вәгазь тыңларга җыелды. Муса пәйгамбәр үзенең вәгазендә эшләргә яраган һәм ярамаган яки тыелган нәрсәләр хакында сөйләгәндә болай диде: «Әгәр кем дә кем угрылык эшләсә, шәригать хөкеме буенча аның кулын кисәрләр, әгәр берәү зина кылса, аны таш яудырып үтерерләр», – диде. Карун, моны ишеткәч, урыныннан торып әйтте: «Әй, Муса, әгәр син үзең зина кылсаң, сиңа карата да шул ук хөкем кулланылачакмы?» – диде. Муса галәйһиссәлам: «Әйе, нәкъ шулай», – диде. Карун әйтте: «Исраил халкы син фәлән фәхишә хатын белән зина кылгансың дип сөйли». Муса әйтте: «Мөгазуллаһ[33], бу ни дигән сүз, ул хатынны бирегә китерегез, аңардан сорап белик», – диде. Ул хатынны алып килделәр, Муса аңарга болай диде: «Исраил халкы өчен дәрьяны икегә аерган һәм Тәүратны иңдергән Ходай Тәгалә белән сиңа ант итеп боерам, безгә дөресен сөйләп бир». Фәхишә хатын куркудан һәм илаһи боерудан өркеп әйтте: «Әй Кәлимуллаһ, Карун миңа, ике кесә алтын биреп, сиңа яла ягарга, ялган сөйләргә кушты: мин ни кадәр генә гөнаһлы булсам да, синең турында ялган сөйләмәм, яла ягарга да җыенмыйм. Карун биргән алтыннар да минем янымда», – диде. Шулай итеп, Карун үзе Исраил халкы арасында хурлыкка калды, мәкере һәм хәйләсе ачылды. Муса галәйһиссәлам йөзен туфракка куйды, Хак Тәгаләгә мөрәҗәгать итеп, Карунга карата шикаятен белдерде. Тәңредән әмер килде: «Әй Муса, җирне синең хөкемеңдә калдырдым, нәрсә теләсәң шуны боер». Шуннан соң Муса галәйһиссәлам Исраил халкына әйтте: «Карун яклы булганнар үз урыннарында торсыннар, минем яклылар читкәрәк китсеннәр». Исраил халкы, урыннарыннан торып, бер читкә китте, ике генә кеше Карун янында калды.

Муса галәйһиссәлам, җиргә мөрәҗәгать итеп: «Аларны тот», – диде, шунда ук алар тубыкларына кадәр җиргә баттылар. Бу

[33] *Мөгазуллаһ* (г а р ә п) – Аллаһның кадерлесе.

хәлне күреп, хәзрәте Мусага ялвара башладылар, яклавын сорадылар, әмма аларның ялварулары кабул ителмәде. Муса галәйһиссәлам, җиргә мөрәҗәгать итеп: «Тагын тот үзләрен», – диде. Алар тезләренә чаклы җиргә баттылар. Муса галәйһиссәлам: «Тагын тот», – диде. Карунның һәм аның яклы булган ике кешенең аяклары тулысынча җиргә батты. Шулвакыт алар беравыздан ярдәм сорап ялвара башладылар, ләкин аларның ялварулары хәзрәте Мусага тәэсир итмәде. Муса галәйһиссәлам, җиргә кабат-кабат мөрәҗәгать итеп: «Аларны тот», – дип боера иде. Җир аларны бөтенләй йотып куйды, эсәрләре дә калмады. Карунны җир йотканнан соң, Исраил халкы арасындагы кайбер ахмаклар: «Муса Карунның хәзинәләрен үзенә алу өчен, дога кылып, аны йирдән йоттырды», – диделәр. Муса галәйһиссәлам, аларның сүзләрен ишеткәч, дога кылды: «Йә Иләһем, Карунның булган барлык хәзинәсен һәм йорт-җирләрен җир йотсын», – диде... (Т.Б., 2, 292–294 б.)

***Гайса галәйһиссәламнең хак дингә өндәве турында.*** Гайса галәйһиссәлам хак дингә өндәү өчен ике кешене, илче итеп, Антакиягә җибәргән иде. Шул илчеләр Антакия шәһәренә килеп җиттеләр. Шәһәр читендә куйларны көтеп йөрүче бер карт кешене күрделәр, аңарга сәлам бирделәр. Ул карт: «Сез кемнәр?» – дип сорады. Алар әйттеләр: «Без – Гайса пәйгамбәрнең илчеләре, халыкны хак юлга басарга өндибез».

Ул карт әйтте: «Дәгъвагызның, өндәп йөрүегезнең дөрес булуын раслый торган берәр дәлилегез бармы соң?» Илчеләр әйттеләр: «Әйе, дәлилебез бар, без сырхауларны дога кылу юлы белән сәламәтләндерәбез». Ул карт әйтте: «Минем бер улым бар, ничә еллар буе авырып ята, табиблар аңарга дәва таба алмыйлар. Әгәр сез, дога кылып, улымны сәламәтләндерсәгез, мин сезнең Ходаегызга иман китерәчәкмен», – диде. Шуннан соң Гайсаның илчеләре, картның авыру улы яткан җиргә килеп, Хак Тәгаләгә дога кылдылар. Картның улы шунда ук сәламәт булды, ул карт иман китерде. Аның исеме Хәбиб Нәҗҗар иде, аңа йасин сахибе диләр иде.

Бу ике илченең игелекле эшләре Антакия шәһәренең халкына да мәгълүм булды. Күп кенә кешеләр аларның догасы бәрәкәтендә сихәтләнделәр.

Ул шәһәрнең патшасы потка табына иде. Бу ике илче турындагы хәбәр аңарга да килеп иреште. Аларның халыкны потка табы-

нудан тыярга тырышуларын белде һәм шуның өчен бу илчеләрне зинданга яптырды. Бу хәбәр Гайса галәйһиссәламгә ишетелде һәм ул Антакия шәһәренә Шәмгун әс-Сафа исемле бер кешене илче итеп җибәрде. Шәмгун Антакия шәһәренә килгәннән соң, патшаның якын кешеләре, аның хезмәтчеләре, коллары белән танышты, дуслашты. Күп вакыт узмады, үзенең акылы һәм белеме белән ул патшаның якын кешесенә әверелде.

Шәмгун Антакия патшасына үзенең асыл максатын белдермәде, аның белән бергә потханәгә барды, Ходай Тәгаләгә гыйбадәт кылды. Кешеләр аны потка табына дип сөйлиләр иде. Патша да аны бик якын күрә һәм үзенең ышанычлы кешесе дип уйлый иде, бер генә эшне дә аның белән киңәшмичә эшләмәс булды. Бер көнне Шәмгун патшага әйтте: «Әй падишаһ, ике юлчыны зинданга яптыргансың дип ишеттем. Аларның гөнаһлары нидән гыйбарәт?»

Патша әйтте: «Алар потлардан башка Ходай бар дип сөйлиләр, халыкны потка табынудан тыярга маташалар». Шәмгун гаҗәпләнгән булып әйтеп куйды: «Ул мөсафирларны бирегә алып килергә боер, аларның бу сүзләре гаҗәпләндерә, әлбәттә». Патша боерыгы белән ул ике илчене зинданнан алып килделәр, алар Шәмгунны күргәч куркып калмадылар, тыныч кына утырдылар. Шәмгун алардан: «Сез кемгә табынасыз?» – дип сорады. «Сезне һәм безне, күкне һәм җирне яраткан Ходай Тәгаләгә гыйбадәт кылабыз», – дип җавап бирделәр. Шәмгун әйтте: «Ходаегызның нинди могҗиза эшләргә көче җитә?» Алар әйттеләр: «Ходай Тәгалә күзсезне күзле итә ала». Шәмгун патшадан сукыр кешене китертүне сорады, бер сукырны китерделәр: «Ходаегызга әйтегез, бу сукырны күрә торган итсен», – диде. Илчеләр дога кылдылар, филхәл ул сукыр күзле күрә торган булды. Шәмгун патшага әйтте: «Әй мәлик, без дә потларыбыздан сорыйк, шундый ук эшне башкарсыннар», – диде. Патша әкрен генә Шәмгунга әйтте: «Беләсеңме, безнең потларыбыз һичнәрсәне белмиләр, күрмиләр һәм ишетмиләр дә. Шулай булгач, алар мондый эшне ничек итеп эшли алсыннар?»

Шәмгун, бу ике илчегә карап, тагын болай диде: «Әй егетләр, сезнең Ходаегыз тагын нинди эшләрне башкара ала соң?» Алар әйттеләр: «Үлене терелтергә көче җитә». Шәмгун әйтте: «Әгәр сезнең Ходаегыз үлекне терелтә алса һәм безгә шуны эшләп күрсәтсә, барыбыз да аңарга иман китерербез», – диде.

Ул патшаның күптән үлгән бер кызын илчеләр дога кылып терелттеләр. Моны күргәч, патша үзенең халкы белән иман китерде, әмма кайберәүләр иман китермәделәр һәм яшерен генә мөэминнәргә каршы мәкерле эшләрен эшли башладылар. Бу хәбәр югарыда искә алынган Хәбиб Нәҗҗарга ишетелде. Ул ашыгып өеннән чыкты һәм илчеләр белән мөэминнәр янына юл тотты. Шул чакта Хак Тәгалә аңарга боерды... (Т.Б., 2, 409–410 б.)

***Ильяс галәйһиссәлам турында риваять.*** Хак сөбханә Тәгалә Ильяс галәйһиссәламне Бәгальбәк шәһәре халкына пәйгамбәр итеп җибәрде. Аларның Әҗиб исемле патшалары бар иде. Элек ул мөселман булган, соңыннан, бер хатынның коткысына алданып, ислам диненнән ваз кичкән һәм потка табына башлаган. Ильяс галәйһиссәлам дога кылды һәм аларда өч ел буе ачлык булды. Шуннан соң алар хәзрәте Ильяска мөрәҗәгать иттеләр, үзләрен бу бәладән коткаруны сорап ялвардылар. Ильяс галәйһиссәлам әйтте: «Әгәр минем динемнең хак дин икәнлеген беләсегез, күрәсегез килсә, әйдәгез, һәрберебез үз Ходаебызга дога кылыйк – мин, үз Ходаема дога кылып, бу бәланең тизрәк китүен сорыйм, ә сез үз потларыгыздан сорагыз. Кайсыбызның догасы кабул булса, аның Ходае табыну өчен лаек булыр». Алар хәзрәте Ильясның сүзләре белән ризалаштылар, һәм, потларын матурлап бизәгәннән соң, аңардан яңгыр яудыруын сорадылар. Күпме генә ялварсалар да, нәтиҗәсе булмады. Аннан соң Ильяс галәйһиссәлам Ходай Тәгаләгә дога кылды һәм аңардан яңгыр яудыруны сорады. Ходай Тәгаләнең әмере белән шунда ук болытлар пәйда булды, һәм яңгыр ява башлады. Әмма Бәгальбәк халкы моны күрә торып та инсафка килергә уйламады, иман китермәде, ә бәлки хәзрәте Ильясны ялганчылыкта гаепләделәр.

Хәзрәте Ильяс галәйһиссәлам, бу кавемнең иман китермәвенә борчылып, Ходай Тәгаләгә:

«Йә Раббым, бу кавемгә газабыңны ирештергәнгә кадәр мине алар арасыннан чыгаруыңны сорыйм», – дип дога кылды. Шулвакыт Ходайдан фәрман килде: «Фәлән көнне фәлән урынга барып тор: каршыңа нәрсә килеп басса да, аңарга менеп атлан».

Хәзрәте Ильяс билгеле көн җиткәч әйтелгән урынга барды, аның каршына уттан ясалган арыслан сурәтендәге бер нәрсә килеп басты. Ильяс галәйһиссәлам аңарга менеп атланды, үз урынына Әл-Йәси-

гъны хәлифә итеп калдырды. Хак сөбханә вә Тәгалә хәзрәте Ильяска оча торган канат бирде, ашау-эчү һәм башка теләкләрне аңардан алды. Ул, фәрештә кебек очып, теләгән җиренә бара ала иде.

Ильяс галәйһиссәлам – сахраларның хуҗасы итеп, Хозыр галәйһиссәлам дәрьяларның хуҗасы итеп билгеләнделәр; елга бер мәртәбә хаҗ вакытында Гарәфәт тавында бер-берсе белән очрашалар һәм рамазан аенда Бәйтүл-Мәкъдистә бергә ифтар кылалар диләр, монысын Аллаһ үзе генә беләдер. (Т.Б., 2, 344 б.)

***Юныс пәйгамбәр кыйссасы.*** Юныс галәйһиссәлам – җибәрелгән пәйгамбәрләрнең берседер. Хак сөбханә вә Тәгалә аны Нәйнава шәһәренең халкына пәйгамбәр итеп җибәрде.

Коръәннең «Юныс» сүрәсендә бу турыда ачык итеп сөйләнгән. Бу шәһәрнең халкы аны ялганчы дип гаепләделәр. Хәзрәте Юныс аларга газап ирешүен теләде һәм үзе кавеме арасыннан китеп барды. Газапның билгеләре күренә башлаганнан соң, Юныс галәйһиссәламнең кавеме иман китерде, һәм газап кире күккә күтәрелде. Бу хәбәр Юныс галәйһиссәламгә билгеле булды.

Юныс галәйһиссәлам үзенең кавеменә элегрәк: «Сезгә күп газаплар килер», – дип әйткән иде. Алар арасына кайтсам, сүзең ялган булды, газап килмәде, дип, мине гаепләрләр дип кайгырды. Шул сәбәпле, кавеме янына кайтмыйча, дәрья тарафына юнәлде. Дәрья ярына килеп җиткәч, ул бер төркем сәүдәгәрләрнең көймәгә утыруларын күрде. Хәзрәте Юныс та алар белән бергә көймәгә утырды. Дәрья уртасына җиткәч, көймә туктап калды һәм ишкәкчеләр: «Бу көймәдә бер качкан кол бар, көймә шул сәбәпле бармас булды», – диделәр. Хәзрәте Юныс әйтте: «Хуҗасыннан качкан кол – ул мин», – диде. Көймәдәге кешеләр әйттеләр: «Син кол булсаң да, синең азатлыгың һәм яхшылыгың кыяфәтеңнән һәм йөзеңнән үк күренеп тора, бер изге кеше син», – диделәр. Юныс галәйһиссәлам кабатлап аларга: «Әлбәттә, мин – качкан колмын», – диде. Ул кавемнең гадәте бар: әгәр көймәдә качкан кол булса, аны тотып суга ташлыйлар, һәм шуннан соң гына көймә йөзеп китә иде. Юныс галәйһиссәлам һаман саен: «Мин – качкан кол, мине дәрьяга ташлагыз», – дип кабатлар иде.

Көймәдә баручылар бу мәсьәләне шобага салып хәл итәргә булдылар. Өч тапкыр салдылар, өчесендә дә хәзрәте Юныс исеменә чыкты. Шуннан соң көймәдәгеләр хәзрәте Юнысны, күтәреп

алып, дәрьяга ташламакчы булдылар. Хак Тәгалә бер зур балыкка фәрманын ирештерде, ул балык, көймә янына килеп, авызын ачып торды. Көймәдәгеләр балыкны күргәч, хәзрәте Юнысны көймәнең икенче ягыннан ташламакчы булдылар. Балык та шул якка чыкты һәм тагын авызын ачып, йотарга әзерләнеп торды. Хәзрәте Юныс, башына бер нәрсәне бөркәнеп, бисмилласын әйтеп, үз-үзен дәрьяга ташлады һәм шунда ук аны балык йотты.

Хак Тәгалә ул балыкка боерды: «Әй балык, мин Юнысны сиңа ашамлык итеп бирмәдем, бәлки синең эчеңне аңарга зиндан иттем. Шулай булгач, син аңарга зыян китермә һәм аны сау-сәламәт килеш сакла».

Ул балык хәзрәте Юнысны үз баласын саклаган кебек саклады. Хәзрәте Юныс сулыш алсын өчен, үзенең башын һәрвакыт судан чыгарып йөзәр иде. Иң хикмәтлесе шул иде: Юныс галәйһиссәлам ул балыкның карынында кырык көн торды. Шул кырык көндә балык җиде диңгезне гизде. Хак Тәгалә аның итен һәм тиресен пыяла кебек нәзек һәм саф, үтә күренмәле итте. Хәзрәте Юныс аның эченнән диңгездәге искиткеч һәм гаҗәеп булган күренешләрнең барысын да күрә, тамаша итә, күңелендә һәрвакыт Ходай Тәгаләне йад итә иде. (Т.Б., 2, 436 б.)

***Хәмзә һәм Гомәр, Аллаһ алардан разый булсын.*** Бу ике мөхтәрәм һәм зыялы кеше мөселманлыкны кабул иткәч, корәйш кабиләсенең олы затлары кара кайгыда калдылар, Әбү Талибнең хозурына килделәр һәм аңарга әйттеләр: «Әй Габделмәннаф улы, син безнөң арабызда иң мөхтәрәм кешеләрдән. Без сиңа киңәш сорап килдек: безнең белән карендәшеңнең улы арасындагы каршылыкны ничек хәл итәргә мөмкин? Ул безнең олы затларыбызны, берәм-берәм алдалап, ата-бабаларыбызның диненнән яздыра, без табына торган потларыбызны хурлый, арабызга фетнә-таркаулык сала», – диделәр.

Әбү Талиб Рәсүлүллаһ хәзрәтен шул мәҗлескә чакыртып китертте һәм аңарга әйтте: «Әй Мөхәммәд, кавемеңнең зыялылары синнән зарланалар, бу турыда нәрсә әйтә аласың? Әмма җавабыңны уйлабрак кайтар, кызуланма». Хәзрәте Мөхәммәд аларга: «Әй, корәйш халкы, миннән нәрсә телисез?» – диде. Алар әйттеләр: «Син безнең ата-бабаларыбыздан калган динебезне хурлап йөрүеңне тук-

тат, безнең табына торган потларыбызны да сүгеп йөрмә. Ул чагында безнең сиңа дәгъвабыз булмас һәм сиңа иярмәбез», – диделәр.

Хәзрәте Мөхәммәд аларга: «Мин дә сездән таләп итәм: бер сүздә без берәгәйле булыйк, ул чагында гарәп дәүләтләре сезгә буйсыныр-лар, чит-ят илләрнең башлыклары да сезгә буйсынуларын белдерерләр», – диде. Алар сорадылар: «Ул нинди сүз соң?» Сәйидү галәм салаллаһу галәйһи вә сәлләм[34] әйтте: «Лә иләһә иллаллаһ[35], дигән сүз ул», – диде. Бу сүзне ишеткәч, корәйш зыялылары, бердәм булып, хәзрәте Мөхәммәдтән баш тарттылар һәм берберләренә әйттеләр. (Т.Б., 2, 442 б.)

***«Фәтех» сүрәсенең иңдерелүе турында.*** Рәсүлүллаһ салаллаһу галәйһиссәлам хәзрәтләре, һиҗрәтенең алтынчы елында, кайбер сәхабәләр белән бергә Мәккәгә барып, Кәгъбәи Мөгаззамәне күреп һәм хаҗ кылып кайтуны кирәк таптылар. Сәхабәләр бу турыда ишеткәннән соң, бу елны безгә хаҗга бару насыйп булачак икән, дип шатланыштылар. Рәсүле Әкрам хәзрәтләре зөлкагъдә аеның башында, дүшәмбе көн Мәккәгә бару теләге белән Мәдинә шәһәреннән чыктылар һәм гомрә хаҗы нияте белән өсләренә махсус киемнәрен киделәр – ихрам багладылар. Үзләре белән корбанлык өчен җитмеш дөяне ияртеп чыктылар. Аларның килүләре турындагы хәбәр Мәккәнең мөшрикләренә мәгълүм булды. Алар мөселманнарны Мәккәгә кертмәскә һәм Кәгъбәне зиярәт итүдән тыярга сүз беркеттеләр, Мәккәнең читенә чыгып, юлларына аркылы төштеләр, сугышчыларын тезеп куйдылар. Пәйгамбәр галәйһиссәлам мөшрикләрнең бу эшләреннән хәбәрдар иде, шуңа күрә Хәдибийә дигән урында туктарга карар итте. Мөшрикләр ягыннан бер илче, килеп, Рәсүл хәзрәтләренең нәрсә өчен монда килүен белергә теләде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Без монда сугышырга дип килмәдек, безнең теләгебез Кәгъбәне зиярәт итү», – диде.

Мөшрикләр мөселманнарның ниятен белгәч, аларны Мәккәгә кертергә ризалыкларын бирмәделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам хәзрәте Госманны илче итеп мөшрикләр янына җибәрде. Алар исә хәзрәте Госманны үзләре янында калдырдылар. Мөселманнар

[34] *Сәйидү галәм салаллаһу галәйһи вә сәлләм* (г а р ә п) – җир йөзендәге иң мөхтәрәм зат.

[35] *Лә иләһә иллаллаһ* (г а р ә п) – Аллаһтан башка гыйбадәт кылырдай бүтән зат юк.

хәзрәте Госманны корәйш мөшрикләре үтергәннәр дигән хәбәрне ишеттеләр. Шул сәбәпле «бийгатүр-ридван[36]» пәйда булды.

Мөшрикләр мөселманнарның бийгат итүләрен ишетеп курыктылар һәм алар белән солых төзү өчен Сүһәйл бин Гомәрне илче итеп пәйгамбәребез янына җибәрделәр. Үзара килешү буенча мөселманнар һәм корәйш мөшрикләре арасында солых төзелде. Бу солых нигезендә мөселманнар мөшрикләр белән ун ел сугышмаска булдылар; яшерен яисә ачыктан-ачык бер-берсенә каршы тормаска, һөҗүм итмәскә һәм мөселманнар бу елны Мәккәгә кермичә генә кайтып китәргә, киләсе елда Мәккәгә килеп, гомрәне каза кылырга сүз беркеттеләр. Һәр ике якта болардан башка да шартлар бар иде. Сәхабәләрнең күпчелеге мондый солыхны төзегәнгә бик кайгырдылар, шулай да, әлбәттә, бу эштә Ходай Тәгаләнең бер хикмәте, мәсләхәте[37] булса кирәк, дип разый булдылар.

Рәсүл галәйһиссәлам Хәдибийәдә, ихрамнан чыгып, мөбарәк башыннан чәчен алдырды һәм алып килгән дөяләрнең берничәсен шунда корбан итеп чалдылар, калганнарын Мәккәгә җибәрделәр, Мәрвәдә корбан итеп итләрен Мәккәнең ярлы кешеләренә өләшергә боердылар.

Рәсүл галәйһиссәлам Хәдибийәдә егерме көн торды. Хәдибийәдән Мәдинәгә кайткан вакытта «Иннә фәтәхнә...» сүрәсе иңде. Иртә белән Рәсүл хәзрәтләре сәхабәләргә әйтте: «Бу кичтә Ходай Тәгаләдән миңа бер сүрә иңдерелде, ул сүрә минем өчен барлык дөньядан һәм дөньядагы барлык нәрсәләрдән дә сөеклерәктер», – диде.

Шуннан соң ул сәхабәләргә бу сүрәне укып күрсәтте, тәбрикләде, сәхабәләр дә, «мөбарәк булсын» дип, Рәсүл галәйһиссәламне котладылар. (Т.Б., 2, 585–586 б.)

***Һиҗрәтнең дүртенче елында.*** Пәйгамбәр галәйһиссәлам Бәни Надыйр кабиләсе яһүдләренең каласына бер эш белән барган иде. Бер өйнең диварына мөбарәк аркасын сөяп утырган иде. Бер яһүд шул өйнең түбәсенә зур бер ташны алып менгән һәм пәйгамбәр галәйһиссәламнең өстенә ташламакчы булган. Филхәл Җәбраил галәйһиссәлам килеп, Рәсүл галәйһиссәламгә бу турыда хәбәр итте. Пәйгамбәр галәйһиссәлам, тиз генә урыныннан торып, Мәдинә шәһәренә кайтып китте, кайту белән Бәни Надыйр яһүдләренә

[36] *Бийгатүр ридван* (г а р ә п) – турылыклы булам дип ант итү.
[37] *Мәсләхәте* (г а р ә п) – файдасы

кеше җибәрде һәм әйтте: «Сезнең хыянәтегез ачылды, минем җиремнән чыгып китегез», – дип, аларга ун көн вакыт бирде. Яһүдләр китәргә әзерләнә башлаганнар иде, шул чакны аларга Мәдинәдән Ибн Әби Мөнафикъ хәбәр итте: «Үз җирегездән китмәгез, калагызның капкасын ныклап бикләп куегыз, мин дә мең кеше белән сезгә ярдәмгә килеп җитәрмен, бер дә курыкмагыз». Яһүдләр ул Мөнафикъның сүзенә алдандылар һәм пәйгамбәр галәйһиссәлам белән сугышырга әзерләнделәр. Рәсүл галәйһиссәлам, бу хәбәрне ишеткәч, бер төркем сугышчы белән барып, яһүдиләрнең каласын урап алдылар, һәм, унбиш көн чолганышта торганнан соң, яһүдиләр гозер итеп калаларын ташлап китәргә риза булуларын белдерделәр. Алар үзләрендә булган барлык коралларны мөселманнарга калдырырга тиеш булдылар. Атлары, дөяләре күтәрә алган кадәр күләмдә генә мал-мөлкәтләрен алырга рөхсәт бирелде. Бу вакыйгадан соң Хак Тәгаләдән аять иңде. (Т.Б., 2, 673 – 674 б.)

***Хәзрәте Гали һәм Фатыйманың нәзер әйтүләре.*** Пәйгамбәр галәйһиссәлам бер көнне мөхтәрәм Гали әл-Мортаза Кәрәмуллаһның өенә килде һәм, Имам Хәсән белән Имам Хөсәен хәзрәтләренең сырхау булуларын күргәч, хәзрәте Гали белән хәзрәте Фатыймага әйтте: «Ходай Тәгалә ризалыгы өчен нәзер әйтегез, балаларыгызга сихәтлек ирештерер», – диде. Алар икесе дә: «Өч көн руза тотарбыз», – дип нәзер әйттеләр. Хак Тәгалә ике имамга да шифа ирештерде, алар икесе дә сәламәтләнделәр. Гали һәм Фатыйма разый Аллаһу ганьһүмә хәзрәтләре нәзерләрен үтәделәр, руза тоттылар.

Хәзрәте Гали бераз арпа алып, ифтар өчен икмәк пешерделәр. Ахшам намазын укып ифтар ашарга әзерләнгәндә, ишекләренә бер мескен килеп: «Йә өйнең хуҗалары, мин – бер ач мескен мөселман кешесе, миңа ашарга бирсәгезче», – диде. Гали хәзрәт үз өлешенә тигән икмәк кисәген ул мескенгә биргәч, өйдәгеләр дә ул көнне, аңарга теләктәшлек күрсәтеп, су белән генә авыз ачтылар. Икенче көнне ифтар ашарга дип торганда, ишекләренә бер ятим бала килеп, садака сорагач, ифтарга дип әзерләнгән ризыкларны шул ятим балага биреп җибәрделәр һәм ул көнне дә ач кундылар. Өченче көнне ифтар вакытында тагын бер әсир кеше килде, һәм ифтар өчен әзерләнгән ризыкны аңарга биреп җибәрделәр. Хак Тәгалә аларның бу игелекле гамәлләре турында аять иңдерде. (Т.Б., 2, 758 б.)

***Сөләйман белән Дауд галәйһиссәлам кыйссасы.*** Бервакыт кичен бер кавемнең куйлары икенче кавемнең игененә кергәннәр, ашаганнар, таптаганнар. Бу ике кавем кешеләре Дауд галәйһиссәлам янына аның хөкемен ишетергә дип барганнар. Дауд галәйһиссәлам куйларның кыйммәтен, күпме иген кимегәнлеген хисаплап чыгарган һәм икесе дә бер үк дәрәҗәдә дигән нәтиҗәгә килгән, куйларны игеннең хуҗаларына биргән.

Бу ике кавем кешеләре Дауд галәйһиссәлам-нең улы Сөләйман галәйһиссәлам янына барганнар һәм Дауд галәйһиссәлам бу мәсьәләне ничек хәл итүен сөйләп биргәннәр. Сөләйман галәйһиссәлам бу вакытта унбер яшьтә булган, ул әйткән: «Атам Даудның хөкеме бик яхшы, ләкин мин ике тараф өчен дә файдалырак булган хөкемне чыгарам», – дигән һәм куйларның хуҗаларына тагын атасы Дауд галәйһиссәлам янына барырга кушкан. Алар Дауд галәйһиссәламгә улы Сөләйманның әйткән сүзләрен төкми-чәчми сөйләп биргәннәр. Моны ишеткәч, Дауд галәйһиссәлам куй хуҗаларын яңадан Сөләйман галәйһиссәлам янына җибәргән һәм үзе дә аның янына килеп, улыннан: «Минем чыгарган хөкемемне ничек бәялисең?» – дип сораган.

Сөләйман галәйһиссәлам: «Хөкемең бик яхшы», – дип җавап биргән. Дауд галәйһиссәлам: «Үзеңнең хөкемең нинди булыр?» – дигән.

Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Куйларны вакытлыча гына иген хуҗаларына биреп торырга кирәк, сөте балаларына булыр, ә иген куй хуҗаларына бирелергә тиеш. Игенне элеккеге хәленә җиткергәнчегә кадәр карап үстерсеннәр, тәрбияләсеннәр, аннан соң яңадан алмашырлар».

Дауд галәйһиссәлам әйтте: «Синең хөкемеңчә булсын», – диде һәм Сөләйман галәйһиссәлам чыгарган хөкем белән эш итәргә булдылар. (Әл-Иткань фи тәрҗимәтил-Коръән, 2, 57 б.)

## *Сүзлекчә һәм аңлатмалар*

*Антакия* – Антиохиянең гарәпчә әйтелеше.

*Әвәрә булма* – мавыкма, борчылма.

*Әл-Йасугъ* – Гайса пәйгамбәр.

*Әнсарлылар* – Пәйгамбәрнең Мәдинәдә яшәүче ярдәмчеләре.

*Әрийха карьясе* (г а р ә п) – Иерихон авылы. Борынгы чыганакларда торак пунктлары, шәһәрләрнең гомумиләштерелеп «карья» дип язылу очраклары да бар.

*Браһман* – һинд монахы, дәрвиш.

*Бәни Исраил* (г а р ә п) – Исраил халкы, исраиллеләр.

*Бәраъәте һәм пакьлеге* (г а р ә п) – гаепсезлеге һәм пакьлеге.

*Бәгальбәк* – Ливандагы шәһәр.

*Бипәрвалык пәрдәсе* (ф а р с ы) – ваемсызлык пәрдәсе.

*Гайшә разый Аллаһ ганъһә* (г а р ә п) – Гайшә, Аллаһ аңардан разый булсын.

*Ганимәт* – гаҗәеп отышлы булу, җайлы килеп чыгу, уңышлы булу һ.б.

*Гарәфә тавы* – Мәккә шәһәре янындагы тау исеме.

*Гарәп мөшрикләре* – төрле потларга (сыннарга) табынучы гарәпләр.

*Гафләтдән киреләнмәгән булса* (г а р ә п) – гамьсезлектән.

*Гумән вилаяте* – Оман провинциясе.

*Гомрә хаҗы* – Зөлхиҗҗә аеннан башка вакыттагы кече хаҗ сәфәре.

*Гүргән* (яки Җүрҗән) – Ирандагы бер өлкә.

*Гыйбри теле* – яһүд (и в р и т) теле.

*Гүштасп* – борынгы ассириялеләрнең изге патшалары.

*Диҗлә* – Багдад шәһәрен урап агучы елга (Тигр елгасы).

*Истимдад урыны* – ярдәм сорап ялвару урыны.

*Карун хәзинәсе* (г а р ә п) – бик саран кеше байлыгы. Коръәндә (28 сүрә, 76 аять) искә алынган тискәре персонаж.

*Каһкаһә белән көлү* (г а р ә п) – кычкырып (берәүне кимсетебрәк) көлү.

*Күһстан* – Ирандагы өлкә, таулар иле.

*Мөзәккәр* (г а р ә п) – ир җенесендәгеләр.

*Мөәннәс* (г а р ә п) – хатын-кыз җенесендәгеләр.

*Мөхәннәс* (г а р ә п) – ир яки хатын-кыз җенесендә булмаган, ике җенесле мәгънәсендә.

*Мәдәин шәһәре* – борынгы Ирандагы Ктесифон шәһәренең гарәпчә әйтелеше.

*Мөхәррәр кылдым* (г а р ә п) – азат иттем.

*Мәгъкульрәк* (г а р ә п) – ярашлырак.

*Мән вә сәлүә* (г а р ә п) – күктән төшкән илаһи ризык исеме дип фараз ителә.

*Мөһаҗирләр* – күчеп киткәннәр (Мөхәммәд пәйгамбәрнең иярченнәре).

*Нәҗесләнгән* (г а р ә п) – пычранган, пакьсезләнгән.

*Нәфесле мөсафир* (г а р ә п) – чаманы белмәгән кунак-юлчы.

*Нәүширван патша* (яки Әнүширван патша) – үзенең гаделлеге белән дан казанган Иран патшасы.

*Нәйнава* (яки Ниневия) – борынгы ассириялеләрнең шәһәре. Хәзерге Гыйрак республикасының бер провинциясе.

*Пәнир* (ф а р с ы) – сыр.

*Салман Фариси* – Мөхәммәд пәйгамбәрнең чәчтарашы (парикмахер) дип фараз ителә.

*Сарыф итә* (г а р ә п) – туздыра.

*Сохбәт* (г а р ә п) – утырышу, берәү белән сөйләшеп утыру; иптәшлек, юлдашлык.

*Табаристан* – Ирандагы өлкә.

*Тәдбирене* (г а р ә п) – тиешле чараны күреп.

*Фарсах* (ф а р с ы) – борынгы фарсыларда гамәлдә булган юл үлчәме (чама белән 1200 адымга тигез).

*Фәрәнгистан* (ф а р с ы) – Көнбатыш Европа (кайчагында Европа илләре мәгънәсендә дә гамәлдә булган).

*Ходайлык гыйталар* (ф а р с ы – г а р ә п) – илаһи нурлар.

*Хөҗрә* (г а р ә п) – кечкенә генә бүлмә.

*Хирфәтне эзләсә* (г а р ә п) – һөнәрне, кәсепне эзләсә.

*Һава вә һәүәс ихтыярына* (г а р ә п) – нәфсегә буйсынып.

*Шәһребану* – сасанидларның ахыргы патшалары Йәздегирнең кызы.

*Шам вилайәте* (г а р ә п) – Сүрия (өлкәсе).

*Шәэненә ярамаган* (г а р ә п) – дәрәҗәсенә туры килмәгән.

## *Файдаланылган әдәбият*


*Кабуснамә.* Габделкаюм Насыйри тәрҗемәсе. – Казан, 1882.

*Кобуснома.* С. Долимов тәрҗемәсе. – Ташкент: «Укытучы» нәшрияты, 1967.

*Әл-Итканъ фит-тәрҗимэтил-Коръән.* 1, 2 китап. – Имам Шәйхелислам бин Әсәдулла әл-Хәмиди тәфсире. – Казан, 1907–1911.

*Тәсһийлүл-Бәян фи-тәфсирил-Коръән.* 1, 2 китап. Фарсы теленнән тәфсир итүче Мөхәммәдсадыйк бин Шаһиәхмәд Иманколый әл-Казани. – Казан, 1910–1911.

*Кәлилә вә Димнә. Хөсәен Фәезханов тәрҗемәсе.* «Краткая учебная грамматика татарского языка» китабыннан алынды. – СПб, 1862. – 78–89 б.

**Габделҗәмил Габделхак улыЗәйнуллин**

**Әдәп-әхлак дәресләре**

***Уку ярдәмлеге***

**Уроки нравственности**

***Учебное пособие***

*На татарском языке*

Корректоры –
**Г.Т. Гыйләҗева**

Тышлык бизәлеше –
**М.А. Әхмәтов**

Басарга кул куелды 16.09.2014.
Цифрлыбасма.
Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Шартлы басма табагы 3,95. Шартлы нәшр. табагы 4.0.
Тиражы 350 д. Заказ 160/6.

**Казан университеты нәшрияты**

420008 Казан, Проф. Нужин ур., 1/37
Тел. (843) 233-73-59, 233-73-28